ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
М. ХӘСӘНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ
ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ

Р. Ф. Исламов

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Биобиблиографик күрсәткеч

Казан
2026

УДК 01:821.512.145.0
ББК 91.9:83.3 (2Рос=Тат)
И87

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе
һәм төбәкне өйрәнү институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла

Редколлегия:

Э.М.Галимова (рәис), Л.М.Айнутдинова, Р.Ф.Исламов, А.Р.Мансурова

Исламов Р. Ф.

И87 Габдулла Тукай: Биобиблиографик күрсәткеч. — Казан: ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2026. — 692 б. +12 б. ил.

Бу биобиблиографик күрсәткечтә татар халык шагыйре Г. Тукайның (1886–1913) нәшер ителгән әсәрләре, тормышы һәм иҗат мирасы турында дөнья күргән монографик хезмәтләр, гыйльми җыентыклар, якланган диссертацияләр, язылган мәкаләләр хакында мәгълүмат тупланган. Алар хронологик яктан 1913 елдан хәзергә кадәр вакытны иңли.

Китап Г.Тукайны өйрәнүчеләргә, татар әдәбияты галимнәренә, укытучыларга, аспирантларга, студентларга тәкъдим ителә.

Все права на издание, фотомеханическое воспроизведение, копирование, в том числе во фрагментах, сохраняются за издательством и автором. Любое использование материалов данного издания возможно только с письменного разрешения издательства и автора.

ISBN 978-5-9690-1444-2

© ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2026
© ТР ФА, 2026
© Р. Ф. Исламов, 2026

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ: ТОРМЫШЫ, ИҖАТ МИРАСЫ ҺӘМ ЯҢА БИБЛИОГРАФИЯСЕ

Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен
вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә
кадәр тикшереп чыгаралар әле.
Г. Тукай. «Уянгач беренче эшем»

I

Халык шагыйре Габдулла Тукай — егерменче йөз башы татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган классик әдипләребезнең берсе. Аның тормыш юлын һәм иҗат мирасын өйрәнү юнәлешендә хәзерге вакытка шактый хезмәтләр башкарылган. Ләкин ирешелгән казанышлар белән бергә, башкарыласы эшләр дә байтак. Чөнки моңа кадәр дөнья күргән хезмәтләр аерым җитешсезлекләрдән, төгәлсезлекләрдән азат түгел. Профессор Ибраһим Нуруллин (1923–1995) һәм Риф Якупов (1940–2011) язганча, «Революциягә кадәрге истәлекләр шагыйрьгә кагылышлы факт, вакыйга һәм мәгълүматларның нигезле һәм ышанычлы булулары белән аерылып торалар… Революциядән соңгы истәлекләргә килгәндә исә, шагыйрьнең олылыгын раслау, аны күтәрү һәм мактау җитәрлек. Әмма бу истәлекләрнең күбесендә Тукай бизәлгән, ул «грим сөртелгән» кыяфәттә күз алдына килеп баса»[1]. 1944 елда Г. Тукай турында истәлекләр туплаганда, аларның кайберләрен, дөреслеккә туры килми дип, хәтта, авторларына кире кайтару очраклары да булгалаган[2].

Сәяси эшлекле, публицист Фуат (Мәхмүтфуат) Туктаров (1880–1938) Г. Тукайның гомерен шундый өч дәвергә бүлеп карарга тәкъдим итә: «Беренче дәвере — тууыннан алып Уральскига киткәнче үткәргән гомере, моны Тукаев балалык вакыты диеп атарга тиештер. Икенче дәвере — Уральски мәдрәсәсендә торган елларыдыр ки, монысы Тукаевның шәкертлек заманыдыр. Өченче дәвере исә — Тукаевның соңгы алты еллык гомере, ягъни Казанда үткәргән елларыдыр». Шул ук вакытта ул, бәлки, тагын берничә дәвергә бүлү ихтималын да искәртеп, «Тукаевның тәрҗемәи хәлен, аның әсәрләрен бик тәфсилле рәвештә тикшергәннең, фәнни һәм тарихи тәдкыйкат[3] ясаганнан соңында гына мөмкин булачактыр ки, моның өчен әһле булган бер галимнең байтак вакытлар хезмәт вә һиммәт[4] сарыф итүе кирәктер»[5], — дип яза.

---

[1] Нуруллин И. Хатирәләр турында берничә сүз // Тукай турында хатирәләр / Төз. һәм текст. аңл. бирүчеләр: И. Нуруллин, Р. Якупов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — Б. 4.

[2] Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге: 9 ф., 4 тасв., 30, 31 сак. берәм.

[3] *Тәдкыйкат* — җентекләү.

[4] *Һиммәт* — кайгыртучанлык.

[5] «Усал» // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 239.

Билгеле булганча, «Тукайның Уральскига[1] киткәнче яшәгән чорын өйрәнүдә аның «Исемдә калганнар» дигән автобиографик очеркы төп чыганак булып санала. Ләкин анда да вакыйгалар даталары белән күрсәтелмәгән, бәлки, күпчелек очракта «бервакыт», «кайвакыт», «шул вакыт», «кайчакта», «бер заман» дип кенә язылган... Әмма «Исемдә калганнар» — фантастик әсәр дә түгел. Андагы вакыйгалар, даталары күрсәтелмәсә дә, чынбарлыкны чагылдыралар»[2].

Шуңа күрә, үткәндәге бай тәҗрибәгә нигезләнеп, заман таләпләрен истә тотып, булган истәлекләргә тәнкыйди карап, яңа табылган материалларны файдаланып, мәсьәләне мөмкин кадәр җентекләп һәм киңрәк яктырту зарурлыгы барлыкка килде.

Казан губернасы, Казан өязнең Иске Мәңгәр волостена караган Кушлавыч авылының мәншүрле (указлы)[3] мулла Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалим улы (1842/43–1886) беренче тапкыр 1865 елның 24 маенда шул ук губерна һәм өязнең Ямаширмә авылының (хәзер Татарстан Республикасы Биектау районы) указлы мулласы Сиражетдин Нәҗметдин улы (1813/17–1883) һәм Мөхибҗамал Ягъфәр кызы (1822–?) гаиләсендә туган Бибигафифәгә (Гафифә) (1840/41–1885) өйләнә. Аларның Мөхәммәтшәриф (1873–1890)[4] исемле ир баласы һәм Бибигазизә (Газизә) (1876–1963) исемле кыз баласы була[5]. Г. Тукай үзенең «Исемдә калганнар» дигән автобиографик очеркында бу хакта искә төшереп, шулай яза: «Мулла булгач та өйләндеке бер җәмәгате илә берничә еллар торгач, җәмәгате вафат булып, бер ир вә бер кыз баласы калмыштыр»[6].

Бибигафифә 1885 елның 28 апрелендә (10 маенда) өченче баласын тапканда кан китүдән вафат була[7].

Аннары Мөхәммәтгариф Өчиле[8] авылы мулласы Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы Әмировның (1829–1909)[9] кызы Бибимәмдүдәгә (1866–1890) (1886 елгы метрика

---

[1] *Уральск* — 1613 елда Чаган елгасының Җаек (Урал) елгасына койган урынына кальга (крепость) буларак нигезләнгән. 1773–1775 елларда Е. И. Пугачев (1742–1775) җитәкчелегендә крестьяннар күтәрелеше үзәкләренең берсе булганга күрә, Екатерина II (1729–1796) указы белән 1775 елда шәһәрнең Җаек исеме Уральск итеп үзгәртелгән. 1968 елда Казакъстан ССРның (хәзерге Казакъстан Республикасының) Урал өлкәсе үзәгенә әйләнә. Казакълар аны Тәгә (Тәкә) дип тә атаганнар.

[2] Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1973. — 28 апр.

[3] 1864 елның 30 апрелендә ала.

[4] Ютәл авыруыннан 17 яшендә 1890 елның 12 (24) мартында вафат була, Кушлавыч авылында җирләнә.

[5] Баһаветдинова Х. Сиражетдин хәзрәт шәҗәрәсендә Габдулла Тукай эзләре / Х. Баһаветдинова // Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2014. — № 3–4. — Б. 250–251.

[6] Тукаев Г. Исемдә калганнар // Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1901. — Б. 4.

[7] Баһаветдинова Х. Күрс. хезм... — Б. 251.

[8] *Өчиле* — Казан губернасы Казан өязе Яңа Кишет волостена (хәзерге Татарстан Республикасы Арча районы Өчиле җирле үзидарәсе) караган авыл. Элек Кече Бирәзә — русча Малые Верези дип тә аталган.

[9] Зиннәтулла Әмиров хәзерге Пермь краеның Каҗмакты (Барда) авылында Әмирхан Әмиров (1769–1817) һәм хатыны Бәзиха (1776–1834) гаиләсендә туган икенче уллары Зәй-

дәфтәрендә — Миңсафа[1]) өйләнә. 1886 елның 14 (26) апрелендә аларның Габдулла (метрика дәфтәрендә — Габдуллажан[2]) исемле уллары туа. Бу турыда Г. Тукай үзе шулай ди: «Моннан соңра атам, икенче мәртәбә өйләнүе уларак, Өчиле карьясе[3] Зиннәтулла хәзрәтнең Мәмдүдә исемле кызыны (минем анамны) алмыштыр. Анам илә бер ел ярым кадәр торгач, беренче бала уларак, мин дөньяга килгәнмен»[4].

Ләкин бәхетле тормыш озакка сузылмый: 1886 елның 29 августында (10 сентябрендә) Мөхәммәтгариф хәзрәт «кату зәхмәте илә» вафат була. «Исемдә калганнар»да бу хакта мәгълүмат шулай китерелә: «Минем туганыма 5 ай заман үткәч, атам аз гына вакыт авырып, тәрке дөнья итмештер[5]»[6]. Чынлыкта исә «әтисе үлгәндә Габдулла нәкъ дүрт ай ярымлык булган. Күренә ки, шагыйрь балачак хатирәләрен чамалап кына язса да (4 ай ярымлык вакытын төгәл хәтерли алмый)»[7].

Тол калган егерме өч яшьлек Бибимәмдүдә кире Өчилегә атасы йортына кайта. Анда Зиннәтулла хәзрәтнең икенче хатыныннан[8] туган алты балалы ишле гаилә арасына сыймау сәбәпле, 1888 елның 22 декабрендә[9] Вятка губернасы Малмыж өязе Сосна пүчинкәсенең (хәзерге Татарстан Республикасы Балтач районы) указсыз мулласы (чыгышы белән хәзерге Татарстан Республикасы Әтнә районы Мөндеш авылыннан) алтмыш тугыз яшьлек Мөхәммәтшакир Фәйзуллинга (1839–1916)[10] кияүгә чыгарга мәҗбүр була. Кечкенә Габдулланы Кушлавычка илтеп, бер кибән арыш хисабына Шәрифә (1818–1895) исемле карчыкка вакытлыча асрамага биреп калдыра[11]. «Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам мине авылы-

---

нелбәшәр (1803–1853) һәм хатыны Габидә (1804–?) улы. Ул башта Солтанай (хәзер Барда районында) мәдрәсәсендә укый. Аны тәмамлагач, Уфа губернасының Аргаяш (хәзер Чиләбе өлкәсенең шул исемдәге район үзәге) кантонындагы Гашир дигән татар авылында балалар укыта. Аннары Казан губернасындагы Кышкар мәдрәсәсендә белемен арттырганнан соң, Өчиле авылына имам итеп тәгаенләнә: Акманаев Р. «Туган илем Кожамакты карьяседер...» / Р. Акманаев. — Барда, 2011. — Б. 15–16.

[1] Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1973. — 26 апр.

[2] Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? ...

[3] *Карья* — авыл.

[4] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 4.

[5] *Тәрке дөнья итмештер* — үлгән, вафат булган.

[6] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 5.

[7] Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? ...

[8] *Икенче хатыныннан* — Зиннәтулла хәзрәтнең беренче хатыны Камилә Хәбибулла кызы 1874 елның 28 ноябрендә вафатыннан соң, Наласа авылы мулласының тол калган хатыны Латыйфа Фәтхулла кызына өйләнә. Аларның Бибисажидә (1877–1956), Гандәлип (1879–?), Гөлчәһрә (1880–?) исемле кызлары, Кәшфелкәбир (1879–1938), Кәшфинур (1885–1918/19), Шәмсемөнир (1890–1914) исемле уллары туа. Габдулла Кушлавычка кайтарылганда Шәмсемөнир әле тумаган була.

[9] Якупов Р. Тукай Сосна пүчинкәсендә / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1974. — 7 сент.

[10] Ул 1916 елның 3 декабрендә күкрәк авыруыннан вафат була.

[11] *Шәрифә (1818–1895) исемле карчыкка вакытлыча асрамага биреп калдыра* — Кушлавыч авылы кешесе, Г. Тукайның ерак кардәше Кәмалетдин Хисаметдинов (1882–?) үзенең истәлегендә бу вакыйганы шулай сурәтли: «Атасы үлеп анасы башка иргә киткәч, Тукайны

мыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрә карчыкка вакытча асрарга калдырып, үзе Сасна нам карьянең [1] имамына кияүгә чыкмыштыр... Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-өч ярым яшендә генә булганмын дип уйлыйм»[2], — дип яза Г. Тукай. Шуңа күрә Шәрифә карчыкның аңа карата булган начар мөгамәләсен бу хакта белгән кешеләр сөйләвенә генә нигезләнеп тасвирлый.

Алга таба булган вакыйганы Г. Тукай шулай сурәтли: «Мин бу карчыкта торган мөддәттә[3] анам да теге муллага үзләшеп җиткән булырга кирәк: ул бервакыт мине үзе янына Саснага алдырырга атлар җибәрткән... шул атка утырып киткән дәкыйкаләрдә[4] миндә, бала булсам да, бер нәүгы шөгур хасил булганмы[5], нидәндер, мин хәзердә дә атта утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам»[6]. Аңлашылганча, бу 1889 елның март–апрель айларына туры килә. Биредә аны яхшы кабул итәләр, бигрәк тә үги әтисенең сөюе, чәй янында ак күмәчкә кәрәзле бал ягып бирүе баланың хәтеренә нык уелып кала.

Ләкин әлеге бәхет-шатлыклар бары тик бер ел тирәсе генә булып ала. Чөнки әнисе 1890 елның 18 гыйнварында «эч китү берлә» вафат була[7] һәм бөтенләй ятим калган Габдулланы февраль–март айларында янә Өчиле авылына Зиннәтулла бабасы үзе алып кайта. Ул вакытта аңа 3 яшь тә 9 ай була. «Исемдә калганнар»да бу вакыйга шулай тасвирлана: «Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы семья эченә мин ятим булып килеп кергәнмен. Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам — юатучы, иркәләним дисәм — сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр»[8]. Шул еллардагы корылык сәбәпле, ул якларда каты ачлык барлыкка килә[1].

Өчилегә бабасына калдырган. Менә шуны ишетеп, күршебездә Урманай Гыйззәтулла, аның күп кешегә холкы ярамый торган хатыны Шәрифә карчык иде. Боларның бер генә кызлары бар иде, угыл балалары җук иде... Менә болар үзләренә бала итеп асрап аламыз дип, Тукайны алып кайтканнар иде»: Хисаметдинов К. Габдулла Тукаев хакында исемдә калганнар / К. Хисаметдинов // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 180.

[1] *Сасна нам карьянең* — Сасна исемле авылның; «Сосна һәм Сосна пүчинкәсе ике аерым авыл булып...Бу пүчинкәдә яшәүчеләрнең элекке бабалары Сосна авылыннан күчеп килгәнлектән, авыл Сосна пүчинкәсе дип атала»: Якупов Р. Тукай Сосна пүчинкәсендә / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1974. — 5 сент.

[2] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 5.

[3] *Мөддәттә* — вакыт эчендә.

[4] *Дәкыйка* — минут.

[5] *Бер нәүгы шөгур хасил булганмы* — бер төрле сизенү, аң ачылып китү барлыкка килгәнме.

[6] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 6.

[7] Бу мәгълүмат Вятка губернасы Малмыж өязе (хәзер Татарстан Республикасы Балтач районы) Көшкәтбаш авылы мәчетенең метрика дәфтәрендә теркәлгән.

[8] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 7.

Зиннәтулла хәзрәт, хәтта, тирә-як авылларга чыгып, хәер сорашып йөрергә мәҗбүр була. Габдулла чәчәк белән авырый. Бу гаиләдә бары тик Бибисаҗидә (1877–1956) генә аның төп таянычына әверелә. «Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә аппак саф бер фәрештә күренә»[2], — ди аның турында шагыйрь еллар үткәч.

1893 елның 25 декабрендә Бибисаҗидәне Көтернәс[3] авылы кешесе Әхмәтсафа Хәбибуллинга (1869–?) кияүгә бирәләр[4]. Никах һәм туй мәҗлесе булган Өчиле авылына Кырлайдан Габдулланы да алып киләләр. Байтак еллар үткәч, Уральскидан 1903 елның 30 июнендә язган хатында аның кылган изгелекләрен шулай искә ала: «Мөшфика[5] апаем! Синең сабый вакытта һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да онытмам. Анам дарел бәкайә рихләт иткәч[6], бабайлар өендә бәңа мәрхәмәт күзе илән караучы юк иде, мәгәр син бар идең»[7].

«Ни күрсәм дә күргәнмен, ни булса да булган — һәр ничек мин бу семьяга сыймаганмын. Бер көнне бабай, үги әбинең киңәше илә булырга кирәк, авылымыздан Казанга бара торган бер ямщиккә мине утыртып, Казанга озаткан. Ямщик Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан 60 кына чакрым), Печән базарында[8]: «Асрарга бала бирәм, кем ала?!» — дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктән алган. Ул мине мөддәтсез бер асрау бала итеп өенә алып кайткан»[9], — дип яза Г. Тукай бу гаиләдән үзенең беренче тапкыр аерылуы турында. Чынлыкта исә «бер ямщик» дигәне Зиннәтулла хәзрәтнең күршесе, авыл халкы җитештергән әйберләрне җыеп, Казанга илтеп сату һәм аннан башка кирәк-яракларны алып кайту белән шөгыльләнгән Гыйльфан Сабитов (?–1936) була. Ул Казандагы Әхмәт исемле таныш байның балалары булмау сәбәпле, аңа Габдулланы уллыкка алырга тәкъдим итә. Ләкин алар килгәндә, бай өйдә булмый, ә асрау кыз хуҗа рөхсәтеннән башка баланы алып кала алмый. Аптырашта калган Гыйльфан кире базарга барып, андагы халыкка хәлне сөйли[10]. Шул вакыт Мөхәммәтвәли (?–?) исемле

---

[1] Билгеле булганча, XIX гасырның 90 нчы еллары Идел буенда кытлык еллар исәпләнелә. Ә инде 1891 елда аяусыз корылык, 1892 дә рәхимсез ачлык була.

[2] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 9.

[3] Хәзер бу авыл Арча районының Күпербаш авылы белән кушылган.

[4] Туйдан соң Әхмәтсафаны Каенсар авылына мулла итеп куялар. Аларның Габделвәһһәб (1896–1957), Мәсрүрә (Бибимәсрүрә, 1900–1981), Һания (Өммегания, 1903–1976), Фатыймабикә (1907–1942), Нурдидә (1910–?), Әкълимә (1922–?), Солтанәхмәт (1905–1942) исемле балалары туа. Бибисаҗидә хәзерге Татарстан Республикасы Яшел Үзән (элекке Норлат) районы Бәчек авылы мәктәбендә укыткан Һания тәрбиясендә булып, шунда вафат була.

[5] *Мөшфика* — шәфкатьле.

[6] *Дарел бәкайә рихләт иткәч* — вафат булгач, үлгәч.

[7] Апасы Саҗидәгә // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 74.

[8] *Печән базары* — Казанның хәзерге Париж Коммунасы исемендәге бакчадан алып Париж Коммунасы, Татарстан һәм Мәскәү урамнары чатлыкларына кадәр мәйданны биләп торган урын. Үткән гасырның утызынчы елларына кадәр Казан татарларының үзенә күрә иҗтимагый бер үзәге рәвешендә яшәп килә.

[9] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 9–10.

[10] Зыятов Ф. Тукай Өчиледә / Ф. Зыятов // Казан утлары. — 2011. — № 4. — Б. 121.

бер кеше баланы үзләренә алып китә. Г. Тукай аның төп кәсебен хәтерләми: «Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа бистәдә[1] иде. Әти талчокта сату итә идеме, әллә тиреченә идеме шунда — анысын яхшы белмим. Әни, бер дә армый-талмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде»[2]. Биредә аның өсте бөтен, тамагы тук була, шул рәвешле ике ел рәхәтлектә үткәрә. Бервакыт Мөхәммәтвәли белән Газизә (?–?) икесе дә берьюлы авырый башлыйлар. «Алар, үзләренең үләчәкләреннән куркып: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк...» — дип, теге мине Казанга китергән ямщикне табып, мине янәдән аңар утыртып, Өчиле карьясенә җибәргәннәр»[3], — дип яза Г. Тукай «Исемдә калганнар»да. Баланың кире кайтканына Зиннәтулла хәзрәт гаиләсендә, әлбәттә, шат булмыйлар.

Озакламый Габдулланы Кырлай[4] авылыннан Сәгъди[5] исемле бер кеше асрамага га алып китә. Г. Тукай бу турыда шулай яза: «Арба кузгалды. Сәгъди абзый белән без янәшә утырып киттек. Ул юлда миңа: «Менә хәзер Кырлайга кайтып җитәбез, анда әниең[6] каршы чыгып көтеп тора торгандыр, Алла боерса, бездә катык, сөт, ипи ипи күп, теләгәнчә ашарсың», — дип, миңа барып җитәргә ике-өч кенә чакрым калган бәхетләр илә мине җуатып бара иде»[7].

Өчиледә туган, Габдулланың анасы Бибиməмдүдә белән бергә үсеп, Кырлайга кияүгә чыккан Нәфисә Әхмәтшина (1864–?) истәлегенә күрә, Сәгъди абзыйларның Сабира[8] белән Сажидә[9] исемле ике кызы булып, ир балалары булмауга борчылалар. лар. Аның киңәше буенча алар Габдулланы үзләренә алырга булалар. «Шуннан соң, озак тормыйча, бердән-бер көнне Сәгъди абзый, ат җигеп, Зөһрә тәтәй белән мине Өчилегә шул турыда сөйләшергә җибәрде. Без Габдулланың бабасы белән барып сөйләшкәч, ул, бик куанып, риза булды һәм шунда ук безгә баланы утыртып алып китәргә кушты. Без аны, үзебез белән утыртып, Кырлайга алып кайттык»[10], — ди, ул. Кырлай авылы кешесе, Г. Тукайның балалык һәм мәдрәсә елларында иң якын дусларыннан берсе булган Сафа Мөхәммәтшин (1879–1951) дә аның сүзләрен куәтли: «Нәфисә абыстайның сүзе дөрес, Габдулланы Кырлайга Сәгъди абзый үзе алып

---

[1] *Яңа бистә* — Казанның көньягында урнашкан бистә, Казан елга портына барганда тимер юл күперен чыккач су кул яктагы бистә (хәзер шәһәрнең Идел буе районында).

[2] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 10.

[3] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 12.

[4] *Кырлай* — Казан губернасы Казан өязе Иске Мәңгәр волостена (хәзерге Татарстан Республикасы Арча районы Яңа Кырлай җирле үзидарәсе) караган авыл.

[5] *Сәгъди* — Сәгъдетдин Шәмсетдин улы Салихов (1837–1904); ул 1904 елның 20 маенда фалиждан (паралич) вафат була: Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1973. — 30 апр.

[6] *Әниең* — Сәгъди абзыйның хатыны Бибизөһрә Габделгани кызы Габделхаликова (?–?).

[7] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 13.

[8] *Сабира* — Бибисабира (1869–1892), Сәгъдинең олы кызы.

[9] *Сажидә* — Бибисажидә (1889–1894), Сәгъдинең кече кызы.

[10] Нәфисә Әхмәтшина истәлекләре // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 24.

кайтмады, чөнки ул вакытта Сәгъди абзыйның бер кулына паралич булган иде, ул үзе ат тотып йөрерлек түгел иде. Габдулланың хәтерендә ялгыш калгандыр»[1].

Габдулланың Кырлайга килүенең шагыйрь үзе язганча булганын аның замандашы, яшьтәше һәм сабакташы Хәлилелрахман Гобәйдуллин (1886–1951) да сөйли: «Нәфисә карчык белән Сафа карт әйткәнчә, аны Кырлайга Нәфисә абыстай белән Сәгъди абзый хатыны Зөһрә абыстай алып кайтмадылар, Габдулла үзе язып калдырганча, Сәгъди абзыйның арбага кашка туры ат җигеп, Габдулланы янына утыртып алып кайтканын бүгенгечә хәтерлим. Мин Нәфисә абыстайны ялганлый торган карчык дип әйтәсем килми, картлык сәбәпле аның хәтере чуалган булырга мөмкин»[2].

Дөрес, Сәгъди абзыйны паралич сугуы хакында Г. Тукай үзе дә яза. Ләкин анда ул болай тасвирлана: «Әтине дә, кич белән әллә кайсы авылдан кайтып ат туарган чакта, кисәктән килгән бер авыру эләктерде. Аның шундук аңсыздан бер аягы аксады. Бу авыру хакында «ат җене сукты», «йолдыз атты»-фәлән кеби төрле хөкемнәр йөрттеләр»[3]. Күренгәнчә, вакыйга Габдулла инде Кырлайга килгәч була, кулы түгел, ә аягы имгәнә. Моны Х. Гобәйдуллин да раслый: «Шул кыш Сәгъди абзыйны паралич сугып, аның бер кулы (!), бер аягы зәгыйфь булып калды»[4].

Габдулланың Кырлайга килүе тарихи яктан 1892 елның июнь урталарында була. Чөнки ул «Исемдә калганнар»да яза: «Мин барып бер аймы, күпмедер торгач, урак вакыты җитте. Әти, әни вә ике апай уракка китә башладылар»[5]. Биредә ул әле мул тормышта яши. Үзенең тиңдәшләре белән күңеле булганчы уйный, ашау мәсьәләсе дә борчымый.

Ләкин көтмәгәндә беркөнне Бибисабира басудан авырып кайта да, иртәгесен вафат була. Шуннан соң Габдулла әнисенең: «Менә, «үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр; үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» шул инде ул; мөгаен шуның шомлыгыннан булды инде бу!»[6] дигән сүзләрен ишеткәли башлый.

Урак тәмамланганнан соң бәрәңге алу вакыты җитә. Инде Габдулланы да эшкә җәлеп итә башлыйлар. Шулай бервакыт Сажидә апасы ялгыш аның аягына тимер көрәк белән чаба. Әлеге вакыйганы Г. Тукай үзе болай яза: «Бу вакыт, көз көненең салкын вакытлары булса да, мин яланаяк идем. Аякларым туңганга, мин аларны балчыкка күмеп утыра идем. Бервакыт шулай аякны балчыкка күмеп, бәрәңге чүпләгән чагымда, теге бәрәңге казучы аксак Сажидә апай яңлыш минем аякка тимер көрәк белән чапты»[7].

Инде эшләр тәмамлангач, Габдулланы авылның имамы Фәтхерахман хәзрәт Гобәевның (?–?) хатыны Mahруй абыстайга (?–?) кыз балалар белән бергә укырга би-

[1] Нәфисә Әхмәтшина истәлекләре... — Б. 25.

[2] Хәлилерахман Гобәйдуллин истәлеге // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 45.

[3] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 27.

[4] Хәлилерахман Гобәйдуллин истәлеге... — Б. 46.

[5] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 16.

[6] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 18.

[7] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 19.

рәләр. Ул анда бер кыш сабак тыңлый, «Иман шарты», «Һәфтияк»[1], «Бәдәвам»[2], «Кисекбаш»ларны[3] укый.

Икенче елда исә, язга чыгар алдыннан Сәгъди абзыйларның бер ир баласы дөньяга килә. Габдулла килер алдыннан бер ел элек вафат булган уллары[4] истәлеге итеп, аңа да Садри[5] дип исем куялар. «Исемдә калганнар»да бу хакта шулай укыйбыз: «Мин, әни эштә чагында, һәрвакыт шул баланы җуатып, тирбәтеп утыра идем. Менә тагы урак вакыты да җитте; үткән җәй, бөтен авыл халкы эштә булганда, урам буе чабып йөргән мин бер малайны бу ел Садрины (ул бала Садретдин исемле иде) тартып йөрергә ураккa да алып чыктылар. Шунлыктан бу җәем уйныйсы килгән балалар өчен зур газап булган нәрсә — эш белән үтте. Бу бала тугач, әтинең мине сөюе әүвәлгечә бөтен калса да, әни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды, шөйлә ки[6], мин үз өлешемә төшкән аз гына мәхәббәттән дә коры калдым»[7].

Н. Әхмәтшина истәлегендә дә бу раслана: «Без күчкәч, Зөһрә тәтәй бер ир бала тапты. Аның исемен Садри дип куштылар. Шуннан соң Сәгъди абзый семьясында Габдулланың кадере китте. Элеккечә аны кадерләми башладылар...»[8].

Икенче көздә аны мәдрәсәгә укырга бирәләр. Ул әүвәл Хәбиберахман Гобәевтан (Хәбри хәлфә, 1869–?) сабак тыңлый, аннары Фәтхерахман хәзрәткә күчә. Еллар үткәч, остазын ихтирам белән ул шулай искә ала: «Авылымызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, бер заман әтинең шәриге йә дусты булгангамы, нидәндер, миңа атна саен 5 тиен акча бирә иде»[9]. Моңа нисбәтән хәзрәтнең улы, Габдулланың яшьтәше һәм сабакташы Хәлилерахман Гобәйдуллин үзенең истәлегендә Габдулла Кырлайга килгән көннәрдә үк әтисе әйткән шундый сүзләрне китерә: «Әткәй миңа: «Ул минем белән бергә Кышкарда[10] укыган Гариф абзый улы булырга кирәк, атасы

---

[1] *«Һәфтияк»* — Коръәннең кыскарак сүрәләреннән сайлап төзелгән җыентык; «Коръәннең җидедән бере» мәгънәсендә.

[2] *«Бәдәвам» китабы* — дини әдәбият ядкәре. Аның авторы билгесез. Кайбер фаразлар буенча, ул Идел буе Болгарында иҗат ителгән, 17–18 йөзләргә нисбәт иткән фикерләр дә бар.

[3] *«Кисекбаш»* — XIV гасырда иҗат ителгән язма дини-дидактик шигъри әдәби әсәр. Күп тапкырлар типография ысулы белән бастырылган һәм татарлар арасында популяр булып, киң таралган.

[4] *Бер ел элек вафат булган уллары* — Сәгъдетдин улы Садретдин 1890 елның 12 гыйнварында 8 нче яшендә эч авыруы белән вафат була: Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1973. — 30 апр.

[5] *Садри* — Садретдин (1893–?). Ул 1917 елда мәгълүм Октябрь түнтәрелешеннән соң Кырлайда беренчеләрдән булып Кызыл Армия сафларына языла һәм ватандашлар сугышында һәлак була (төгәл елы әлегә билгесез).

[6] *Шөйлә ки* — менә шулай.

[7] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 25.

[8] Нәфисә Әхмәтшина истәлекләре… — Б. 26.

[9] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 26.

[10] *Кышкар* — элекке Казан губернасы Казан өязенә (хәзер Татарстан Республикасы Арча районы Яңа Кишет җирле үзидарәсе) караган һәм мәдрәсәсе белән танылган авыл.

дус кеше иде, улын да күргә кирәк», — диде»[1].

Шул вакытларда Сәгъди абзыйның кече кызы Бибисаҗидә дә чахотка авыруыннан вафат була[2].

Чыганаклардан күренгәнчә, Г. Тукай атасы Мөхәммәтгарифның бертуган апасы Фаизә Шәмсетдинова (1838–1922) Уральск шәһәрендә яшәүче бертуган сеңелесе Бибигазизә Госмановага (?–?) хат язып, Габдулланың бөтенләй ятим, чит кешеләр кулында калуын, үзенең мөмкинлекләре чикле булуын аңлатып, аны алуларын үтенә[3]. Бибигазизә һәм Галиәсгар (1845–1900)[4] Госмановларның Гобәйдулла исемле бердәнбер уллары да вафат була[5].

1894 елның көзендә Кушлавыч авылының Бәдри[6] исемле кешесе Кырлайга Габдулланы алырга килә. «Исемдә калганнар»да вакыйганың башланышы шулай тасвирлана: «Берваkыт көз көне, өйләдән соң, әти белән әни ындырда иде, мин җан тәрәзә төбендә «Рисаләи Газизә»[7] укып утыра идем, безнең капкага бер арбалы кеше килеп туктады»[8]. Мосафир өйгә кереп, баладан әти-әниләре кайдалыгын сорашкач, аларны алып кайтырга куша. Хуҗалар кайтып, күрешеп, чәй эчкәч, мосафир бу баланы алырга килгәнлеген белдереп, сүз башлый: «Мин — Кушлавыч кешесе. Бу бала авылымызның имамының баласы. Без аны ничә еллардан бирле югалтып, кайда икәнлегеннән бихәбәр идек; менә хәзер таптык. Ул сездә икән. Җаек каласында аның атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе[9] бар. Менә шул җизнәсе, каенесесенең болай кара кешеләр кулында йөрүен ишетеп, аны Җаекка үз катына чакырмакчы була. Менә мин быел, Җаекта аның кушуы буенча, бу баланы эзләргә чыктым, менә хәзер алып китәм»[10].

Өйдә зур киренклек урнаша һәм сөйләшү югары тонга күчә башлый. Бәдретдин абзый: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга, мин хәзер үрәдникkә әйтәм, әле без аны таба алмый йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне падсуд җибәрер-

---

[1] Хәлилерахман Гобәйдуллин истәлеге... — Б. 46.

[2] Бибисаҗидә 1894 елның 30 апрелендә вафат була: Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1973. — 28 апр.

[3] Нуриев Җ. Килү / Җ. Нуриев // Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — Б. 24.

[4] *Галиәсгар* — Галиәсгар Госман улы Госманов, Мәңгәр волосте Түбән Сәрдә (хәзер Татарстан Республикасы Арча районында) авылында туып үскән.

[5] *Гобәйдулла исемле бердәнбер уллары да вафат була* — Гобәйдулла 11 яшендә 1894 елның 21 февралендә тамагы шешүдән вафат була.

[6] *Бәдри* — Бәдретдин Хисаметдин улы Хисаметдинов (?–?), Г. Тукайның ерак туганы. Ул, Габдулланы Уральскига озатып җибәрә. 1898 елда үзе дә шунда күченеп китә, баштарак балта остасы, аннары вак сәүдәгәр була. Гайнетдин Туприев 1937 елгы истәлегендә аның Башкортстан авылларының берсендә яши икән дип 1932 елда ишеткәнлеген әйтә: Tatar xalьq şaoqire Ƣabdulla Tuqaj turьnda jaŋa materiallar // Sovet ədəbiatь. — 1936. — № 7. — B. 81.

[7] Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838) әсәре.

[8] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 27.

[9] *...атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе* — сүз Бибигазизә Мөхәммәтгалим кызы Госманова һәм аның ире Галиәсгар Госман улы Госманов турында бара.

[10] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 28–29.

мен», — дип, куркыткач, Сәгъди абзый белән хатыны риза булалар. Киткәндә аларны хуҗалар елый-елый басу капкасына кадәр озата баралар.

Бу турыда Н. Әхмәтшина: «Сәгъди абзый семьясында үзен бик үгисетә башлаулары турында килеп миңа зарлангалагач, мин, ул турыда Өчилегә, бабаларына хәбәр иттем. Шуннан соң аны Кушлавычтан килеп алып киттеләр», — дигәч, аның истәлекләренә карата, гомумән, берникадәр сораулар барлыкка килә, әлбәттә.

Бәдретдин абзый белән Габдулла кайтышлый юл өстендәге Өчиле авылына Зиннәтулла хәзрәткә кереп, чәй эчеп чыгалар.

Габдулланың Кырлайдан китү вакытын дәлилли торган тагын бер факт ачыклана. Кушлавычка кайтканның икенче көненең иртәсен ул шулай тасвирлый: «Чәй эчтек, Бәдри абзыйның Гайшә исемле зур гәүдәле, күк күзле, ачык кына йөзле бер хатыны, Камалетдин исемле 14–15 яшьлек бер угълы[1], вә Кәшифә исемле 12 яшьләрендә бер кызы[2], вә Нәгыймә исемле бер имчәк баласы бар иде»[3]. Р. Якупов моны шулай шәрехли: «Имчәк бала дип гадәттә яшь, яшь ярымлык баланы атыйлар. Бу баланың туган елын белү өчен без Габдулла Кушлавычка кайткан 1894 елдан бер елга чигерәбез. Димәк, Нәгыймә 1893 елда туган булырга тиеш. Кушлавыч авылында 1893 елда туган кешеләрнең исемлеген эзлибез. Анда Нәгыймә 1893 елның 14 маенда туган, әтисе — солдат Бәдретдин Хисаметдин угылы, әнисе Гайшә Мөхәммәтсадыйк (икенче бер язмада Садыйк) кызы, дип язылган»[4].

Бәдретдин абзый озакламый үз эшләре белән Казанга китә һәм анда бер ай була. Габдулла шул вакытта Камалетдин белән бергә авылның мәдрәсәсенә барып, сабак укый. Шул вакытларда аның кулына «Фәвакиһел-җөләса»[5] китабы килеп керә. Аның белән танышуын шулай тасвирлый: «Кич белә китаплар актарганда, кулыма «Фәвакиһел-җөләса» китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм вә аңларга тырышам, фәкать мин Кырлайда чакта тик «Газизә»[6] вә «Сөбателгаҗизин»нәр генә укыганга, бу китаптагы оят сүзләргә гаҗәпләә-

---

[1] *Камалетдин исемле 14–15 яшьлек бер угълы* — Камалетдин 1882 елның 1 гыйнварында туган: Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1973. — 30 апр.

[2] *Кәшифә исемле 12 яшьләрендә бер кызы* — Кәшифә 1885 елның 1 ноябрендә туган: Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1973. — 30 апр.

[3] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 31.

[4] Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли? / Р. Якупов // Хезмәт (ТАССР, Балтач р-ны). — 1973. — 28 апр.

[5] Фәвакиһәл-җөләса фил-әдәбият. Мостатраф вә рузел-әхйар китапларыннан интихаби тәэлиф кыйлынып кырык руза үзеренә мөрәттиб мордәдәлларның калебләрен әхйа кыйлыр бер китаптыр вә Габделкаюм мелла Габденнасыйр угылының каләм фәкыйранәсеннән җәрәян итмеш бер әсәрдер. Ошбу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмышдыр 1884 нче елда. — Б. 615 б.

[6] *«Газизә»* — Таҗетдин Ялчыголның (1768–1838) Урта Азия шагыйре Суфи Аллаһияр-ның (1630 еллар — 1721 яки 1723) «Сөбател-гаҗизин» («Көчсезләрнең ныклыгы») дигән шигъри әсәренә язган шәрехләмәләр. Аңлатмасында язганча, әлеге эшне кызы Газизә үтенече белән башкарганга, ул аны «Рисаләи Газизә» дип атый.

нәм вә, китапта шундый сүзләр дә була микәнни? — дип, үземә сөаль[1] бирә идем»[2]. Сүз, әлбәттә, шагыйрь Габделҗәббар Кандалыйның (1797–1860) «Сәхибҗәмал» дигән поэмасы хакында бара[3].

Кушлавычта Ситдыйк исемле бер абруйлы кеше аның белән күрешергә килә. Ләкин ул исерек була. Габдулла сәлам дә кайтармый, сузган кулын да алмый. Сәбәбен сорагач, ул «Бәдәвам» китабындагы «Исереккә сәлам бирмә, Ул бирсә һәм син алма...» дигән бәетләр белән җавап бирә, шунда булганнарны гаҗәпкә калдыра.

Менә бервакыт Бәдретдин абзый кайтып төшә. Ул Габдуллага яңа киемнәр алып кайта. Берничә көн торгач, алар Казанга чыгып китәләр. Анда Печән базарына килеп туктагач, кайндыр Мөхәммәтвәли килеп чыга. Г. Тукай көтелмәгән бу очрашуны шулай сурәтли: «Шулвакыт күрдек ки, безгә таба күзләре яшәргән, куллары җәелгән, сакалы агарып бетә язган бер кеше җөгереп килә. Бу минем яныма килгәч тә: «Әле син теремени?! Анаң әле кичә генә сине төшендә күргән иде; әйдә, өйгә алып барыйм; чәй эчәрсең, бездә кунарсың», — дип, мине алып китте»[4]. Бу Бәдри абзыйзыйның рөхсәте белән булгандыр дип уйларга кирәк.

Алар хәзер Иске бистәгә күчеп яши башлаганнар икән. Габдулланы кунак итәләр. Икенче көнне әнисе аны ләгәнгә утыртып юындыра, яхшы кәләпүш, тире чалбар кидерә. Мөхәммәтвәли аны Бәдри абзый төшкән номерга илтеп куя.

«Җаектан мине алырга килүче Алты-биш Сапый[5] дигән кеше әле Казанга китеп җитмәгән икән. Шул сәбәпле, Бәдри абзый белән без бер-ике атна кадәр шул кешене көтеп яттык»[6], — дип, яза Г. Тукай шул көннәрне искә төшереп.

Нигаять Алты-биш Сапый Казанга килеп җитә һәм күрше номерга урнаша. Бәдри абзый Габдулланы шунда күчереп, аңа уникә тиен акча бирә, авылына кайтып китә.

Берничә көннән алар Җаекка юнәлә. «Мине, чыпталы чананың өстен каплап, Алты-биш Сапыйның хатыны[7] алдына утырттылар да һичбер яктан сулыш алырга бирмәделәр. Тик бер-бер авылга чәй эчәргә төшкәч кенә, иркенгә чыгаралар иде»[8], — дип, яза Г. Тукай. Башка юлчыларга кушылып, бергә баралар. Шагыйрь үзе язганча, унсигез көндә Җаекка барып керәләр. Башта Алты-биш Сапый өенә төшәләр, ә кичкә таба аны апасы белән җизнәсенә илтеп куялар.

Димәк, Габдулланың Уральскига килү вакыты 1894 елның ахырына яки 1895 елның башына туры килә.

«Моннан соңгы хәлләре һәм бу вакытларындагы үзе хәтерләмәгән хәлләре хәзергә эшләнмәгән булганлыктан, аның тәрҗемәи хәлене мөфассал[9] рәвештә хати-

---

[1] *Сөаль* — сорау.

[2] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 32.

[3] Фәвакиһәл-җөләса... — Б. 559–579.

[4] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 35.

[5] *Алты-биш Сапый* — Сафиулла Мәҗитов (?–?), Җаек кешесе. Күп сөйләргә яратканга, аны «Алты-биш Сапый» дип атаганнар.

[6] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 36.

[7] *Алты-биш Сапыйның хатыны* — Фатыйма, Г. Госмановның сеңелесе.

[8] Тукаев Г. Исемдә калганнар... — Б. 37.

[9] *Мөфассал* — тулы, җентекле.

раттан вә сәнәдләрдән[1] җыеп эшләнер диеп өмид итәмез»[2], — дип яза 1913 елда ук ук «Кояш» газетасы.

Габдулла Кариев (1886–1920) та «Габдулла әфәнденең Уральскида үткәргән еллары аның мәгыйшәтендә[3] үзенә бер дәвер тәшкил итәдер. Бу дәверне тикшерү вә тәфсилле мәгълүмат бирү — шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен язучылар бурычыдыр... Чөнки бу язган нәрсәләрем, бер тарафтан, шагыйребезне янә бер мәртәбә искә төшерү булса, икенче җәһәттән, киләчәктә аның мөфассал тәрҗемәи хәлен язучыларга бәлки бер материал булыр диеп зан итәмен[4]»[5], — дип яза үзенең истәлегендә.

II

Уральскига килгәч, Габдулла әүвәл Г. Госманов өендә яши, әлбәттә. Аны башта Мотыйгулла Төхфәтуллин (1845–1920) карамагындагы мәдрәсәгә[6] укырга бирәләр. Ул анда Фәтхетдин Рәхмәтуллин[7], Сиражетдин[8] исемле хәлфәләрдән сабак бак тыңлый. Ике-өч елдан соң Мотыйгый хәзрәтнең үзеннән дәрес ала башлый. «Аның бу мәдрәсәсендә тән җәзасы бөтенләй кулланылмый, шәкертләр арасында демократик мөнәсәбәтләр алга сөрелә, алар — мәдрәсә шәкертләре — уку йортының эчке тәртипләрен урнаштыруда үзләре катнаша. Менә шуңа күрә дә, мәдрәсә диварларында кулъязма гәзитә-журналлар чыгуы, аларда шәкертләр тарафыннан язылган, иҗат ителгән парчалар, хикәяләр басылуы табигый бер күренеш булып әверелә»[9]. Хәзрәт тарафыннан алдырылган «Тәрҗеман»[10], «Шәркый рус»[11], «Ва-

---

[1] *Сәнәд* — документ.

[2] Шагыйрь Габдулла Тукаев. Габдулла Тукаевның яшьлек еллары // Кояш. — 1913. — 7 апр.

[3] *Мәгыйшәт* — тормыш итү.

[4] *Зан итү* — уйлау, караш.

[5] Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы / Г. Кариев // Мәктәп. — 1913. — № 4. — Б. 101.

[6] С. Исәнбаев тарафыннан 1966 елда төзелеп бастырылган альбомда урнаштырылган бу мәдрәсәнең фотосы дөреслеккә туры килмәве хакында кара: Ишмөхәммәтов Г. Кечкенә бер истәлек / Г. Ишмөхәммәтов, Н. Вәлиев // Совет мәктәбе. — 1971. — № 1. — Б. 33.

[7] Г. Тукайга җизни тиешле (Галиәсгар Госмановның бертуган сеңелесе Газизәнең ире) бу кеше турында әлегә тулы мәгълүматыбыз юк. Чыгышы белән ул Казан губернасы Чистай өязе (хәзер Татарстан Республикасы Нурлат районы) Күлбай-Мораса авылыннан булган.

[8] Бу кеше турында әлегә мәгълүматыбыз юк.

[9] Төхфәтуллин Х. К. Камил Мотыйгый: Фәнни-популяр очерк / Х. К. Төхфәтуллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. — Б. 5.

[10] *«Тәрҗеман»* — 1885–1918 елларда Бакчасарай шәһәрендә Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914) нашрлегендә һәм мөхәррирлегендә кырымтатар телендә нәшер ителгән әдәби-сәяси һәм гыйльми газета.

[11] *«Шәркый рус»* — 1903 елның апреленнән (1904 елның июненнән көндәлек) 1905 елга кадәр Тифлистә (Тбилисидә) әзәрбәйҗан телендә Мөхәммәд Ага Шахтәхтински (1846–1930) нашрлегендә, Мөхәммәт Колыйзадә мөхәррирлегендә чыккан демократик юнәлештәге газета.

кыт»[1], «Йолдыз»[2] гарәп телендәге «Тәраблис» һәм төрек газеталары белән шәкертләр иркенләп танышып баралар.

Мәдрәсәдә бер үк вакытта Әхмәтшаһ Сираҗетдинов (1850–1919)[3] исемле укытучыда өч ел русча укый. Г. Кариев остазның укучысына карта булган мөнәсәбәтен шулай тасвирлый: «Шуны да әйтеп китәргә кирәк: Габдулла әфәнде Тукаев газеталарда яза башлагач, карт учитель[4] аш мәҗлесләрендә Габдулла әфәнденең ышкылда да вакытындагы зирәклеге хакында: «Хосусан чит телләрне белүгә бик истигъдадлы[5] иде», — дип сөйли иде; Габдулла әфәндегә учительлек иткәнлеге берлә ифтихар[6] кылган сымак сөйләп куя иде»[7].

Мотыйгулла хәзрәт яшь вакытында мәдрәсәдә Габдулланың атасы белән бергә укыган. Бу хакта искә төшереп, ул шулай яза: «Габдулланың атасы Гариф мулла Кышкарда укыганда шәригем[8] улдыгыннан, Габдулланы үзем дә мәхәббәтле күрер идем. Дәрес вакытларында үз алдыма каршы йөзгә-йөз утыра иде. Кайчагында «Мин атаң белән бергә Кышкарда укыган идем, шуның өчен сине яратам» дидегемдә тәбәссем[9] илә көлеп, ак йөзен кызартып, башын аска иеп куя торган иде»[10]. Хәзрәттән шигырь төзелешенең гаруз системасын, поэтик фигуралар (аеруча тәҗнис) ясарга өйрәнә.

Г. Госманов вафат булгач[11], «малы варислар арасында бүленгән булганга»[12] Габдулла яшәргә мәдрәсәгә күчә һәм аның чын-чынлап мөстәкыйль тормышы башлана. Ул анда ун ел гомер кичерә.

---

[1] *«Вакыт»* — Оренбургта алтынчылар һәм эшкуарлар, җәмәгать эшлеклеләре бертуган Мөхәммәдшакир (1857–1914), Мөхәммәдзакир (Дәрдемәнд) (1858–1921) Рәмиевләр наширлегендә һәм язучы, җәмәгать эшлеклесе Фатыйх (Мөхәммәдфатыйх) Кәрими (1870–1937) мөхәррирлегендә 1906–1918 елларда нәшер ителгән көндәлек сәяси һәм әдәби газета. Барлыгы 2308 саны дөнья күргән.

[2] *«Йолдыз»* — 1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр Казанда сәяси эшлекле, журналист, нашир, педагог, тел галиме Һади (Әхмәтһади) Максуди (Максудов) (1868–1941) наширлегендә һәм мөхәррирлегендә нәшер ителгән сәяси, иҗтимагый һәм әдәби газета. Аның идарәсе «Болгар» номерларында була. Барлыгы 1900 саны дөнья күргән.

[3] *Әхмәтшаһ Сираҗетдинов* — чыгышы белән Саратов шәһәреннән, рус теле буенча тирән белеме өчен алтын медаль белән бүләкләнгән.

[4] *Карт учитель* — сүз рус теле укытучысы Әхмәтшаһ Сираҗетдинов турында бара.

[5] *Истигъдад* — сәләтлелек, булдыклылык.

[6] *Ифтихар* — горурлык, мактау.

[7] Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы... — Б. 101.

[8] *Шәригем* — иптәшем.

[9] *Тәбәссем илә* — елмаю белән.

[10] Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Җәмаледдин Вәлиди тарафыннан язылган Тукайның тәрҗемәи хале һәм әшгаре хакында бер мөляхәзә. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе Казанда. — «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1914. — Б. XXIII.

[11] *Г. Госманов вафат булгач* — Галиәсгар Госманов 1900 елның 30 июлендә ашказаны авыруыннан вафат була.

[12] Моради Я. Тукаев Уральскида. Басылды «Г. Гомәрев вә шөрәкясенең» тиҗарәтханәсендә. — Астрахань: Тип. Т-го Д-ма «А. Умеров и Ко», 1913. — Б. 12.

Хәзрәтнең улы Камил[1] 1902 елда Каһирәдән укуын тәмамлап кайткач, Габдулла аңардан гарәп әдәбияты буенча дәресләр ала.

«Габдулла әфәнде мәдрәсәдә вакыт гаять фәкыйрьлек берлә гомер кичерде, — дип яза Г. Кариев. — Аның бар килә торган дахудлары: кыш көне өч бала укытудан, җәй көне хәзрәтнең метрика книгаларын язып алган бер-ике сум акчадан гыйбарәт иде. Хәер инде, картрак шәкертләрне русча да укыткалый иде шикелле. Фәкать бәгъзы бер елларны Гурьевтан аз гына кардәш тиешле[2] — мулламы, йә бер бай бай сәүдәгәрдәнме, киемлекләр, бәгъзән азрак акча да килә иде шикелле»[3].

К. Мотыйгый матбага эшләре оештырып, «гыйльми, әдәби, хикми вә фәнни» «Әлгасрелҗәдит»[4] исемле кулъязма журнал чыгару өчен рөхсәт ала. Анда «Г. Тукайның сатирик хатлары, публицистик мәкаләләре һәм кайбер шигырьләре урнаштырылган. Алар Г. Тукайның беренче әсәрләрен шагыйрь үзе язган хәлендә укырга, моңарчы шулай булырга тиеш дип кенә уйланылган кайбер сүзләрне дөресләргә, Тукай текстларын аныкларга ярдәм итә»[5]. Бу фикер Габдулла белән бергә Уральскида мәдрәсәдә укыган Гали Хикмәтуллин (1883–1984) истәлегендә дә чагылыш тапкан: «Иң ахырдан шул: ник Тукайның кайбер шигырьләрен «төзәтеп» бастырлар икән? Мәсәлән, «Шагыйрь»гә шигыре «Әлгасрелҗәдит»тә: — Бу сүзләрне язып «Әлгасрежәдит»кә, Итәм тәкъдим Нәҗип белән Мәҗиткә», — дигән юллар белән бетә иде[6]. Бу строфаны төшергәннәр. «Өзелгән өмид» шигырендә дә ике юл югалган. Алай итмәскә иде!»[7].

---

[1] *Камил* — Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин (1883–1941), нашир, журналист, җырчы-артист. Аның турында: Төхфәтуллин Х. К. Камил Мотыйгый: Фәнни-популяр очерк / Х. К. Төхфәтуллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. — 80 б.; Вафеев Р. Господин издатель / Р. Вафеев. — Уральск: Полиграфсервис, 2012. — 224 с.; Җиһангирова Г. «Галиҗәнап вә нәзакәтле иде...» (Татарстан Республикасы Милли музее фондларында Камил Мотыйгый архивы материаллары) / Г. Җиһангирова // Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2012. — № 3–4. — Б. 170–176; Исхаков С. М. Мухамед-Камиль Тухватуллин: малоизвестные факты политической биографии / С. М. Исхаков Җиһангирова // Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2025. — № 1 (118). — С. 136–148.

[2] *Кардәш тиешле* — Гурьев байлары Әүхәди (?–?) һәм Әхмәди (?–?) Абдуловлар булып, Әүхәди — Г. Тукайның атасы ягыннан булган әбисе Мәргубә (?–?) абыстайның (Мөхәммәтгалим (?–?) мулланың җәмәгате) бертуганы Мөхәммәди (?–?) улы. Әхмәди (?–?) турында исә әлегә мәгълүматыбыз юк.

[3] Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы... — Б. 101–102.

[4] *«Әлгасрелҗәдит»* — 1904 елдан Уральски шәһәрендә кулъязма рәвешендә таралган, 1906–1907 елларда Камил Мотыйгый наширлегендә һәм мөхәррирлегендә басмада нәшер ителгән әдәби һәм сәяси журнал. Барлыгы 73 саны дөнья күргән.

[5] Гайнуллин М. Татар телендәге беренче әдәби-политик журнал «Әлгасрел-җәдит» / М. Гайнуллин // Совет әдәбияты. — 1961. — № 9. — Б. 146.

[6] Г. Тукай бу шигырен М. Ю. Лермонтовның «Г(-ну) Павлову» (1831) шигыреннән файдаланып язган һәм беренче тапкыр «Әлгасрелҗәдит» журналының 1907 елгы 2 нче санында бастырган. Анда бу ике юл бар. Әмма «Габдулла Тукаев шигырьләре, 3 нче дәфтәр» дигән җыентыкның 1909 елда чыккан икенче басмасында алар төшереп калдырылган. Шагыйрьнең ике томлык «Әсәрләр»енең 1 томында (1953) бу юллар бар. Ә аннан соң нәшер ителгән күптомлыкларда (1 т., 1955, 1 т., 1975, 1 т., 1985. 1 т., 2011) тагын юклар.

[7] Хикмәтуллин Г. Тукай турында исемдә калганнар / Г. Хикмәтуллин // Тукай — ядкяр-

К. Мотыйгый «Уралец» типографиясен сатып алгач, Габдулла мәдрәсәне бөтенләй ташлап, хәреф җыючы булып эшли башлый, шәһәрдәге «Казан» миһманханәсендә[1] бер кечкенә бүлмә алып, Казанга киткәнче шунда тора.

Бу хакта Г. Кариев шулай яза: «1905 нче елның ахырларында «Фикер»[2] газетасы чыга башлагач, Габдулла әфәнде «Фикер» матбагасында бишәр сум вазыйфа[3] алып, ике ай набуршчик булып хезмәт итте. Набуршчик вакытында бәгъзы бер нәрсәләрне үзлегеннән төзәтә башлагач, Камил әфәнде аңар 10 сум жалунйә биреп, мөсәххих[4] итеп куйды. Мөсәххих булып торган вакытында «Фикер»гә шигырьләр һәм мәкаләләр яза башлады. Тукаевның иң беренче басылган шигыре «Мужик йокысы»[5] булды»[6].

Г. Тукай «Мөхәррирgә» исемле шигырен язгач, К. Мотыйгый аның хезмәт хакын егерме сум ясый. Ләкин, «Фикер» газетасы чыгудан туктый. Матбаганы Мортаза Гобәйдуллин сатып ала[7]. Берникадәр вакыттан соң ул газетаны чыгару белән шөгыльләнми башлый. Шуннан соң Г. Тукай «Матбага берлә уйнаган бер байга» дигән шигырен яза.

1902–1903 елларда Габдулла укыган мәдрәсәгә Истанбулдан Габделвәли Әмруллаһ (?–?)[8] исемле бер шәкерт килә. Ул аңардан төрек әсәрләре турында шактый мәгълүмат ала. Еллар үткәч, бу турыда журналист, театр һәм әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче Габдерахман Кәрам (1878–1947) аның сөйләгәннәрен шулай искә ала: «Төрек әдибе ул минем остазым, — дип атый, — ул минем дөньяга карашымны киңәйтте, фикеремне ачты», — дип сөйли торган иде. Шуның тәэсире астында булса кирәк, ул башта әсәрләрен дә төрекчәрәк яза иде»[9]. Шул ук вакытта рус әдәбиятын-

---

ләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 219–220.

[1] *«Казан» миһманханәсе* — Уральски шәһәре бае Мортаза Гобәйдуллин (?–?) 1905 елда ача. Аңа кадәр ул «Коммерческий клуб» (халык телендә аталышы «Каружный клуб») булган.

[2] К. Мотыйгый наширлегендә һәм мөхәррирлегендә әдәби һәм сәяси «Фикер» газетасының беренче саны 1905 елның 26 ноябрендә нәшер ителә.

[3] *Вазифа* — хезмәт хакы.

[4] *Мөсәххих* — корректор.

[5] Рус шагыйре А. В. Кольцовның (1809–1842) «...Что ты спишь, мужичок?» дигән сүзләр белән башланган исемсез шигыреннән (1839) файдаланып язылган.

[6] Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы... — Б. 103–104.

[7] 1907 елның февралендә, губернатор фәрманы белән, К. Мотыйгыйдан наширлек һәм мөхәррирлек хокуклары алына. Шул вакытта миллионер Мортаза Гобәйдуллин (?–?) типографияне һәм «Тәрәккый» нәшриятен бөтен газета-журналлары белән арендага алырга ризалыгын әйтеп тәкъдим ясый. Яңа мөхәррир итеп Вәлиулла Хәмидуллин (?–?) билгеләнә. Озакламый, бу эшнең чыгымы бик зур, дигән сылтау белән, басмаларны чыгару туктатыла. «Фикер» газетасының соңгы саны 1907 елның 13 маенда чыга.

[8] *Габделвәли Әмруллаһ (?–?)* — Истанбул университетында укыган вакытта солтанга каршы хилаф хәрәкәтләрдә катнашканы өчен эзәрлекләүләрдән качып Россиягә чыга һәм Уральски шәһәренә килеп юлыга. Анда ул Г. Тукай белән таныша һәм алар бик нык дуслашып китәләр. Иранда ихтилал башлангач, шунда китә.

[9] Кәрам Г. Тукай турында исемдә калганнар / Г. Кәрам // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда /

нан һәм А. С. Пушкинның (1799–1837) һәм М. Ю. Лермонтов (1814–1841) әсәрләрен укый.

Шул вакытларда Казаннан «Матбагаи Шәрәф»[1] хуҗаларыннан Г. Тукайга аның «Фикер»дә, «Әлгасрелҗәдит»тә басылган шигырьләрен мәҗмуга[2] рәвешендә бастырырга сорап, хат язалар.

Оренбургтагы «Вакыт» газетасы идарәсеннән дә Г. Тукайны эшкә чакырып хат килә[3].

Г. Тукай шәһәрдә уздырылган төрле мәдәни чараларда да катнаша. Мәсәлән, бер кыш көне «Казан» миһманханәсендә русларның ниндидер бер кичәсе була. Ул Хәкимҗан[4] исемле берәү белән хәерче киемнәре киеп, үзе аңа карап «Теләнче» исемле шигырен укый.

К. Мотыйгый Уральскида «Яңа тормыш»[5] исемле газета чыгаруны оештыру эшләре белән шөгыльләнә башлый. Пайчылары күрсәтелгән (Г. Тукаев — 100 сум) шартнамәнең[6] 1907 елның 20 июлендә төзелүенә нигезләнеп, профессор И. Нуруллин шулай яза: «Димәк, 1907 елның июль ахырында әле Тукайда Казанга бөтенләйгә күчеп китү (дөресрәге, әйләнеп кайту) фикере урнашып җитмәгән. Ул гына да

Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 399.

[1] *«Матбагаи Шәрәф»* — бертуган Шәһеретдин (1877–1938), Борһан (1883–1942), Гыйльметдин (1885–1942) Шәрәфләр 1906 елда «Матбагаи Шәрәф» дигән типография ачалар һәм ул төрле исемнәр астында һәм төрле кешеләр җаваплылыгында, чынлыкта исә Г. Шәрәф җитәкчелегендә, 1918 елга кадәр эшли.

[2] *Мәҗмуга* — җыентык.

[3] Бу вакыйганы Оренбург сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, иганәче Әхмәт Хөсәенев (1837–1906) тарафыннан тәрбиягә алып үстерелгән һәм соңыннан Казанда 1908 ел башында «Китап» исемле ширкәт төзегән Габдерахман Дәүләтшин (?–?) да белгән булса кирәк. Чөнки шагыйрь шул ук елның 9 июнендә аңа юллаган хатында болай яза: «Ошбу көннәрдә Оренбургка хат яздым. Анда барсам, баргач та акчаңызны йибәрермен...». Күренгәнчә, Г. Тукай ул чакыруга башта уңай җавап биргәнгә охшый. Әмма ул вакытларда Серноводскийда дәваланучы дусты язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе Фатыйх Әмирханга (1886–1926) 23 июньдә язган хатында исә бу хосуста киңәш бирүен үтенә: «...Оренбургка Фатыйх Кәримев чакырган иде. Анда барсам, бәлки, үземә мөгайян эш булуы һәм серьезный кешеләр тирәсе файдалы булыр иде, дим. Нишлим? Барыйм микән? Монда «Әл-ислах» ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем. Ләкин бу да бәгыйд. Шушы минем кайгым тугърысында бер-ике юл языңыз әле...». Ф. Әмирхан хатны алган, әлбәттә. Бу хакта ул «Авырулар галәмендә» дигән язмасында телгә ала. Ничек кенә булмасын, һәрхәлдә, Г. Тукай Оренбургка бармый һәм аңа аннан башка чакыру да килми.

[4] *Хәкимҗан* — язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Мәһдиевнең (1903–1995) мәгълүматына күрә, Хәкимҗан Йосыпов чыгышы белән хәзерге Татарстан Республикасы Арча районы Иске Кишет авылыннан.

[5] *«Яңа тормыш»* — «Фикер» газетасының дәвамы буларак, 1907 елның ноябреннән 1908 елның мартына кадәр Уральск шәһәрендә татар телендә нәшер ителгән атналык газета. Мөхәррире Мөхәммәтгали Мусин була.

[6] Аның факсимилесен кара: Гайнуллин М. Татар телендәге беренче әдәби-политик журнал «Әлгасрел-җәдит»... — Б. 150.

түгел, «Яңа тормыш» газетасы чыга башласа, солдатка каралгач, (әгәр алынмаса), яңадан әйләнеп кайтырга да нияте булган»[1]. Ләкин «өзелеп сагынып та, Казанга кайта алмый йөдәгән, әмма күңеле белән мең мәртәбә кайткан шагыйрь тойгыларының гәүдәләнеше»[2] инде аның «Пар ат»[3] шигырендә ачык чагылыш таба.

Г. Тукай 1907 елның 30 декабрендә Казаннан Уральскига Г. Кариевка язган хатында үзенең шатлыклы тойгыларын шулай белдерә: «Мин хәзер Казанда инде. Уральскида вакытта шуны сөйли-сөйли авыз суларым кибеп бетдеге вә шунда бару хакында шигырьләр («Пар ат» — *Р. И.*) яздыкым Казанда инде»[4].

Шул ук вакытта үзе пай керткән «Яңа тормыш» газетасын да сарказм белән искә алып, шулай яза: «Әйе, Уральскидә берничә сабый балалар тарафыннан надан вә җаһиланә чыгарылган «Яңа тормыш» монда килеп тора. Мәрхүмнәр! — дим дә куям»[5].

Шагыйрьнең Җаектагы дусты, соңыннан приказчик булып эшләгән Рәхмәтулла Хәйруллин (?–?) «Тукайның Казанга кайтырга акчасы юк иде. Без, приказчиклар — мин, Габделгани Гобәев, Григорий Трофимович Курушкин, Хикмәтҗан Бариев һәм Габдулла Исхаковлар — үзара акча җыйнап, Тукайны Казанга озаттык»[6], — дип, яза. Г. Кариев истәлегендә башка төрле мәгълүмат укыйбыз: «Аның кайтырга акчасы юк иде. Аңа атасыннанмы, белмим кемнәндер, 100 сумнар чамасы мирас калган икән, шуны бер писарь берлә хлапатать итеп, Казанга килер алдыннан алып, шул акча[7] берлә үзенең сөйгән Казанына килде».

III

Г. Тукай Уральскида шагыйрь, публицист, журналист булып җитешә. Аның исеме Россиянең башка төбәкләрендә дә шактый ук таныла башлый. Мәсәлән, 1906 елда «Таң йолдызы»[8] газетасы мөхәррире булган Сәгыйть Рәмиев (1880–1926): «Бик исемдә, «Царь-голод» тәрҗемәсен[9] безгә Габдулла Тукаев дигән кеше йибәргән

---

[1] Нуруллин И. Туган якларга таба... / И. Нуруллин // Соц. Татарстан. — 1975. — 25 апр.

[2] Нуруллин И. Туган якларга таба...

[3] Тукаев Г. Пар ат // Фикер. — 1907. — 6 май.

[4] Габдулла Кариевкә // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 81.

[5] Габдулла Кариевкә... — Б. 81.

[6] Рәхмәтулла Хәйрулла улы Хәйруллинның Габдулла Тукай турында истәлекләре // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 133.

[7] Бәлки, ул үзендә булган шул 100 сумны «Яңа тормыш» дигән газета чыгару өчен пайчы буларак тапшыргандыр.

[8] *«Таң йолдызы»* — татар эсерлары — «Таңчылар» оешмасы органы. 1906 елның 18 маеннан 16 ноябренә кадәр Казанда татар телендә атнага 2–3 тапкыр нәшер ителә, барысы 65 саны дөнья күрә. Нашире — Г. Пүтиләков, аннары — Ф. Туктаров, 19 июньнән С. Рәмиев, фактик мөхәррире — Г. Исхакый (1878–1954).

[9] *«Царь-голод» тәрҗемәсен...* — академик А. Н. Бахның (1857–1946) «Царь-голод. Экономические очерки» (1883) исемле китабының тәрҗемәсе.

иде. Һәм ул безгә шигырьләр дә яза, шигырьләрен газетамызга без бик яратып дәреҗ итә[1] идек»[2].

Уральскида нәшер ителә торган татарча басмаларны даими рәвештә күзәтеп барган Галиәсгар Камал (1879–1933) шулай яза.: «Ул чакларда яңа темаларда, бик саф булмаса да, татарча язылган шигырьләр булмаганлыктан, Тукайның шигырьләре бик тиз күзгә бәрелде. Мин шул килгән газет һәм журналлардан Тукайның язган шигырьләрен эзәрләп барып, укый башладым»[3].

Танылган язучы, драматург, тәнкыйтьче Фатих Әмирхан (1886–1926) аның белән беренче тапкыр күрешкәндә: «Бу фамилия миңа «Әлгасрелҗәдит» журналында чыккан кайбер шигырьләре аркылы таныш иде»[4], — ди.

Нашир, «Матбагаи Шәрәф» типографиясен оештыручыларның берсе һәм аның җитәкчесе Гыйльметдин Шәрәф (1885–1942) шагыйрь белән 1907 елда хат аша танышуын яза: «Без шигырьләрене кабул итәмез. Бу көндә «Беренче, икенче «Тукаев шигырьләре»[5] исемендә йөри торган шигырьләрене безгә йибәрә. Мәҗмугаларын йибәреп, берәр ай чамасы үткәч (5 июль, 1907 нче сәнәдә), Габдулла әфәнде безгә «Шүрәле» шигырен йибәрә һәм хатында: «Тарафыңызга тагы да «Шүрәле» вә «Тәрбиятел әтфаль»гә сәрләүхәле[6] шигырьләремне күндерәм. Шуларны «Китмибез!» вә «Бездә истигъдад[7] бар»[8] шигырьләре белән бергә рисаләнең[9] башына куярсыз. «Кечкенә генә бер көйле хикәя» (бу әсәр тиздән матбугатыбызда чыкса кирәк) сәрләүхәле шигырь басылмый калса да зарар итмәс зан итәм[10]», — дип яза. (Буңа караганда «Шүрәле»не шагыйрь 1907 нче сәнә, июньнәрдә язган була.)»[11].

Татар теле һәм әдәбияты галиме, педагог, тарихчы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Җәмал Вәлиди (1887–1932) «Габдулла әфәндене мин элек «Нур»[12] да күрдем.

---

[1] *Дәреҗ итә* — бастыра.

[2] Рәмиев С. Икенче апрель көне / С. Рәмиев // Ил. — 1914. — 2 апр.

[3] Камал Г. Габудлла Тукай турында истәлек // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 295.

[4] Әмирхан Ф. Тукай тугрысында искә төшкәннәр / Ф. Әмирхан // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 225.

[5] *«Беренче, икенче «Тукаев шигырьләре»...* — «Г. Тукаев шигырьләре» исеме белән чыккан ике җыентык. Беренчесе «Шигырьләр көтепханәсе»ннән «3 нче дәфтәр» (1907, ноябрь), икенчесе «4 нче дәфтәр» (1908, январь) дип билгеләнгән.

[6] *Сәрләүхәле* — исемле.

[7] *Истигъдад* — булдыклылык.

[8] Г. Тукайның «Юаныч» дигән шигыре күздә тотыла.

[9] *Рисаләнең* — әсәрнең.

[10] *Зан итәм* — уйлыйм.

[11] Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар / Г. Шәрәф // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 265–266.

[12] *«Нур»* — 1905–1914 елларда Петербургта башта Гатаулла Баязитов (1846–1911), 1911 елдан аның улы Сафа (Мөхәммәтсафа) Баязитов (1885–1937 елдан соң) тарафыннан нәшер ителгән әдәбият һәм мәгариф, дөнья яңалыкларын һәм заман ихтыяҗларын яктырткан газе-

Ләкин аның чынлап танылуы «Әлгасрелҗәдит» иләдер. Аның «Әлгасрелҗәдит»тә чыккан элек шигырьләре укымыш вә уйганмыш халкымызның чын шагыйрьдән көттеге бер тарыз[1] тәфәккер[2] вә ифадә[3] иде»[4], — дип яза.

Г. Тукай Казанга 1907 елның көзендә кайта. Кызганыч ки, пароходта угрылар аның юл кәрзинен урлыйлар. Ул иң әүвәл «Болгар»[5] номерларында урнашкан «Йолдыз» газетасы редакциясенә килә. Шунда Г. Камал белән күрешә, аның хөрмәтенә кичке аш мәҗлесе оештырыла. Икенче көнне номерлар хуҗасы белән сөйләшеп, айлыгы тугыз сумга 40 нчы бүлмәне аның өчен алып куялар.

Г. Тукайның Казанга кайту хәбәре тиз арада шәһәргә таралып өлгерә. Аның белән күрешергә китапчылар, әдипләр, яшьләр редакциягә килә башлый.

Сентябрь ахырларында солдатка каралу өчен туган ягына кайтып китә. Ул «Олы Мәнгәрдә урнашып, берничә көн тора. Авыл ул вакытта волость үзәге була, ләкин хәрби-медицина комиссиясен яшьләр Олы Әтнәдә үткәннәр. Олы Мәнгәрдә Г. Тукай Хәкимов Вәли (Чәпәли Вәлие) (?–?) йортына төшә. Бу очраклы хәл булмый, чөнки Вәлинең анасы Мәчтүрә апа элек тә вак-төяк сату эшләре белән Уральск шәһәренә барып йөри торган булган. Аларның Тукай белән танышлыгы Уральск шәһәрендә үк башланган»[6].

Шул елның ноябрь айларында чыга башлаган «Әхбар»[7] газетасына хезмәттәшлек итәргә Г. Тукайны да чакыралар. Башта риза булса да, башка эшкә керүен сәбәп итеп, аннан баш тарта. Чөнки ул шул вакытта Габдерахман Дәүләтшин (?–?) тарафыннан гамәлгә куелган «Китап»[8] исемендә нәшриятка экспедитор[1] булып эшли

та. Сүз Г. Тукайның бу газетаның 1905 елгы 6 декабрь санында басылган «Шималь яктан чыгып бәркъ, орды бер нур» дигән юл белән башланган шигыре турында бара.

[1] *Тарыз* — рәвеш, ысул, тәртип.

[2] *Тәфәккер* — фикерләү.

[3] *Ифадә* — аңлату.

[4] Җәләй. Габдулла Тукаев // Вакыт. — 1913. — 6 апр.

[5] *«Болгар»* — Казанда Евангелистлар һәм Мәскәү (хәзерге Татарстан һәм Мәскәү) урамнары чатында кунакханә (№ 17/59). П. П. Романов проекты буенча 1866 елда беренче гильдия сәүдәгәре, нәселдән шәрәфле гражданин Ибраһим Аппаков (1821–1885) табыш китерү йорты буларак төзеттерә. Аны 1897 елда Әхмәт Хөсәенов (1837–1906) И. Апаковның кызы Бибимәрьямбанудан (1866–?) сатып ала. 1906 елда сәүдәгәр Фәтхулла Әхмәдуллин (?–?) аның бер өлешен арендалап, кунакханә ача. 1907 елда Мөхәммәтрәхим Казаков (1874–1937) аңардан кунакханәне сатып ала. 1910 елның 1 декабреннән «Болгар» номерлары бертуган Мөхәммәтша (?–?) һәм Гарәпша (?–?) Рамазановлар идарәсенә күчә. Г. Тукай анда (төрле бүлмәләрдә, соңгысы 40 нчы), башка урыннарда торып алгалаганын исәпләмәгәндә, 1907 елның көзеннән 1912 елың 12 нче декабренә кадәр яши. Кунакханә 2008 елның 28 сентябрендә тулысынча сүттерелеп, урынына шуңа охшашлы бина корылды.

[6] Әхмәтҗанов М. Шагыйрь эзләре / М. Әхмәтҗанов // Соц. Татарстан. — 1974. — 26 апр.

[7] *«Әхбар»* — Харис Фәйзи (1870–1933), журналист, әдәби тәнкыйтьче Борһан Шәрәф (1883–1942) наширлегендә һәм мөхәррирлегендә 1907–1908 елларда Казанда нәшер ителгән сәяси, әдәби, тиҗари татарча газета. Аның идарәсе «Болгар» номерларында урнашкан була. Барлыгы 85 саны дөнья күргән.

[8] *«Китап»* — Габдерахман Дәүләтшин (?–?) җитәкчелегендә Казанда 1908 ел башында оештырылган китап бастыру һәм сату ширкәте. Г. Дәүләтшин «Хөсәения» мәдрәсәсендә рус

башлый. Әүвәл нәшрият конторасы урнашкан «Московский номерлар»га[2], бер айдан соң «Уральский подворье»га[3] күчә һәм шул контора бүлмәсендә яши. Нәшер ителә торган материалларның корректураларын карый, китапларны әзерләп, посылкаларны тегеп почтага илтә, Казанда китап белән сәүдә итүчеләргә илтеп тапшыра.

«Китап» нәшрияты 1908 елның көзендә эштән туктагач, Г. Тукай янә «Болгар» номерларына күчә.

1908 елның август башында «Яшен»[4] журналы нәшер ителә башлый. Г. Тукай аның беренче саныннан ахыргысына кадәр актив язышучыларның берсе була.

Шул вакытларда Казандагы Никитин циркында[5] көрәшүчеләр арасында төрек милләтеннән булган Карәхмәт (?–?) исемле бер пәһлеванның батырларны җиңеп, Печән базары халкын шаулату вакыйгасы Г. Тукайга «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш»[6] исемле күләмле әсәрен язарга этәргеч бирә.

Г. Тукай «Шәрекъ клубы»[7] белән дә тыгыз хезмәттәшлек итә. Анда 1910 елның 15 апрелендә «Халык әдәбияты» дигән лекция укый. Бу хакта шагыйрь үзе болай аңлата: «Көннәрдә бер көн бер иптәшемә уйнап кына: «Мин халык әдәбияты тугрысында лекция укыйм», — дип әйткән идем. Ул, шуңар ышанып, Тукаев лекция укыячак икән дип, мөгътәбәр гәзитәләрнең берсенә язып та өлгергән». Дөрестән дә, «Йолдыз» газетасының 1910 елгы 8 апрель санында: «Лекция. Ошбу тиз арада «Шәрекъ клубы» залында Габдулла әфәнде Тукаев халык әдәбияты тугрысында лекция укыячак» дигән белдерү басылып чыга.

Әлеге вакыйганың шаһите булган, «Шәрекъ клубы»ның халык уен кораллары оркестрында мандолинада уйнаган, Җәлал Мәҗитов (?–?) бу хакта болай искә ала:

теле һәм әдәбиятын укыткан, аның Д. Таждаров псевдонимы белән «Яшь хатын» дигән драма язуы да билгеле.

[1] Бу хакта ул Уральскидагы апасы Газизә Госмановага Казаннан 1908 елның 27 мартта язган хатында болай ди: «Без хәзер Әхмәт байның угылы илә бергә «Китап» нәшрияты исемле бер ширкәт ясадык... 40 тәңкә айга жалуние бирәләр».

[2] *«Московский номерлар»* — «Апанаевское подворье» буларак кунакханә тибындагы өч катлы кирпеч бина XX гасыр башында беренче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтйосыф Апанаев (1833–1903) тарафыннан төзеттерелгән. Аның вафатыннан соң улы Габдулла (1873–1937) карамагына күчә. Урнашкан урам исеменә нисбәтле ул мосафирханә шулай аталып йөртелгән.

[3] *«Уральские подворье»* — дөресе «Казанское подворье» аталышында Мәскәү урамында, Печән базары тирәсендәге Рамазановларның берничә арзанлы номерлары.

[4] *«Яшен»* — Казанда драматург, татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучыларның берсе Галиәсгар Камал (1879–1933) наширлегендә һәм мөхәррирлегендә 1908–1909 елларда 15 көндә бер тапкыр нәшер ителгән сатирик журнал. Барлыгы ун саны дөнья күргән.

[5] *Никитин циркы* — рус цирк артистлары һәм цирк хуҗалары бертуган Дмитрий (1835–1918), Аким (1843–1917), Петр (1846–1921) Александрович Никитиннар үз акчаларына Мунча күле урынына төзеттерелгән агач биналы цирк рәсми рәвештә 1890 елның 20 маенда ачылган. Татарлар аны *«Микитин»*, ә циркны *«ат кәмите»* дип йөрткәннәр.

[6] Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш. 7 нче дәфтәр. Габдулла Тукаев асәре. — Лито-типогр. И. Н. Харитонова Казань, собст. дом, 1908. — 22 б.

[7] Аның тарихы турында: Миңнуллин Ж. Шәрык клубы: тарихи очерк / Ж. Миңнуллин. — Татар. кит. нәшр., 2013. — 95 б.

«Йомшак кына аваз белән җылы гына җөмләләр белән башланган бу лекция бара-бара эзгә төшә һәм Г. Тукай үзе дә (су коеныр алдыннан чиркәнеч алган кеше кебек) иркенләп сулу ала һәм сөйли торган сүзен киңәйткәннән-киңәйтә бара. Халык лекцияне бик яратып тыңлый һәм ахырында лекциядән бик риза булып таралалар»[1].

Татар теле һәм фольклор галиме Хуҗа Бәдигый (1887–1940) шулай ук бу лекцияне тыңлаган кешеләрнең берсе. Хосусан, ул үзенең истәлегендә: «Халык шыгрым тулы иде. Теоретик материал күп булмаса да, лекция миңа бик ошады, Тукай үзенең лекциясендә, хәзерге күзлектән караганда да, халык әдәбиятының (фольклорның) эчтәлеген яхшы ук дөрес билгеләп бирде»[2], — дип яза.

Бу лекция шул ук елда Казанда «Сабах» көтепханәсе тарафыннан И. Н. Харитонов (1859–1927) матбагасында аерым китап итеп нәшер ителә[3], икенче басмасы 1912 елда дөнья күрә. Аннан соң ул Ж. Вәлиди тарафыннан төзеп, 1914 елда Казанда «Мәгариф»[4] көтепханәсе басмасында нәшер ителгән «Габдулла Тукай мәҗмугаи гаи асаре» дигән китапта урнаштырыла, шагыйрь «Әсәрләр»енең күптомлыкларына кертелә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә Г. Тукай фондында әнә шул лекцияне тыңларга керү өчен билет саклана[5]. Аны шагыйрьнең замандашы Габделбарый Рәхмәтуллин (1887–1972)[6] исемле кеше 1956 елда Институтка тапшырган.

Г. Рәхмәтуллинның «Шәрекъ клубы»на мәгълүм лекцияне тыңларга баруы очраклы гына булганга охшамый. Чөнки ул үзе дә каләм тибрәткән, аның кайбер шигырьләре «Ялт-Йолт»[7] журналы, «Йолдыз» газетасында дөнья күргән. Димәк, ул Казанның шул чордагы әдәби-мәдәни тормышында турыдан-туры катнашып яшәгән.

---

[1] Габдулла Тукай турында Җәлал Мәҗитов истәлекләре // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 459.

[2] Бәдигый Х. Бөек халык шагыйре Г. Тукай турында исемдә калганнар / Х. Бәдигый // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 313.

[3] Тукаев Г. Халык әдәбияты. Нашире: «Сабах» көтепханәсе / Г. Тукаев. — Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1910. — 43 б.

[4] *«Мәгариф»* — бертуган Шәрәфләрнең шул исемдәге китап белән сәүдә итү ширкәте нигезендә Казанда 1906 елда оештырылган «Камалетдинов вә шөрякәсе» дигән нәшрият һәм китап сәүдәсе ширкәте. Башлаучысы — Галиәсгар Камал, иптәшләре — Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиев (1873–1941), Мөхәммәтәмин Мостафин (?–?), Мөхәммәтрәхим Хәнәфи (?–?), һәм башкалар. 1907 елның 22 июнендә аның җитәкчесе итеп М. М. Мостафинны сайлыйлар.

[5] Беренче тапкыр матбугатта безнең тарафтан игълан ителде: Исламов Р. Лекциягә билет. Ул нинди сер саклый? / Р. Исламов // Кызыл таң. — 2011. — 26 нояб.

[6] Аның турында тулырак: Исламов Р. Ул Тукай лекциясен тыңлаган / Р. Исламов // Мәдәни җомга. — 2014. — 11 июнь.

[7] *«Ялт-йолт»* — 1910–1918 елларда Казанда нашире һәм мөхәррире Әхмәт (Әхмәтзәки) Урманчиев (1889–1922) булган, 15 көндә бер чыга торган әдәби, фәнни һәм сәяси журнал. Аның идарәсе «Болгар» номерларында урнашкан була. Барлыгы 123 саны дөнья күргән.

Билетның үзенә килгәндә исә, анда гарәп хәрефләрендә типография ысулы белән мондый сүзләр бастырылган: «Билет номер 36. «Шәрекъ клубы»на лекция тыңларга керү өчен. 10 тиен».

Әлеге лекциянең, күрәсең, «Шәрекъ клубы»нда үткәрелгән башка мәдәни чаралар кебек үк, түләүле булу турында «Йолдыз» газетасының 1910 елгы 15 апрель санында басылган тагын бер игъланда күрергә мөмкин: «Бүген, пәнҗешәмбе, 15 апрель, кич 9 сәгатьтә «Шәрекъ клубы»нда Габдулла әфәнде Тукаев халык әдәбияты турында лекция укыячак. Билет бәясе 30 тиеннән 15 тиенгә кадәр».

Шәрекъ клубында шагыйрь элегрәк тә чыгышлар ясаганлыгы билгеле. Мәсәлән, Дәүләт Сафинның (?–?) истәлегендә шундый мәгълүмат табарга мөмкин: «1908 елда «Шәрекъ клубы»нда бер кичәдә шагыйрьнең «Безне урынсыз яманлыйлар» исемле шигырен укыячагы игълан ителде. «Мөхәммәдия» шәкертләренең байтагысы минем белән монда бар иде. Халык шагыйрьнең чыгышын түземсезлек белән көтеп алды. Номерларны әйтеп торучы Г. Тукай номерын әйткәннең соңында да, шагыйрь кыюсызлыгыннан булырга кирәк, кыстатып кына чыкты. Язылган шигырьне кулына тоткан килеш ярым күңелдән, ярым карап шактый көчле тавыш белән укыды»[1].

Шул вакытларда Казан мәдрәсәләренең берсендә география фәне укыткан, булачак педагог һәм тел галиме Закир Шакиров та (1881–1968) үзенең истәлегендә: «Кабан күленә каршы бинада, «Шәрекъ» клубында, Тукайның халык әдәбияты турында лекциясе булды»[2], — дип, бинаның төгәл урынын күрсәтә.

Аңлашылганча, Г. Тукай үзенең мәгълүм лекциясен, күп чыганакларда ялгыш язылганча, «Шәрекъ клубы»ның Евангелистовский (хәзер Татарстан урамы, 8 йорт) урамындагы бинасында түгел, ә Кабан күле буендагы Х. Сабитов өендә урнашкан вакытта укыган.

Димәк, әлеге билет халык шагыйренең тормыш юлын һәм аның әдәби эшчәнлеген өйрәнүдә өстәмә кыйммәтле документларның берсе булып тора.

IV

Истәлекләрдән күренгәнчә, Г. Тукай Уральскида яшәгәндә үк төрле төбәкләргә баргалаган. Мәсәлән, хәзерге Оренбург өлкәсе, Бурaнный районы, Линевка авылында татар теле укытучысы Зәкәрия Әхмәрев (?–?) 1953 елның 12 мартында язучы Әхмәт Фәйзигә (1903–1958) юллаган хатында булачак шагыйрьнең җәй көне Самышев Зәйнулла (?–?) исемле сабакташы белән кунакка кайтып йөрүен хәбәр итә. Алай гына да түгел, алар анда бергәләп фотога да төшкәннәр.

К. Хисаметдинов истәлегеннән күренгәнчә, алар бергәләп Дәвана, Льбищин якларында унбиш көн йөреп кайткannар[3].

---

[1] Сафин Д. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай турында минем истәлекләр / Д. Сафин // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 405.

[2] Шакиров З. Мин география укытканда / З. Шакиров // Тукай Башкортостанда / Төз., баш һүз, аңл. С. Сафуанов. — Өфө: Башкорт. кит. нәшр., 1966. — Б. 35.

[3] Хисаметдинов К. Күрс. хезм. — Б. 185–187.

Г. Тукай Уральскидан Казанга күченеп кайткач яшәгән дәверендә берничә тапкыр сәфәрдә булып ала. Аерым алганда, ул 1908 елда Г. Камал белән Мәкәржә[1] ярминкәсенә бара. Алар анда Тимерша Соловьевның (1875–1947) «Двухсветная» кунакханәсендә яшиләр. Г. Кариев үзенең истәлегендә шулай яза: «Шулай йөри торгач, беркөнне «Двухсветная» хуҗасы Тимерша әфәнде Соловьев (белмим, ни өчендер) бездән, кечкенә генә пианина куяр өчен ясаган сәхнәсенә чыгып, төрле милли шигырьләр укуымызны үтенде. Без, яшь күңелләр, һич игътиразсыз[2] (мәрхүм шагыйремез Тукай да шунда) аның сүзен кабул итеп, мәгълүм сәхнәгә менеп, «Бәхилләшү» шигырене: «Караңгы икән көнемез, күрмәс икән күземез», — дип вә башка шундый күңел уйгата торган шигырьләрне кайсын «Беренче сада», бәгъзысын «Икенче сада»[3] көенә (ул вакытларда садалар мудада иде) җырлап төштек. Пәрәмәч ашаучы агай-энеләр безнең җырлавымызны бик яратып, кайсы: «Афәрин! Яшәңез!» — дигән тавыш вә алкышлар берлә безне каршы алдылар. Кунакларның безнең җырлавымызны шулкадәр яратып кул чабуларына Тимерша әфәнденең үзенең дә бик кәефе килгән иде. Ул, безнең янга килеп, барымызның да кулларымызны кысып, рәхмәт укып чыкты һәм барымызны да бер бүлмәгә алып кереп, пилмән берлә безне кунак итте. Ул һаман безнең җырлавымызны әллә нинди бер байның да хушына киткәнен сөйләп, безнең күңелне күтәрә һәм моннан берничә еллар мөкаддәм[4] Галиәсгар әфәнде Камал җәнапләренең дә шул ук без җырлаган сәхнәдә әллә нинди халык җырлары җырлаганын, аны әллә нинди көлкеләр берлә болгатып, безнең кәефне табарга тырыша иде.

Тимерша әфәнде, безнең «Двухсветная»да җырлаганымызны белсеннәр өчен, парадный тәрәзәсенә: «Милли шигырьләр укыла, халык җырлары җырлана» дип, бер кечкенә генә плакат та элеп куйды. Безнең эшләр шәбәйде. Икенче көнне инде ул безнең барымыз өчен дә алты данә кызыл, бер данә зәңгәр фәсләр алдырган иде...

...Габдулла әфәнде Тукай, җырлаган вакытта, безнең алда халыкка арты, безгә алды берлә, капельмейстер[5] шикелле, куллары берлә болгап торадыр иде... Шулай эшләр яхшы гына барганда, гөнаһ шомлыгына каршы, әллә кайдан бер гармунчы мишәр[6] килеп чыкты.

---

[1] *Мәкәржә* — Түбән Новгород шәһәре янындагы Макарьевода ел саен июль-август айларында үткәрелә торган ярминкә. XVI гасыр урталарында Иделнең сулъяк ярындагы Макарьев монастыре (хәзерге Түбән Новгород өлкәсе, Лысково районы, Макарьево поселогы) янында барлыкка килгән, 1819 елда Түбән Новгород каршындагы үзәнлеккә күчерелгән. Анда Россиянең барлык шәһәрләреннән дә диярлек һәм чит илләрдән сәүдәгәрләр үзләренең товарлары белән сату иткәннәр. Мәкәржә ярминкәсе Октябрь түнтәрелешеннән соң да бераз эшли һәм 1929 елда бөтенләй туктатыла.

[2] *Игътиразсыз* — бәхәссез, каршылыксыз.

[3] *Сада* — аваз, тавыш.

[4] *Мөкаәддәм* — элек, борын.

[5] *Капельмейстер* — дирижер.

[6] Сүз Мирфәйз Бабажанов (1867–1943) турында бара.

Ул гармунчы мишәр дә Тукайның капельмейстерлыгы тәхетендә без җырлаган сәхнәгә менеп, гармунны әйттерә, үзе уйнаганда, хатыннар тавышы берлә[1] мишәрчә әллә нинди урам җырлары җырлый башлады. Бу мишәрнең һөнәре халыкка тагы да охшады булырга кирәк: халык шатлыгыннан урынында тора алмыйча, төрлечә үзенең шатланганын изһар итәргә[2] тотынды. Ни эшләргә белми, кул чабулар кирәкме, урындыклар белән дөбердәтүләр кирәкме, хасыйл[3], бөтен «Двухсветная» ду куба иде. Бу мишәр гармунчы безгә караганда ун өлеш артык муаффәкыять[4] казанды...

Бу гармунчыны халык шулкадәр яраткач, Тимерша әфәнде дә аны Мәкәржә буена җырларга алды...

Шуннан берничә еллар үткәч, мин Тукайдан Мәкәржәдә капельмейстер булып куллар болгатуының мәгънәсен сорый идем. Ул аңар бер борчылып, бер кызарып: «Калдыр әле шуларны», — дип, сүзне тиз генә икенчегә бора иде.

Мәрхүм Тукайның Мәкәржәдә булуы беренче һәм актыгы булды»[5].

Журналист, «Әлислах»[6] газетасының рәсми нашире һәм мөхәррире, укытучы, Г. Тукайның замандашы, иң якын дусларыннан берсе Вафа (Әхмәтвафа) Бәхтияров (1881–1960) бу хакта менә нәрсә ди: «Тукай үзенең тормышында кайбер хаталарын искә төшереп, шул хата эшләре өчен үкенә торган иде. Иң зур хаталарыннан берсе итеп Нижний (Горький) ярминкәсенә (Г. Камал белән бергә) барып «Сәйяр» труппасына кушылып, «Двухсветная» гостиницасының залында бөтен илдән җыелган купецлар, сәүдәгәрләр каршына чыгып үзенең шигырьләрен укуын күрсәтә иде <...>»[7].

***

Беренче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан, иганәче Хәсән Акчурин (1866–1916) 1908 елда Г. Тукайны Саратов губернасындагы Гурьевкадагы үзенең фабрикасына кунакка чакыра. Оештыру эшләрен Казандагы сәүдәгәр Бәд-

---

[1] *Хатыннар тавышы берлә* — андый тавыш контртенор дип атала. Бу хакта үзе күреп, үзе ишеткән язучы А. Расих та яза: «Мирфәйзә кулына кечкенә генә кыңгыраулы гармунын ала һәм шунда уйнап җырлый башлый. Мин аптырап калам. Әлбәттә, аның матур тавыш белән җырлавыннан түгел, ә шундый олы бәдәнле, үгездәй таза агайның хатын-кызларныкы кебек чәрелдек тавыш чыгаруыннан»: Расих А. Ишан оныгы: Роман-истәлек, беренче китап / А. Расих. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. — Б. 118.

[2] *Изһар итәргә* — белдерергә, күрсәтергә.

[3] *Хасыйл* — нәтиҗә.

[4] *Муаффәкыять* — уңыш.

[5] Кариев Г. Тукай Мәкәржәдә / Г. Кариев // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 671–672.

[6] *«Әл-ислах»* — демократик яшьләр һәм алдынгы шәкертләрнең басма органы булган газета (рәсми рәвештә 1907 елның 3 октябрендә чыга башлый) идарәсе әүвәлге урнашкан «Болгар» кунакханәсеннән 1908 елның 2 мартында Екатеринински (хәзерге Тукай, 63) урамындагы уртакул сәүдәгәр Габделшәкүр Апаков (1860–1923) өенә күчерелә. Газета, матди кыенлыклар аркасында, 1909 елның 22 июлендә чыгудан туктый.

[7] Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр / В. Бәхтияров // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 383.

ретдин Апанаевка (1867–1937 дән соң) тапшыра. Бу вакыйганы Хәбиберахман Зәбири (1881–1942) шулай тасвирлый: «Аның юлына бер йөз сум расхут тотарга кушып, миңа хат килде. Ул бу чакыруны кабул итте, өсте-башы рәтле булсын өчен хәзер киемнәр магазиныннан труйка кастүм, яңа батинка, оекбашлар, фантазия якалы[1] күлмәк, галстук, бер кат бельё, башына яңа кепка алып, башыннан аягына кадәр киендердек. Күңеле бик күтәрелде»[2].

Шагыйрьне анда зур хөрмәт белән каршы алалар һәм кунак итәләр. Фабрика мөгаллиме Кыям Кадыйри (Кыяметдин Иманколов) (?–?) истәлегендә шулай яза: «Мәҗлес озакка сузылды. Ул мәҗлестә рабучий, ыслужшчий һәм байлардан башка, укучы, укытучылар да бар иде. Тукайдан сораулар да булды. Сорауларга кыска-кыска матур җаваплар биреп, җыелганнарны шатландырды. Тукай үзе дә ул мәҗлестә шат иде. Тукай Акчуриннарда атна-ун көн кунак булды. Һәр көн кич Тукай өчен шундый шатлыклы мәҗлесләр ясалды»[3].

Ул фабрикага да кереп йөри. Киткәндә аны поездга утыртып, зурлап озаталар.

***

Г. Тукай 1911 елның апрель азакларыннан 6 июньгә кадәр Әстерхан шәһәрендә йөреп кайта.

«Шагыйрьне күреп белгән һәм аны бу сәяхәтенә башлап сукмак салышкан өлкән буын астраханьлыларның тагын берсе — Н. Шабанов. Үзенең сөйләвенә караганда, 1910 елда ул Казанга килә һәм, Г. Камал ярдәмендә, Габдулла Тукай белән таныша. «Казанга килгәннең икенче көнендә иртән, — дип сөйли Н. Шабанов, — мин тукталган номерның ишеген какты лар. Ишекне ачсам, Г. Камал белән миңа таныш булмаган бер егет басып тора. Ул егет Г. Тукай булып чыкты...». Аның сүзләренә караганда, әнә шул көннәрдә үк Тукай Астраханьга барырга вәгъдә итә»[4].

«Кечкенә сәяхәт» дигән мәкаләсендә шагыйрь үзе бу турыда шулай яза: «Бу ел апрель ахырында Казанның «Самолет» ширкәтенең «Тургенев» нам[5] пароходына утырып, Әстерханга сәфәр иттем. Урыным 3 нче класста иде»[6].

Пароход Саратов шәһәрендә туктый. Шәһәрнең «Беренче мәхәллә кызлар мәктәбе» укытучысы Мәүсүфә Яраева (?–?) Казандагы җизнәсе Нургали Надиев (1882–1940) җибәргән телеграмма буенча Г. Тукайның Әстерханга баруын белә. Ул укучы кызларны аның белән күрешергә алып бара. Шунда катнашкан Б. Әмированың ис-

---

[1] *Фантазия якалы* — крахмал якалы, кайтармалы якалы күлмәк. *Автор искәрмәсе*.

[2] Зәбири Х. Шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр / Х. Зәбири // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 366.

[3] Акчуриннар фабригы мөгаллимнәреннән Кыяметдин Кадыйри истәлеге // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 677.

[4] Миңнуллин Р. Тукай Астраханьда / Р. Миңнуллин // Казан утлары. — 1967. — № 4. — Б. 120.

[5] *Нам* — исемле.

[6] Кечкенә сәяхәт // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 29.

тәлегеннән күренгәнчә, укытучы апасы пароходка кереп, Г. Тукайны үзе белән алып чыга. Автор алга таба шулай яза: «Мәүсүфә апабыз безне бер сафка тезде дә, безгә карап: «Менә шул инде Тукай абыегыз», ә Тукайга карап: «Бу минем укучыларым. Сезнең шигырьләрегезне бик яратып укучы шәкертләрем», — диде. Тукай безгә кул биреп күреште. Без каушап калдык, ни әйтергә белмичә, сүзсез катып басып тордык. Хәтта букетларыбызны да бирергә оныттык. Мәүсүфә апа әйткәч кенә, букетларыбызны аңа суздык»[1].

Г. Тукай Әстерханга килүен тасвирлаган өч истәлек бар. Ләкин аларда бер-берсенә каршы килә торган моментлар да күзәтелә. Әйтик, Габдерәхим Утабалиев (?–?) шагыйрьнең «Люкс» номерларына төшкәннән соң «Идел» газетасы редакциясенә килүен яза. Хәнәф Гайфетдинов (?–?) исә, аны ат белән пристаньга барып алып кайтуын тасвирлап, каршы алучылар арасында Шәһит Гайфи[2], С. Рәмиев һәм тагын берничә кеше булуын әйтә.

Гөлсем Мөхәммәдова (1903–1988) истәлегеннән күренгәнчә, аларда фатирда торучы С. Рәмиев белән бер бүлмәдә яши[3].

Вәлид Алиев (?–?) язганча, «Тукайның бик ябык, авыру булуын күреп, Давыд абый Сәгыйть Рәмиев белән бергәләп аны доктор Нариманов[4] алып баралар»[5].

Г. Тукайны Калмык базары, Яңа Гаскәр дигән авылларга да алып баралар. Тияктә аның катнашында әдәби ахшам үткәрелә. Ул җырчы Мәрьям (Мәрьямбану) Искәндәрова[6] тарафыннан «Аркадия» исемле җәйге бакчада куелган концертта да була.

Әстерханнан китәр алдыннан шәһәрнең Зимний театрында аның хөрмәтенә зур кичә үткәрелә. Шунда катнашучыларның күмәк фотосы алдырыла. В. Алиев аны озатуны шулай сурәтли: «Габдулла Тукайны Астраханьнан бик олылап озаттылар, аңа шактый зур сумма акча җыелып бирелде. Тукай Астраханьнан килгәндәге кебек 3 нче класста түгел, бәлки, 1 класста, аерым каютада китте. Үзе дә килгәндәгедән

---

[1] Әмирова Б. Тукайны каршылау // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 683.

[2] *Шәһит Гайфи* — Гайфетдин улы Гайфетдинев (Гайфи) (1883–1937), мөгаллим. Шәхес культы корбаны. Әстерхан өлкә мәхкәмәсе үзенең 1959 елгы 18 апрель карары белән Калмык АССР НКВДсы элекке өчлегенең 1937 елгы 7 декабрь карарын гамәлдән чыгарып, аклана.

[3] Мөхәммәдова Г. Балачак истәлеге / Г. Мөхәммәдова // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 723–727.

[4] *Нариманов* — Нариман Кәрбәлай Нәҗаф улы Нариманов (1870–1925), әзәрбәйҗан әдибе, дәүләт эшлеклесе, табип. Ул вакытта Әстерханда сөргендә була.

[5] Тукай Астраханьда. Сәгыйть Рәмиев белән (Вәлид Алиев истәлеге) // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 692.

[6] Газиев И. М. М. Искәндәрова / И. М. Газиев // Габдулла Тукай. Энциклопедия / Баш мөх. З. З. Рәмиев. — Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты, 2016. — Б. 298.

күп үзгәргән иде. Башына эшләпә, өстенә европача тегелгән яхшы костюм, ак яка салып галстук бәйләгән, кымыздан соң шактый тазарган һәм матурайган иде»[1].

Г. Тукай 1911 елның 6 июнендә «Василий Лапшин» дигән пароходка утырып, Казанга кайтырга чыга.

***

Сәламәтлеге шактый какшап киткәч, шул ук елның декабрь уртасыннан 1912 елның март башына кадәр Өчиле авылында абзасы Кәшфелкәбир мулла Әмировта (1885–1938) торып килә. Аның хатыны Рабига (1886–1967) бу турыда шулай сөйли: «1912 елның декабрь урталарында Габдулла, хат язып, абыйсын бик ашыгыч чакыртып алды. Ул барганда Габдулла бик каты авыру булган. Барып кергәч тә абыйсыннан: «Җиңги нинди табигатьтә, әгәр бер кадәр вакыт мин сезгә кайтып ятсам, миннән тарсынмасмы? » — дип сораган. Ирем: «Җиңгәң бик әйбәт, кайт, бер дә тарсынмас», — дигәч: «Алайса кайтам, дуктырлар миңа авыл һавасында торырга киңәш бирәләр», — дигән. Улвакыт бик салкын иде. Ирем аны үзе белән бергә алып кайтмакчы булган. Ләкин көннәр бик салкын булганга һәм берничә көнлек эшем бар дип, ул аның белән кайтмый калган. Ирем кайтканның иртәгесен, бик салкын көнне, Сәрдә авылының[2] бер кешесе кереп: «Сезгә кунак алып кайттым, каршы чыгып алыгыз», — дигәч, без ирем белән аңар каршы чыктык. Ул чанада толыпка төренеп яткан иде. Аягында — чуар киез итек иде. Чанадан үзе төшә алмады, ирем белән без култыклап төшереп, күтәреп өйгә алып кердек. Гәүдәгә бик кечкенә булганга, ябыкканга күрә күтәрергә бик җиңел иде»[3].

1912 елның 1 гыйнварында «Матбагаи Шәрәф» типографиясе хуҗаларының берсе Г. Шәрәфкә язган хатында үзенең хәлен менә ничек тасвирлый: «Ниһаять, авылга кайтып йиттем. Сандык шикелле кечкенә генә нараттан салган ак өй үземнеке. Көненә ике ягылганга, бик җылы, тәмам чишенеп йоклыйм. Иртә белән яңа сауган җылы сөт эчәм. Гомумән, тегенди сөтне дә күбрәк эчәргә туры тырышам. Фәкать әле авылларда сыерлар бозауламаган икән. Хәзер үк үземдә бераз яхшыру вә хәлләнү сизә башладым. Казаннан алып кайткан даруларны да истигъмаль итәм[4]. Эшләр болай барса, бер-ике айдан сихәтләнермен кебек...»[5].

Бирегә кайтып торуның сәяси ягы да булса кирәк. Чөнки истәлек сөйләүче болай ди: «Ничектер, ул бездә торганда һаман үзен тикшерәләр дип шикләнеп тора иде[6].

---

[1] Тукай Астраханьда. Сәгыйть Рәмиев белән (Вәлид Алиев истәлеге)... — Б. 697.

[2] *Түбән Сәрдә* — хәзер Татарстан Республикасы Әтнә районындагы авыл.

[3] Рабига Әмирова-Мөхәммәтҗанова [истәлекләре] // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 56–57.

[4] *Истигъмаль итәм* — кулланам.

[5] Гыйльметдин Шәрәфкә // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 111.

[6] Ә Урманчиевкә 1912 елның 1 гыйнварында язган хатында шундый юллар бар: «Бу адресны, кем сораса да, бирмәгез. Гыйльметдингә дә шулай яздым». Рус телендә язылган адреста хатны алучы буларак Кәшфелкәбир мулла Әмиров күрсәтелгән. Ул тагын болай дип тә өстәгән: «Астына татарча язып, миңа тапшыруларын үтенәсез». Г. Тукай, үзен борчымау-

Бездә бераз торгач, авылга килеп аны сорап китүчеләр булган. Ләкин, минем иремнең әйтүе буенча, «монда андый кеше юк», дип әйтеп җибәрә торган булганнар. Анда-монда киткәндә, ирем һәрвакыт аны сорап килгән чит кеше булса: «Юк дип әйтегез, янына беркемне дә кертмәгез», — дип әйтеп китә иде. Шунлыктан, сорап килүчеләр булса да, без аның янына беркемне дә кертми идек. Язган язуларын Габдулла һәрвакыт миңа биреп куя иде. Арчага барганда, ирем аның язуларын почтага алып барып сала иде»[1].

Г. Тукай анда март ахырларына кадәр барлыгы өч ай ярым чамасы тора, сәламәтлеге дә шактый гына яхшыра. Аны Казанга Кәшфелкәбир үзе илтеп куя. Киткәндә Рабига ике мамык мендәр[2] биреп җибәрә.

***

Г. Тукай 1912 елның 14 апрелендә Уфага сәфәргә китә. Аны Казаннан «Ялт-йолт» журналы нашире һәм мөхәррире Әхмәт (Әхмәтзәки) Урманчиев (1889–1922) һәм «Сабах»[3] ширкәте җитәкчеләреннән берсе булган Шиһабетдин Әхмәрев (1882–1966) озата. Шагыйрь «Фултон» пароходына утырып башта Самарага бара. Ул анда «Бристоль» кунакханәсенә урнаша һәм шул ук көнне шәһәрнең мулласы, «Икътисад»[4] журналы нашире Мөхәммәтфатыйх Мортазин (1875–1937) белән очраша. Иртәгәсен хәзрәтнең бер шәкерте аны ат белән тимер юл вокзалына озатып куя һәм ул поездда Уфага юнәлә. Аның замандашы, шагыйрь белән 1907 елның көзеннән үк аралашкан иң якын дусларыннан берсе, «Сабах» ширкәтенең Уфадагы бүлегә мөдире Х. Зәбиринең истәлегендә бу вакыйга болай тасвирлана *(стиле сакланды — Р. И.)*:

«1912 нче ел яз иртә килде. Апрель башыннан ук костюм белән дә йөрерлек иде. Апрельнең ничәнче көне булганын хәтерләмим, бик матур бер көнне иртә белән сәгать 10 нарда «Сабах» ширкәтенең Уфадагы магазины алнына беренче дәрәҗә җиңел извошчик килеп туктагач, мин тәрәзәдән күреп, Тукайны танып алып шаккаттым. Әле ул экипаждан да төшеп өлгермәгән иде, мин атылып чыгып өлгердем. Бер яктан күрешәбез, икенче яктан мин: «Нигә телеграмм бирмәделәр», — дип сөй-

---

ларын теләп, кайдалыгын бары тик берничә якын дусларына гына әйтеп, башкаларга белдермәүләрен үтенүе кайбер башка истәлекләрдә дә телгә алына.

[1] Дөрестән дә, Г. Тукайның Өчиле авылыннан Г. Шәрәфкә 1912 елның 1 гыйнварында, Ә. Урманичевкә язган (ике) хатлары мәгълүм.

[2] Бу хакта Г. Тукай 1912 елның январь аенда Ә. Урманчиевкә язган хатында да яза: «Әле авыл хатирәсе булыр дип бер юрган, ике мендәр эшләтеп алдым».

[3] *«Сабах»* — үзенең башлангычын Казандагы «Көтебханәи ибтидаи» дигән китап кибетеннән алган, 1902 елда бертуган Габделвәли (1870–1921 елдан соң) һәм Мөхәммәтгали (?–?) Әхмәдуллиннар тарафыннан «Габделвәли Әхмәдуллинның Сабах көтебханәсе» итеп үзгәртелгән китап бастыру һәм сату ширкәте. 1911 елда аның каршында Габделвәли Әхмәдуллин «Өмид» басмаханәсе ача (1916 ел азакларында И. Н. Харитонов (1859–1954) типографиясе белән берләштерелә). Иптәшләре — Хәбиберахман Зәбири (1891–1942), Шиһабетдин Әхмәров (1882–1966), Сөррах хәлфә (?–?), Г. Гыйльфанов (?–?), Хуҗа Сәгыйть (?–?) һ. б. 1921 елда яңа хакимият карамагына күчерелә. Казан һәм Уфа шәһәрләрендә китап кибетләре булган.

[4] *«Икътисад»* — 1908–1913 елларда Самара шәһәрендә нәшер ителгән айлык журнал.

ли башлагач: «Мине Шиһаб озатканда: Уфа зур түгел, вокзалдан чыгып извошчикка магазин «Сабах» дип әйтсәң, шул җитә. Синең поездың Уфага иртә белән барып керәчәк, дип, сөйләде», — ди.

Нәкъ шул вакытта Хөсәен Булгаков дигән кеше үтеп бара иде. Аның йорты Мәҗит Гафури белән бер урамда булганлыктан, мин: «Хөсәен абзый, Гафурига әйт әле Тукай килгәнлеген», — дип үтендем.

Тукай да юл мәшәккъәте белән арганлык, рух төшенкелеге хис ителми. Ашыгып-ашыгып бер-беребезгә сөальләр биреп, бер-берсенә бәйләнешсез сүздән туктый алмыйбыз, һаман сөйләшә бирәбез. Ахырында: «Йә Тукай, кайда, сиңа нумер алыйкмы, әллә берәр гаиләгә урнаштырыйкмы?» — дигән сөальгә каршы: «Син бит әле өйләнмәгәнсең, Казанда миңа әйттеләр: Зәбири үзе магазин артында тора, шунда бергә оешырсыз», — дигән җавабын ишеткәч: «Менә минем бүлмәм: көндез кантур була, кич белән минем йокы бүлмәм. Язу өстәлен бер читкә тартам да үземнең күчмә койкамны куеп, шунда йоклыйм», — дидем.

«Бу инде бик яхшы, шунда без бергә торырбыз», — дип башка бер урынга барырга теләмәгәнен аңлатты. Һәм без шул рәвешчә тора башладык. Мин кантур өстәлендә, Тукай минем койкада ята идек күзгә йокы төшкәнчә. Һәр көнне диярлек Мәҗит һәм без икәү сөйләшеп, салмак кына, тәмләп кенә сыра эчеп, чын, самими утырышлар үткәрә идек.

Тукай бу турыдагы истәлекләрен материал итеп «Ялт-йолт» журналына язганлыгы, почтага салганда миңа укыганлыгы хәтеремә килә. Тикшерелгәч, табылмый.

«Тукай Уфада «Сабах» артындагы әрҗәләр өстендә аунап яткан», — дигән ялган буяулы сүзләргә җавап бирүне кирәксенмимен. Минем үземнең дә шунда торуым һәм ул вакытта өйләнмәгән булуымны бик үк фәнни дәлилләр белән исбат итәргә маташып, фәнне уен җиргә расхутка чыгарасым килми, тарих үзенекен исбат итәр.

Үзем ни хәлдә булсам, Тукай да нәкъ бер үлчәүдә иде һәм ул моннан риза булып иң рәхәт моментларын үткәреп китте. Мине шул шатландыра.

Тукай 150 сум акчасыны миңа сакларга биреп куйды. «Минем әле вак-төяк расхутка тагын акчам бар», — дип байлыгын да сөйләп алды.

Кесәсеннән чыгарып, Муса Бигиевтән килгән хатны укырга бирде. Бигиев, ипташларе Галим Мәкъсутов, Лотфый Исхаковлар исеме белән, аны Петербургка кунакка чакырып язган иде. «Әйдә, әле башта Уфада кунак бул, бу турыда соңрак уйлашырбыз», — дидем.

Уфада минем белеш-танышларымнан кайберләре безне кунакка чакырсалар да Тукай һичбер йиргә барырга теләмәгәнлеген аңлатты.

Ул заманда Уфада кыз-хатыннар безнең Казанга караганда бик күп алда торалар иде. Үзләрен бик күп иркен тоталар, әйтергә мөмкин, яңа китап алучыларның күп өлеше алар иде дип.

Магазинга килгәндә кыз-хатыннар Тукайны күрәселәре, танышасылары килә, ләкин ул һичберсен кабул итми. Бичаралар магазин белән ике арадагы ишек ярыгыннан тамаша кылып кына китәләр иде.

Мәҗит Гафури һәр көнне килә. Ике шагыйрь рәхәтләнеп көн үткәрәләр. Бу турыда Мәҗитнең истәлекләре булганлыктан, артык язуны кирәксенмим, тик шуны гына әйтеп узам: мин аларның тыныч кына, тәмләп кенә шунда утыруларын тели

идем. Шәһәргә чыгып уралып йөрсәләр кирле-кирәкмәгән кешеләргә очрап, Тукайның кәефен җибәрә торган берәр вакыйга булмас дип куркына идем...»[1].

Г. Тукайга Уфаның табигате, бигрәк тә аның коры саф һавасы, агачларның күплеге бик ошый. Шәһәрдә чат саен сөт кибетләре булуы, сыраханәләрнең сирәклеге дә шагыйрьне тәэсирләндерә.

Уфада үткәргән вакыты турында ул үзенең «Мәкаләи махсуса»сында болай яза: «...Квартир гомумән күңелле. Кеше күп килә. Эч пошарлык түгел. Монда һәр көн мөхәтдисе кәбир[2] Әхмәтфәиз Даутов белән күрешәбез. Ул скрипкәдә маташтыра, әлегә яхшы уйный алмый. Ләкин җырласа, мин андый җыруны бөтен гомеремә тыңлар идем. Аның гади сөйләшүдә дә металлический вә музыкальный тавышы җырлау заманында бөтен көчен вә голүвиятен изһар итә[3]...»[4].

М. Гафури (1880–1934) шагыйрьнең Уфага килү хәбәрен ишеткәч тә, аны эзләп «Сабах» кибетенә килеп җитә. Аның белән очрашуы турында Г. Тукай шулай яза: «Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа караганда да җуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мосахәбәмез[5] күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде. Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Шаярыр идек — әле генә язмыш ханым кыйнаган; җылар идек — әле күздән яшемез дә кипкән...»[6].

Ул күрешү хакында М. Гафури үзе болай ди: «…Тукай гаилә тормышын артык сөймәгәнгә, аны гаилә эченә алып барырга теләү бушка китәчәк булганга, ул якны әйтеп тормадым.

Без, язгы кояш астында бераз йөреп, берәр җиргә кереп утырырга карар бирдек. Без бүген матуррак бер җиргә керергә муаффәкъ булдык. Кояшка каршы булган бу залны Тукай үзе дә яратты.

Без инде монда бик иркенләп утырмакчы булдык. Эшләр, Тукай теләгән рәвештә, бик шәп китте.

Бик кәефле утырган вакытта, Тукай бизгәк тоткан кебек калтырана башлады. Аның шундый вакытта йота торган порошогы «Сабах»та калганга күрә, даруны җибәртеп алдырырга туры килде. Шул даруны эчкәннән соң, Тукайның калтыравы басылып, бераз кәефе төзәлде.

Баштарак Тукай да, мин дә, сүз таба алмаган кебек, бер-беребезнең күзебезгә карашып, тик утыра идек. Бара торгач, безнең мәҗлес бик күңелле булып китте. Күб-

---

[1] Зәбири Х. Шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр / Х. Зәбири // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 368–370.

[2] *Мөхәтдисе кәбир* — хәдисне күп белүче.

[3] *Голүвиятен изһар итә* — бөеклеген ачып бирә.

[4] Тукай Г. Мәкаләи махсуса // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 53.

[5] *Мосахәбәмез* — әңгәмәбез.

[6] Тукай Г. Мәкаләи махсуса... — Б. 55.

рәк сүзләребез шигырь вә шагыйрьләр, Казан һәм дә мохитебез хакында иде. Тукай Казандагы тормышыннан ялыкканлыгын, шул сәбәпле кымызга иртәрәк булса да, Казаннан китәргә ашыкканын сөйләде.

Тукайның хәссас күңеленнән чыккан бик гади генә сүзләре, аның бу дөньядан һәм дә үзенең мохитеннән разый булмавы — миңа яхшы ук зур тәэсир бирде. Бу вакытта безнең икебезнең дә күзләребездә ихтыярсыз атылып чыккан күз яшьләре ялтырый иде…»[1].

***

Г. Тукайны Петербургка чакырып язылган хат, кызганыч ки, сакланмаган. Х. Зәбири, аны үзе күреп укыган кеше буларак, андагы шундый юлларны китерә: «Бән фәлән һәм фәлән әфәнделәр сези Петербура дәгъвәт идәрез. Истәрсәңез, Финляндияйә сәяхәт идәрез. Бер кат әлбисә[2] бездән һәдия[3] улыныр, Петербура кәлеңез әфәндем»[4].

Шул вакытта «Нур» газетасы идарәсендә сәркятип булып эшләгән Кәбир Бәкер (1885–1944) истәлегендә бу хакта шулай диелгән: «...1912 нче елның алдында Петербургта бер кыйсем[5] яшь дини голәма арасында «Хәбәр» исемендә бер гәзитә чыгару фикере таралды. Шул вакыт Муса әфәнде Бигиев Казанга Тукайны чакырып хат язган. Ул вакыт Тукай бу хатка, ни өчендер, иҗабәт итмәгән[6]. Яз булгачтын, дәваланырга тугры килеп, шул уңайдан Петербургка да барып китәргә уйлаган...»[7].

Ул елларда журналист булган Кәрим Сәгыйдев (1888–1939) тә бу фактны искә ала: «...Янәдән хәзерге көндә Петербургтагы мөхтәрәм затларымыздан берничәсе 1912 елның башында Петербургта «Сүз» исемле татарча бер газета чыгармакчы булып та йөргәннәр, менә бу ике мәсьәлә бергә буталганнар иде. Габдулла әфәнде үзе бу мәсьәләнең эчендә, һәммәсеннән хәбәрдар, һәммәсенә разый, шулай итеп, Петербургка килергә тели иде...»[8].

Чынлыкта Г. Тукайны Петербургка дин галиме, публицист, җәмәгать эшлеклесе Муса Бигиев (1873 яки 1875–1949), шәһәрнең «Җәмгыяте хәйрия» мәктәбе мөдире имам Лотфулла Исхаков (?–1925)[9], сәүдәгәр һәм нашир Галим (Мөхәммәтгалим) Мәкъсудов (1857–?) чакыралар. Бу хакта М. Бигиев «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатыйх (Мөхәммәтфатыйх) Кәримигә (1870–1937) 1914 елның 7 апрелендә үзе юллаган аңлашу хатында болай дип яза: «Дөрест, өч-дүрт адәм без Габдулла әфәндене

---

[1] Гафури М. Тукай Уфада / М. Гафури // Ил. — 1914. — 2 апр.

[2] *Әлбисә* — кием.

[3] *Һәдия* — бүләк.

[4] Зәбири Х. Шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр... — Б. 370.

[5] *Кыйсем* — төркем.

[6] *Иҗабәт итмәгән* — уңай җавап бирмәгән.

[7] Бәкер К. Тукай Петербургта / К. Бәкер. — Оренбург: Электро-паровая Лито-тип. Т-а «Каримов, Хусаинов и К-о», 1914. — Б. 11.

[8] Сәгыйд К. Тукай тормышыннан истә калганнар / К. Сәгыйд // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 713.

[9] İmam Lütfi el İshaki / Naşiri Safiye bintü Kemaletdin Ahsaen Böre. — Tampere, 1945. — 75 s.

дәгъвәт итмеш идек. Казанда Габдулла әфәнденең гайәт айаныч хәлләре безә мәгълүм иде... Казанда корректорлык шәрәфенә канәгать кылуб тормыш Габдулла әфәнде, Петербургта ул вакыт интишары фараз кылынмыш җәридәдә (нәшер итәргә уйланылган гәзитәгә) исмән генә мөхәррирлек хезмәтенә әлбәттә разый улыр да Петербурда бәлки калыр хыялында идек». Анда шулай ук аерым кешеләр тарафыннан Г. Тукайның фатир, көндәлек ашау-эчү һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү мәсьәләләрен хәл итүне үз өсләренә алынуы турында да әйтелә.

«Истәрсәңез, Финляндияйә сәяхәт идәрез» мәсьәләсенә килгәндә исә, М. Бигиев, дөрестән дә, Г. Тукайны үпкәләре авырулар өчен ул вакыттагы Выборог губернасында оештырылган «Халила» беренче дәүләт шифаханәсенә урнаштыруны да уйлаган булган.

Г. Тукай, ниндидер сәбәпләр аркасында, чакырылган вакытта Петербургка бармый. Уфага килгәндә дә ул бу хакта уйланмый. Ләкин биредә дә, Троицкида да әле кымыз вакыты булмау һәм шул вакытта теге хат аның исенә төшү фактлары шагыйрьдә пайтәхеткә бару карарын барлыкка китерә.

Х. Зәбири үзенең истәлегендә Г. Тукайның Уфадан Петербургка китү вакыйгасын шулай тасвирлый: «...Шуннан соң Габдулла әфәнде телеграмм бирде. Ике көннән соң Лотфый әфәнде Исхаковтан «Тукаевка 25 сум акча бир», — дип, миңа телеграмм килде. Мин вокзалга озатышып Мәскәүгә тугры бара торган поездга билет алып бирдем. Эстәрлетамак сәүдәгәрләреннән бер кеше Мәскәүгә кадәрле карап барырга һәм анда Николайски вокзалда озатып йибәрергә дә өстенә алды. Мәскәүдән телеграмм бирүләрен дә үтендем...»[1].

Ләкин, Х. Зәбири язганча, Г. Тукайны Петербург вокзалында каршы алучы булмаган. Ул извочик яллап, М. Бигиевнең квартирасына килә.

М. Бигиев мәгълүматына күрә, Г. Тукай Петербургка бернинди хәбәрсез килә. Аерым алганда, бу турыда ул болай ди: «Кабул итте, килде. Телеграмм-фәләнюк иде, истикъбаль кылалмадым[2]. Номер хәзерләп куймыш исәм дә, капум[3] төбенә килгәч, номерга барайык дия алмадым. Гайәт тар квартирамда үзенә махсус гайәт зур бүлмәдә урын вирдем. Килү сәгатендә телефон илә бөтен Петербурга шагыйрең кодумендән[4] хәбәр таралтдым. Ул көндә үк адәмләр килә башлады...»[5].

Дөрестән дә, Г. Тукай Петербургка килгән вакытта М. Бигиев үзенең ишле гаиләсе белән Сергиев (хәзерге Чайковский) урамында 81 санлы йортта арзанлы гына квартирада яши. Аның язучылык эшеннән башка килере булмый.

Г. Тукайга Петербургта иң элек аның һава шартлары бик авыр тәэсир итә. К. Бәкер бу хакта болай ди: «...Тукай үзенең Петербурга килүеннән бик нык зарланды. Бу зарлануның башлыча сәбәбе: Петербург һавасының юешлеге вә бер дә туктамый

[1] Зәбири Х. Шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр... — Б. 371.

[2] *Истикъбаль кылалмадым* — каршылый алмадым.

[3] *Капум* — ишегем.

[4] *Кодумендән* — килеп җитүе турында.

[5] Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 636.

бер хәлдән икенче хәлгә күчеп торуы иде. Хосусан аның Петербургка килгән көннәре әллә нинди күңелсез суык һәм юеш булды...»[1].

Шагыйрь гәрчә М. Бигиевтә дүрт көн яшәсә дә, алар арасында самими мөнәсәбәт урнаша алмый. Бу хакта ул үзе К. Бәкергә болай дип аңлата:

«1) Муса әфәнде ят кеше... өстенә фәүкыльгадә тәкәллефле (артык дәрәҗәдә төче теллеләнеп хөрмәт күрсәтү), — Тукайның үз тәгъбиренчә, — сөче телле... Сөче теллелекне ул үзе шулай тәфсир кыла: ул менә — Муса әфәнде була инде — юк кына нәрсәне тәкәллефләндереп зурайта. «Затегалиләре, бәндәләре» ди... Әллә нәрсә вә әллә нәрсәләр катыштыра да ике арага пәрдә сала да куя. Шуның өчен, никадәр якын булырга теләсәң дә, аның белән рәхәтләнеп, тәкәллефсез сөйләшеп булмый. Ул «затегалиләре» ди бит инде. Аңа каршы син ни дип әйтергә кирәк?..

2) Анда Муса әфәнденең җәмәгате бар... Ул гына йитмәсә, аның кардәшләре вә тагын берничә курсисткалар да килә. Өстенә алар тагын һәрвакыт юл өстенә утыралар. Исәнләшсәң, сөйләшеп торырга кирәк, минем өчен тукталып, исәнләшеп торуы үзе бер бәла... Исәнләшмәсәң, килешми…»[2].

М. Бигиевнең искә алынган җәмәгате — Әсма (1884–1975) ханым Чистай шәһәренең имам-хатыйбы, ишан, танылган «Камалия» мәдрәсәсен нигезләгән 2 нче гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтзакир Камалов (1804–1893) һәм аның хатыны Бибифатыйма абыстай (1855–1939) кызы. Шагыйрь Петербургка килгәндә Бигиевләр гаиләсендә биш бала була.

Г. Тукай шулай ук М. Бигиевнең мохите, ягъни ул аралашкан кешеләр белән дә үзләшеп китә алмаган. Шагыйрь Петербургта яшәүче татарларның үзара төрле мөнәсәбәттә булуларын да абайлап ала. Бу хакта болай ди: «Дүрт-биш көн һичкайда чыкмый, белгән-күргәннән һичбер кешесез мәхбүс[3] ятканнан соң, кичә Петербург курсларыннан берендә укый торган Шәриф әл-Әхмәди[4] дигән бер әфәнде килде. Бераз сөйләшкәннән соң, Сафа мәхдүмнең визит карточкасыны биреп, иртәгесе көн өйләдән соң сәгать бергә Сафа әфәнденең үз өенә чакырганлыгын сөйләде. Муса әфәнде миңа һичбер хәбәр итмәстән, аңа бик катгый рәд[5] җавабы бирде. Юк кына нәрсә өчен бик кызып: «Булмас, иртәгә аның вакыты юк, чакырылган йиремез бар, — диде»[6].

М. Бигиевнең мәгълүм хатында исә мондыйрак факт сурәтләнә: «...Мөхтәрәм Сафа хәзрәтнең бер наборщигы килеп, Габдулла әфәндене дәгъвәт итмеш. Бән ул вакыт ханәмдә юк идем. Кайттым, Габдулла әфәнде дәгъвәт хәбәрене сөйләде. «Наборщик васыйтасы илә[7] (аша) дәгъвәт иттермәк сезең шаэнеңезә мөнасиб дәгел[8].

---

[1] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 14–15.

[2] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 15.

[3] *Мәхбүс* — тоткын.

[4] *Шәриф әл-Әхмәди* — Шәриф Әхмәт улы Манатов (1887 яки 1892–1936), публицист, сәяси һәм җәмәгать эшлеклесе. Ул вакытта Петербург психоневрология институты студенты. Шәхес культы чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

[5] *Катгый рәд* — кискен каршы.

[6] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 19.

[7] *Васыйтасы илә* — аша.

[8] *Шаэнеңезә мөнасиб дәгел* — дәрәҗәгезгә туры килми.

Үзләре килеб сезе зийарәт итсенләр. Соңра дәгъвәтләренә, әлбәттә, ижабәт идерсез», — дидем...».

Г. Тукай үзенә карата М. Бигиевнең мондый мөнәсәбәтен кабул итә алмаган, әлбәттә. Бер үк вакытта үзенең киеренке хәлдә калуын төшенеп ала һәм Уфага кайтып китәргә кирәклеге турында сүз кузгата.

К. Бәкер, «Нур» газетасының нашире Сафа (Мөхәммәтсафа) Баязитов (1885–1937), Петербург университеты студенты Шакир Мөхәммәдъяров (1883–1967), К. Сәгыйдев шагыйрьне берникадәр кунак итеп, аның күңелен бераз күтәрү хәстәренә керешәләр.

С. Баязитов акчасына Петербургның Казан (хәзерге Плеханов) урамындагы бишенче санлы йорттагы номерлардан мебельле бер бүлмә алына һәм Г. Тукай шунда яши башлый.

Бер үк вакытта Ш. Мөхәммәдъяровның турыдан-туры ярдәме белән Г. Тукайны Петербург университеты табибы А. Р. Польгә (1876–1923) күрсәтү мөмкинлегенә ирешелә. К. Бәкер болай яза: «Доктор Тукайның үзенә: «Зәгыйфьлектән башка авыруың юк... Тазарсаң (?) бетәр... Фәкать боның өчен яхшырак санаторийәләрдән беренә барып, бик яхшы тәрбияләнергә кирәк, — дигән икән, Тукай: «Кымызга барсам, булмасмы? — дип бик исрар кыйлгач (үз фикерендә каты торгач), «Кымыздан яхшы файдаланырга мөмкин... Тик бик пөхтә җир булырга кирәк», — диде, ди. Озаткан вакытта Шакир әфәндегә (хәрфиян) шулай дигән: «Туберкулезның соңгы дәвере, бер үпкәсе (кайсы як икәне хәтердә калмаган) череп беткән, икенче үпкәсенең дә яртысы гына калган. Тын ала торган әгъзаларының дүрттән бере белән генә тын алып тора…»[1].

Бу хәбәрдән соң Г. Тукайның дуслары, аның үзенә сиздермичә, әлбәттә, үзара акча җыеп, шагыйрьнең гомерен өч-дүрт елга гына булса да озынайту максатында, Швейцариягә дәваларга җибәрергә дигән фикергә киләләр. Әмма Г. Тукай Троицкига кымызга китәргә карар кыла.

К. Бәкернең истәлегенә мөрәҗәгать итик: «...Китәсе көн бу мәктәптә («Җәмгыяте хәйрия» мәктәбендә — *Р. И.*) укыган бөтен ир вә кыз балалар исеменнән Тукайга (номерына) алты кешелек бер вәкаләт йибәрелде. Вәкилләрдән өчесе кыз, икесе ир бала, берсе мөгаллим Мәхмүт әфәнде Сипаев иде. Вәкилләр сөекле шагыйрьләренә үзләренең «Сау бул!»ларыны әйтеп, кыз балалар исеменнән мәгъсүм[2] мәхәббәт галәмәте булган зур бер букет — саф аллы-гөлле чәчәкчәкләр тәкъдим иттеләр. Ир балалар исеменнән бронзадан эшләнгән яхшы, кыйммәтле бер карасавыт китерелгән, анда садакать[3] вә мәхәббәт ләмәтен мөшгыйрь[4] бер рәсем (эмблема) куелган — бронзадан бик матур бер үрдәк, эте белән сумка сурәте төшерелгән иде. Тукай бу шәкертләрнең үзләренә дә, бүләкләренә дә бик куанып калды…»[5].

---

[1] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 39–40.

[2] *Мәгъсүм* — эчкерсез.

[3] *Садакать* — тугрылык.

[4] *Мөшгыйрь* — белдерүче.

[5] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 49–50.

Кич белән Мөхәммәтшаһ Җиһаншин (?–?) исемле бер хәлле кешенең өендә Петербург татар сәүдәгәрләре һәм приказчиклары тарафыннан Г. Тукай хөрмәтенә мәҗлесе уздырыла. Анда аңа тәбрик адресы белән 50 сум акча тапшырыла.

Г. Тукайны Петербургтан озату, К. Бәкер язганча, шулай була: «Хәтеремдә яңлыш калмаган булса, поезд Николаевский вокзалдан төнге сәгать беренче ярты да кузгалачак иде. Вокзалга Тукайны озатырга Петербург имамнарыннан Сафа ахунд Баязитов, Лотфи әфәнде Исхаков, төрле мәктәпләрдә укучы студент вә яшьләр, төрле сәүдә йортларында хезмәт итүче мөселман приказчиклары да килгәннәр — 25–30 га якын кеше бар иде. Мәҗлес алдыннан сөйләнгән сүз буенча тимер юлга билетны Уфага кадәр Муса әфәнделәр алып куярга тиеш иделәр. Көндез бервакыт Муса әфәнде Тукай янына кереп, үзе билет алып куячагын әйтеп киткән иде. Шунлыктан башкалар билетны Муса әфәнде алган дип тордылар. Хәлбуки, Муса әфәнде вокзалга да килмәде. Поезд китәр вакыт якынлашкачтын, Сафа әфәнде белән мәслихәтләшеп, без өченче класстан плацкарт белән бер билет алдырдык (каты йөткергәнлектән, икенче класс кешеләре белән килешеп барырга уңгайсыз булыр дип, Тукай икенче класстан билет алырга риза булмады. Ятар өчен аерым урынлы булгач, өченче класс та ярар, диде).

Икенче, өченче звонок булды. Муса әфәнде һәнүз[1] юк иде. Тулып торган халык арасыннан ерып кереп, утырып та өлгермәдек — поезд кузгалып китте.

Мин Тукайны Мәскәүгә кадәр озата бардым. Иртәсе көн сәгать 10 нарда Мәскәүгә җиттек. Анда Николаевский вокзалдан Рязанский вокзалга күчеп, аш (обед) ашап, чәй эчүгә поезд килде. Бик сайлап бер урын алып, Тукайны утыртып озатып калдым. Мәрхүм, ялгыз китәргә булгач, бик уңгайсызланган кебек булган иде...»[2].

***

Г. Тукай, Уфага кайтып җиткәч, унберенче май көнне Казанга Ә. Урманчиевкә хат яза. Ул аңа Петербургка баруыннан зарлана, сәламәтлеген какшатуын белдерә. Бераздан Троицкига китәргә җыенуын әйтә. Хаттан аңлашылганча, ул «Ялт-йолт» журналы белән танышып бара, аның сыйфатын яхшырту максатында үзенең кайбер киңәшләрен дә җиткерүне кирәк саный. Троицкидагы Габдрахман Рахманкулов (1879–1937) адресын күрсәтеп, шундый характерда үтенечен дә юллый: «Керләрне җибәргәндә, почтада жугалмаслык итеп, эченә минем корзинкада онытылып калган кара тышлы дәфтәрне дә җибәрсәңез иде, зинһар. Ул дәфтәрдә минем «Җан азыклары» дигән почти шул мәҗмугалек шигырьләрем бар»[3]. Ә уникенче майда К. Бәкергә шундый эчтәлекле хат күндерә:

«Мелла Кәбир!

... Мин кайтып җиттем. Эшләр көткәнчә. Уфа докторына кан тәхлилле тугрысында бардым. Ул әүвәл тазарырга, сәламәтләнергә кирәклеген вә бер кадәр беткән тәнне тәхлилгә вә анда микроб булган тәкъдирдә дә аңар агулы дару җибәрү мөм-

[1] *Һәнүз* — һаман.

[2] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 54–55.

[3] Әхмәт Урманчиевка // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 116.

кин түгеллеген сөйләде. Җүтәлдән бер-ике төрле дару бирде. Кымыз эчәргә кушты. Уфада кымыз бер генә җирдә. Публика дәрхаль эчеп бетерә. Шулай да күп көнне бер-ике бутылка ләктерәм... Монда чәчәк тә агач исе. Теге аспирин җоттыра торган авыру (бизгәк) күптән бетте...

Сез нишләп йөрисез? Иблис галәйһе... кайларга барырга киңәш бирә?.. Шакирга шундый пәйгамбәр төсле кешесе өчен рәхмәтеме, ни генә әйтим. Кәрим Сәгыйдевкә күп сәлам. Сафа әфәндегә хосусый хат яздым...

Тиздән китмәк булам (ягъни Тройскигә). Хатны шушы адрес белән язарсың: Тройск, Оренбургский губерна. Габдерахман Рахманкуловка (Тукаевка). Шәриф әл-Әхмәдигә сәлам. Мәскәүдән соң, Ходай тугры китереп, урыным яхшы булды. Вагонда буфет та бар иде. Бернәрсәгә дә аптырамадым. Әлегә җитәр.

Тукай.

Уфа, 1912 ел, май — 12»[1].

1908 елның көзеннән башлап Уфада Кәримев-Хөсәеневләрнең «Шәрекъ» китапханәсендә эшләгән Габдулла Вәлиев (?–?) исемле кеше Г. Тукайның Петербургта йөреп кайткан вакытны шулай тасвирлый: «Тукай Уфада вакыт көннәр тәмам җылынган, чын җәй җиткән иде. Мәҗит абзый Гафури белән алар икәүләшеп һәр көнне көн урталарында Уфаның шәһәр уртасында булган бакчасы — «Ушаковский парк» — дигән бакчасына барып ята торганнар иде. «Шәрекъ» китапханәсе юл өстендә булганга күрә, барышлый-кайтышлый: «Без паркка барып ятабыз әле», — дип «Шәрекъ» китапханәсенә кереп, ял итеп чыга торганнар иде»[2].

Бу хакта М. Гафури үзе болай искә ала: «Тукайның Уфага икенче мәртәбә килүенә бакчаларда агачлар яфрак ярган, җир өсте яшел мамык кебек яшь үләннәр белән капланган, кымызлар хәзерләнгән иде. Бик матур кояшлы көндә шәһәр бакчасына чыктык. Анда кымыз эчкәннән соң, агачлар арасындагы ачык җиргә яшел үлән өстенә барып яттык.

Тукай: «Кайда ул Петербургта бу һава белән бу яшеллекләр! Анда яшел нәрсәләрне суганчы маржалар кулында гына күреп калырга була», — диде.

Кымыз эчеп, һавада яту Тукайның сәламәтлеген кайтарган кебек булды, һаваны мактый, иркен сулу ала, ике сүзнең берсендә «сәламәтлек һавасы эчәм» дип сөйли иде.

Тукай Уфаның саф һавасын, матур бакчаларын бик яратты. Шуның өчен, Уфада торганда, аз гына кояшлы вакыт булса, бакчага чыга, кымыз эчеп, яшел үлән өстендә ята иде. Бакчада яшел үлән өстендә йоклап киткән вакытлары да булды…»[3].

Г. Тукайның иң якын дусларыннан берсе, укытучы Каюм Мостакаев (1885–1974) шагыйрь белән М. Гафури арасындагы дустанә мөнәсәбәт турында үзенең истәлекләрендә шулай язып калдырган: «…Тукай Мәҗитне сүз уңае чыккан саен хөрмәт белән телгә ала, аны башлап татарча беренче буларак шигырьләр яза башлаган өлкән шагыйрь булганлыгы өчен генә түгел, һәр икәвесенең арасында идея уртаклыгы һәм дә шул юлда бөтен каршылыкларга күкрәк киреп туктаусыз алга баруын-

[1] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 55–56.

[2] Вәлиев Г. Габдулла Тукай хакында хәтердә калганнар / Г. Вәлиев // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 529–530.

[3] Гафури М. Күрс. хезм.

да дәвам иткәнлеге өчен дә Тукай Мәҗитне күңеленә якын күреп хөрмәт итә иде…»[1].

Берничә ел Александр централендә (Иркутски шәһәреннән 76 километр ераклыкта урнашкан Александровски авылында булган каторга үзәк төрмәсе) тоткынларның балаларын укыткан, соңыннан мәгариф һәм мәдәният эшлеклесе булган Мөбарәкҗан Әмиров (1886–1968) Г. Тукай белән очрашуы турында болай яза: «1912 елның май айлары иде булса кирәк, Габдулла Тукай Троицкига кымызга барышлый Уфага тукталган иде. Габдулла Тукайның туктаган урыны булган «Сабах» китап магазинына кереп Тукай белән күрешергә батырчылык итми йөргән бервакытта, һич уйламаганда, Мәҗит Гафури белән Габдулла Тукай урамда каршы очрадылар. Мәҗит Гафури мине туктатып: «Бу Әмиров әфәнде була, Ерак Сибириядән, каторгада балалар укыткан» дип, Тукай белән таныштырды. Бердән, «Ерак Сибирия» сүзе, икенчедән, «каторга» сүзе Тукайга аерым тәэсир итте булса кирәк, ул миннән Себергә кайчан баруым, анда нинди шартларда эшләвем һәм кемнәрне укытуым турында гаять кызыксынып сораша башлады. Ләкин кемдер берәү килеп чыгу сәбәпле, сүз киселеп калды. «Хәзергә хушыгыз, Габдулла әфәнде», — дип аерылып китәргә туры килде.

Тукай бу вакытта кара көрән төстәге озын гына җөббәдән (җиңел пальтодан), тар кыркулы каракуль бүректән иде. Бөек шагыйрь белән очрашып күрешү минем өчен никадәр кыйммәтле бер вакыйга булса да, ул дәвамлы була алмады. Минем өчен беренче һәм соңгы очрашу булып калды…»[2].

М. Гафури Уфада Г. Тукайга карата тиешле илтфат күрсәтелмәвенә үзенең истәлегендә борчылып яза. Аның, әлбәттә, шул вакыттагы интеллигенция һәм хәлле кешеләр турында сүз йөртүе аңлашылса кирәк. Ул бу хосуста менә нәрсә ди: «…Уфа Тукайның дәрәҗәсенә мөнасип һичбер хәрәкәт күрсәтә алмады. Тукайның Уфага килүү хөрмәтенә һичбер мәҗлес-фәлән тәртип кылынмады. Аның Уфага килгәнен күп кеше белми дә калгандыр.

Тукайның Уфада үткәргән ун-унбиш көн гомере «Сабах» көтепханәсенең артындагы бүлмәдә үтте. Аның күңелен ачып, рухын күтәрерлек һичбер эш эшләнмәде. Бер гаиләдән башка, хосусый дәгъвәт итеп, күңелен ачучы да булмады»[3].

***

Билгеле ки, Г. Тукай Уфада берничә көн булганнан соң, Троицкига барырга карар кыла. Бу хакта ул «Мәкаләи махсуса»сында үзе яза: «Дөрест, мин кымызны Уфада да, әтрафында да эчәчәк түгел. Мин аның өчен Троицкига барырга Казаннан ук карар биреп чыккан вә йөзләп баш бия саудыра торган бер Троицки кешесенә барасы, кымызны савылган урынында чатыр торып эчәсе кеше. Чөнки Уфа әтра-

[1] Мостакаев К. Тукайның ул чорлардагы кайбер кешеләргә карашы / К. Мостакаев Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 2 т.: Мәкаләләр, шигырьләр, төрлеләр. — Б. 526.

[2] Әмиров М. Күз алдында тора... / М. Әмиров // Кызыл таң. — 1961. — 26 апр.

[3] Гафури М. Күрс. хезм.

фын европалылар басып, биттабгы[1], андагы кымыз искусственный[2](җәгъли)ланганыннан хәбәрем бар иде»[3].

Г. Тукайның кымыз белән дәвалану өчен сәфәрен Троицки тарафларында дәвам иттерүнең нигезе булган, әлбәттә. Бу уңайдан Нигъмәтҗан Гафуров (1885–?) исемле кешенең шагыйрь тормышын һәм иҗат мирасын өйрәнүче галимнәрнең берсе булган Сәгыйть Исәнбаевка (1895–1972) 1961 елның ундүртенче мартында Нәманган шәһәреннән юллаган хатында шактый кызыклы мәгълүмат табарга мөмкин: «...1912 нче ел язында Троискинең Габдерахман хәзрәт Рахманкулов Уфага барган иде: «Шунда Тукайны күрдем, үземезгә Троискигә кымыз эчеп ятуга кил дип чакырып кайттым, озакламый килеп калыр», — дип сөйләгән иде»[4].

Аның турында шагыйрь күрсәтелгән мәкаләсендә шулай аңлата: «Мине кымыз өчен Уфага бару фикереннән кайтаручы вә андагы кымызның ясалмалылыгын сөйләүче вә яз көне кымыз эчәргә үзенә чакырып вәгъдә алып килүче ошбу Габдерахман хәзрәт иде»[5]. Әмма аларның сөйләшү-килешүләре ни рәвешле булганлыгын хәзергә әйтү мөмкин түгел: хәзрәт Г. Тукай белән кайда очрашканлыгы турында мәгълүмат юк.

Г. Тукай Уфадан Троицкига 1912 елның унбишенче маенда китә. Аны тимер юл вокзалында мөгаллим, булачак тарихчы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Габделбарый Баттал (1880–1969) озата. Аларның беренче тапкыр очрашулары да әлеге шәһәрдә була. Бу хакта шагыйрь үзенең «Мәкаләи махсуса»сында болай яза: «...Г. Баттал әфәнденең үткен вә искренный интикадларын[6] укыганым булса да, биззат[7] күргәнем юк иде. Бу юлы Уфада аны күрдем...»[8].

Г. Баттал искә алганча, ул Г. Тукайны күрергә «Сабах» ширкәте кибетенә М. Гафури белән ундүртенче май көнне махсус барган; озак кына дустанә сөйләшеп утырганнар. Унбишенче май көнне икесе генә бер извочикка утырып тимер юл вокзалына баралар. Әмма билет Чиләбегә кадәр булып, поезд Троицки янындагы Полетаево станциясендә туктамаячагы ачыклангач, Г. Баттал шагыйрьне каршы алу өчен Чиләбедәге танышы сәүдәгәр Закир Галиевкә (1856–1919)[9] телеграмма җибәрә.

Поезд киткәнче вакыт булудан файдаланып, алар беренче класс залына кереп чәй эчеп, сөйләшеп утыралар. Г. Тукай юлда уку өчен «Сатирикон»[10], «Будиль-

---

[1] *Биттабгы* — табигый.

[2] *Искусственный* — кирилл хәрефләрендә шулай язылган.

[3] Тукай Г. Мәкаләи махсуса… — Б. 56.

[4] [Нигъмәтҗан Гафуров истәлеге] // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 698.

[5] Тукай Г. Мәкаләи махсуса... — Б. 64.

[6] *Интикадларын* — тәнкыйтьләрен.

[7] *Биззат* — үзен.

[8] Тукай Г. Мәкаләи махсуса... — Б. 62.

[9] Бу могтәбәр зат турында тәфсыйле: Миңнуллин Ж. Кем ул Закир Галиев? / Ж. Миңнуллин // Безнең мирас. — 2015. — № 12. — Б. 24–26.

[10] *«Сатирикон»* — 1908–1914 елларда Санкт-Петербургта нәшер ителгән атналык сатирик журнал. Г. Тукай әлеге басмадагы материалларны үзенең иҗатында файдаланган.

ник»[1] дигән сатирик журналлар сатып ала. Шагыйрь ул көнне авыру була. Г. Баттал тал Омскига баручы бер татар сәүдәгәреннән аны карап баруын үтенә[2].

Чиләбегә килү һәм аннан соңгы вакыйгалар Г. Тукай тарафыннан «Мәкаләи махсуса»да җентекле тасвирлана[3].

Чиләбедә Г. Тукайны, сөйләшкәнчә, З. Галиев каршы ала һәм Полетаево станциясенә баручы бер приказчик атына утыртып җибәрә, ә аннан шагыйрь Троицкига поездда китә.

Г. Тукайны станциядән Г. Рахманкуловның кодасы Хәкимҗан Бакиров (?–?) килеп ала һәм, ул үзе язганча, әүвәл туп-туры хәзрәтнең шәһәрдәге өенә төшә. Ә Белгуар Учаров мәкаләсендә бәян ителгәнчә, Г. Тукайны хәзрәтнең дачадагы йортына алып киләләр һәм ул анда берничә көн кунак була, соңыннан да даладан Троицкига килгәләп йөргән, анда башка кешеләр белән очрашкан, дип, тагын мондый бер фактны өсти: «Тукай шәһәрдә булганда мотлакан Фәйзерахман Черкасовның китапханәсендә һәм китап кибетендә булган. Китап кибетендә Тукайга утырып китаплар белән танышу өчен махсус өстәл һәм урындык куелган»[4].

Монда никадәр хаклык бардыр, анысын әйтүе кыен. Әмма Ф. Черкасовның чынлыкта булганлыгы турында язучы Атилла Расихның (1915–1996) «Ишан оныгы» исемле китабыннан да укып белергә мөмкин: «Менә шулай безнең гаилә белән аралашучылар арасында көннәрдән бер көнне Фәез абый Черкасов һәм аның хатыны Сәхип апа пәйда булды. Фәез абзый зур колаклы, кара тутлы калын кара мыеклы кеше иде. Ул ифрат күңелле, «мәҗлес күрке» дип аталучылардан. Фәез абый күбрәк шәкерт тормышыннан бик көлкеле анекдотлар, вакыйгалар сөйләп мәҗлестәгеләрнең эчләрен катырып көлдерә. Сәхип апа да алдынгы хатыннардан, заманында үзешчән спектакльләрдә катнашкан, бик ачык күңелле апа»[5].

Халык музыканты Исмәгыйль Һилалов (1898–1992) истәлегендә башкачарак мәгълүмат китерелә: «1912 ел. Май аеның бер көнендә Ибраһим абый өйгә ашыгып, дулкынланып кайтып керде дә: «Безнең Троицкига Габдулла Тукай килгән. Хәкимҗаннарга төшкән, аларда бер кич кунган. Әле генә шунда бергәләп чәй эчеп кайттым!» — диде»[6]. Х. Бакиров исә, Троицкида яшьләр тарафыннан оештырылган «Театр-музыка һәвәскәрләре җәмгыяте» җыйнала торган йортның хуҗасы була.

Аннары И. Һилалов энесе Исхак белән Хәкимҗаннарга барып, мандолина һәм скрипкада Г. Тукайга «Тәфтиләү», «Сүнде дәрт» һәм башка көйләр уйнап күрсәтүләрен яза.

---

[1] *«Будильник»* — 1865–1871 елларда Петербургта, 1873–1917 елларда Мәскәүдә нәшер ителгән демократик юнәлештәге сатирик журнал. Г. Тукай әлеге басмадагы материалларны үзенең ижатында файдаланган.

[2] Баттал Г. Габдулла Тукаев (Искә төшерү) / Г. Баттал // Кояш. — 1913. — 17 апр.

[3] Тукай Г. Мәкаләи махсуса... — Б. 63–64.

[4] Учаров Б. Тукай в Троицке: К 120-летию со дня рождения / Б. Учаров // Звезда Поволжья. — 2006. — 22–28 апр.

[5] Расих А. Ишан оныгы: Роман-истәлек, беренче китап / А. Расих. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. — Б. 60.

[6] Һилалов И. Троцкида килү һәм китү көннәре / И. Һилалов // Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — Б. 67.

Хәзер игътибарны Ибраһим Һилалов (1895–1981) истәлегенә юнәлтик: «...Укучыларга билгеле булганча, Тукай 1912 елның май аенда кымыз эчеп дәвалану теләге белән Троицкига килә. Ул чакта Троицки яшьләренең көн дә дип әйтерлек җыелыша торган урыны булып Васильев тыкрыгындагы бишенче номерлы йортта урнашкан театр, музыка һәвәскәрләре җәмгыяте санала иде. Йортның хуҗасы (безнең кебек үк яшь егет) Хәкимҗан Бакиров үзе дә музыканы, театрны, әдәбиятны бик ярата торган кеше иде. Май аеның иртә бер көнендә мин Хәкимҗаннарга килеп кердем. Өстәлдә иртәнге чәй әзерләнгән. Хәкимҗан үзе аш-су әзерләшеп йөри. «Бездә зур кунак бар, Габдулла Тукай килде, — диде ул, дулкынлануын баса алмый. — Әйдә, утыр, бергә-бергә чәйләп җибәрербез...

Күп тә үтмәде, бүлмә ишеге ачылып, аннан кара чалбар һәм шундый ук кара жилет кигән Тукай үзе килеп чыкты. Без аңа хәерле иртә теләп исәнләштек, Хәкимҗан: «Кандалалар бик борчымадымы, Тукай әфәнде?», — дип сорады. Тукай сызганылган җиңнәр астындагы ябык беләкләрен тотып: «Алар өчен миндә азык юк бит, коры тире белән сөяктән әлләни кинәнә алмадылар», — дип көлеп куйды.

Чәй янында ул юл хәлләрен, Петербургта, Уфада булуы хакында сөйләп

утырды. Шул вакыт ишек алдына пролеткага җигелгән аргамак ат килеп туктады, кучер өйгә килеп керде һәм Хәкимҗанга бер записка тоттырды. Хәкимҗан записканы кычкырып укыды. «Хәкимҗан әфәнде! Кунагыгыз Габдулла әфәнде Тукай белән шушы җибәргән атта безгә чәйгә рәхим итегез» диелгән иде анда. Записканы Муллагали[1] дигән кеше җибәргән икән. «Ат-арбасына караганда, бер бай кеше булырга тиеш», — дип куйды Тукай. «Әйе, каланың иң мәшһүр байлары булган Яушевларның иң өлкән туганнары», — дип җавап бирде Хәкимҗан.

Тукайның бераз кәефе кырылды, йөзе җитдиләнә төште. Бүлгән чәен эчеп бетергәч: «Андый бай йортка барырга минем киемнәр бер дә лаек түгел бит әле: сюртук — пәке янырлык булган... Аннан соң, ул зур бай белән нәрсә хакында гына сөйләшеп утырырбыз икән? Әллә бармый калсак та ярармы?» — дип, ул Хәкимҗанга карады. «Бармый калу килешмәс, Габдулла әфәнде, без анда бер сәгатьтән дә артык утырмабыз», — диде Хәкимҗан. «Кунак — хуҗаның ишәге. Йорт хуҗасының сүзен егып булмый инде», — дип, ул теләр-теләмәс кенә торып киенә башлады.

Мин аларны озатып калдым.

Шул көнне кич Хәкимҗан Тукайны кымызга — Габдерахман Рахманкуловның дачасына илтеп куйды. Хәкимҗан Бакиров дача хуҗасы Рахманкуловларның кода-

[1] Шагыйрьне ихтирам итеп үзенә кунакка алдырган Муллагали Яушев (1864–1926) танылган бай сәүдәгәр Яушевларның берсе булып, 1910 елда ук Троицк өязендә аның 1131 дисәтинә җире була. 1915 елда коммерция киңәшчесе дигән дәрәҗәгә лаек була. Ул — Троицк мөселман җәмгыяте хәйриянең шәрәфле әгъзасы, 1907–17 елларда аның рәисе. 1909 елда Костанай шәһәрендә мөселман җәмгыяте хәйриянең, 1914 елда башлангыч уку йортларында тәрбияләнүчеләр өчен җәмгыятьнең оештыручысы була. Санкт-Петербург Җамигъ мәчетен төзү өчен 1000 сум акча бирә. «Айкап» дигән казакъ журналын нәшер итү өчен чыгымнар тота. Туганнары белән Троицкида 1901 елда рус классын 2 нче рус-татар классына әверелдерүгә ирешә, бер үк вакытта 4 класслы 2 нче шәһәр училищесының шәрәфле назире була. Аның акчасына 1915 елда Троицкта «Дар әл-мөгаллимин», ягъни мөселман ирләр педагогия училищесы ачыла. 1914–17 елларда Троицк өяз земство собраниесенә сайлана.

сы иде. Станцияга барып, Тукайны каршы алу, дачага озатып кую Хәкимҗанга кодасы тарафыннан тапшырылган эш булган булса кирәк...»[1].

Башкортстан матбугатының күренекле эшлеклесе Мөхәммәт Бикбулатовка (1899–1961) Троицкида туып-үскән Сәкинә Гыйрфанова (?–?) шагыйрьне тимер юл вокзалында каршы алу моменты турында үткән гасырның алтмышынчы елларында кызыклы мәгълүмат сөйләгән: «Менә бер вакыт поезд килеп туктады. Без вагоннан зур гәүдәле, өстенә купшы киенгән, ак якалы, мәһабәт бер кеше чыгар дип көтәбез. Ләкин нык ялгыштык. Аннан кечкенә буйлы, ап-ак чырайлы, ябык, башына кара кәләпүш, ак яка белән костюм өстеннән казаки кигән бер егет килеп чыкты. Бу Габдулла Тукай иде. Без аны котладык һәм чәчәкләр бирдек. Ул безнең кайсыларыбызның аркасыннан сөйде. Шуннан соң аны извозчикка утыртып алып киттеләр»[2].

Габдерахман хәзрәт белән кәсептәш, Троицкидан егерме чакрым ераклыкта, чишмәле үзәнлектә урнашкан утар хуҗасы Әхмәтҗан исемле байда үз вакытында асрау кыз булып яшәгән Фәгыйлә апа истәлегенә күрә, Габдерахман хәзрәтнең җәйләве Әхмәтҗан байның утарыннан дүрт чакрымда гына булган. «Шагыйрьгә хезмәт күрсәтү өчен әнисе белән бер кыз куела. Алар һәр көнне яңа сугым итеннән ризык, бияләрне савып, яңа кымыз әзерләгән. Вәли исемле яшь казакъ егете шәһәрдән азык-төлек, почта, гәзит-журналлар китереп, Тукайдан хатлар алып китеп торган». Шагыйрь янына бары Габдерахманның энесе Әхмәт белән Вәли исемле Борһан авылы башкортына гына теләсә кайсы вакытта керү рөхсәт ителгән.

Заһидә абыстай белән аның Хәдичә исемле кызы Тукайны кадерле кунакларга гына пешерелә торган тәмле ашлар белән сыйлыйлар. Шушы Хәдичә апаның улы — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, күренекле архитектор Р. Мортазин әнисенең сөйләгәннәрен исенә төшереп, шагыйрьнең аеруча куллама белән тозланган ит ашларын яратып ашаганын, кымызны баштарак дару эчкәндәй өнәмичә-рәк, авырлык белән эчкәнен, ә инде күнегеп киткәннән соң көненә бер чирек, чирек ярым эчә башлавын һәм күзгә күренеп төс керә, төзәлүгә таба барганын әйтә.

Бу мәсьәлә Н. Гафуровның хатында башкача сурәтләнә: «Ул арада берничә көннән соң: «Тукай килгән икән», — дип ишеттем. Габдерахман хәзрәткә өенә Тукай белән күрешергә барсам: «Өйдә бер генә көн торды, үзенең җәйләвенә алып барып куйдым», — диде. Аннан Тукайны күрү өчен далага киттем.

Габдерахман хәзрәтнең Троискидан 25 километр ераклыкта бик матур җирләре бар иде. Шунда маллар асрап, кымыз саудырып тора иде. Мин барып күрдем: ямь-яшел чирәм, үлән шау чәчәк матур урынга Тукайга бер палатка корып биргән. Янына хезмәткә, йомыш юлына Габдерахман дигән бер егет (Вәлиевләр приказчигы) куелган иде. Мин беренче күрүем бит: ябык, хәлсез иде, бик аз сөйләшә, сораган сүзләргә дә кыска гына җавап кайтара. «Минга сахра охшады, кымызны да бик яратып эчәм, яшь кузы итләре дә минга якты әле. Монда килгәнемә 4 кенә көн булса да, яхшук хәл керде, йоклыйм да, ашый да башладым», — дип яратып сөйләде...

Озак тормадым, китәргә тугры килде. Янындагы карап торучы егет Габдерахман белән сөйләштем. Ул сөйләде: «Аспиринны бик күп эчә, көненә 2–3 мәртәбә, хәтта,

[1] Һилалов И. Онотолмаҫлык осырашу / И. Һилалов // Совет Башҡортостаны. — 1961. — 26 апр.

[2] Бикбулатов М. Троицкида… / М. Бикбулатов // Кызыл таң. — 1961. 26 апр.

2–3 прашукны берьюлы эчә. «Шул гына мине җылыта, аспирин булмаса, мин туңам...», — ди икән»[1].

Биредә китерелгән кайбер мәгълүмат Г. Тукай тарафыннан үзенең «Мәкаләи махсуса»сында тасвирланганнар белән тәңгәл килә. Шагыйрь анда яза: «...Троискидә берничә көн генә торгач, сахрага, шәһәрдән егерме биш чакрым җиргә киттем. Анда хәзрәт тарафыннан ялланган казакълар аның йөзләп баш биясен савып, бүтән малларын көтеп торалар. Ике киез өйдән гыйбарәт шул казакъ авылына өченчегә миңа махсус чатыр тегелде»[2].

Коры һавалы табигать кочагына барып кергән шагыйрь илһамланып китеп, үзе белдергәнчә, килгәненең беренче көнендә үк «Валлаһи» дигән шигырен иҗат итә:

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!
Ак күмәч берлән ашарлык, саф һава;
Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!
Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
Бер кунышлык күкне сайлый, валлаһи!
Аз гына бер җил исү берлән үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

Г. Тукайга ярдәм итеп торырга куелган егеткә килгәндә исә, Н. Гафуров 1961 елның унбишенче июнендә С. Исәнбаевка күндергән икенче хатта аның турында мондый өстәмә хәбәр бар: «Ул Габдерахман, фамилиясе Мурзин, Троискидән Казанга авылына кайтып киткән икән һәм шунда вафат булган. Адресы: Тукай районы, Иске Ашыт[3] авылы иде. Хатыны Фахирә шул Ашытта үз йортларында тора дип ишеттем»[4].

Троицки байларының ышанычлы кешесе булган Габдерахман Әхмәревнең (1869–1933) кызы Нәҗия ханым (1904–?) әтисенең Г. Тукайны үзләренә кунакка алып кайтуын язып калдырган. Аерым алганда, вакыйга шулай булган: «…Кичен әти Тукайны алып кайтты. Мин гаҗәпләнеп, аптырап калдым: ул минем балачак хыялымда озын буйлы, таза һәм сәламәт булып җанланган иде, чынлыкта исә әти янында яшүсмергә охшаган кечерәк кенә, ябык кына бер егет утыра. Өстендә карарак төстәге җиңел җәйге пальто. Әти Тукайны өйгә алып керде һәм безне, ягъни үзенең дүрт кызын (Сара, Рауза, Зәйнәп һәм Нәҗия — *Р. И.*), аның белән күрештерде.

Алар әти белән икәү утырып ашадылар, әни исә кунак бик аз ашый дип борчылды. Аннан соң без Тукай абыйны көймәдә йөрергә чакырдык, ләкин ул баш тартты. Елгага кадәрге араны җәяүләп үтү аңа авыр булгандыр дип уйлыйм. Ул бездән нин-

[1] [Нигъмәтҗан Гафуров истәлеге]... — Б. 699.
[2] Тукай Г. Мәкаләи махсуса... — Б. 64.
[3] *Иске Ашыт* — хәзер Татарстан Республикасы Арча районында.
[4] Хатның күчермәсе хосусый архивымда саклана — *Р. И.*

ди шигырьләрен белүебезне сорашты. Без теләп җавап бирдек, хәтта кайберләрен җырлап та күрсәттек…»[1].

А. Расих бу гаилә хакында болай дип яза: «Габдрахман абзыйларның бала-чагалары бик ишле иде. Мин белгәне генә әле өч малай, ике кыз. Ләкин минем белән аерата дуслашып киткәне бу балаларның иң кечесе — Үзбәк булды. Мин, билгеле, Үзбәкнең кече абыйсы Чыңгызны[2] да бик яхшы беләм, аның рәссамлыкка укып йөргән чакларын да хәтерлим»[3].

Шагыйрь Троицкида, ягъни кымызда вакытында унберенче июньдә Г. Шәрәфкә ярым оптимист, ярым пессимист эчтәлекле хат яза: «Монда бер тарафта хәлем яхшы, казакъ бае шикелле, иткә тук, кымызга гарык булып торам. Урыным Троискидән 25 чакырым җирдә. Һәр тараф сахра. Ике казакъ өеннән башка бернәрсә дә күренми. Күңелсез, эч поша. Шунысы изә. Авыруым, тагы яңалары башланмаса, бетә инде. Ләкин терелеп нәрсә бар? — дип карыйм каравын. Ач кеше вакытның соң икәнен белсә дә ята, «Торып нәрсә бар?» — ди. Мин дә шулай, өмидем юк»[4].

Уфа шәһәреннән Г. Манафованың (исеме тулы язылмаган) интернетка куйган мәкаләсеннән күренгәнчә, аның әтисе Минһаҗетдин Г. Тукай белән Казанда танышкан булган. Ул далага шагыйрь янына «Айкап»[5] журналының сәркәтибе Әкрам Галиев (1892–1913) мөгаллим Билалетдин Корбангалиев (?–?), приказчик Сафа Кәбиров (?–?), Вәлетдин (?–?) хәлфә белән барып йөргән.

М. Манафов, кызы язганча, әдәбият дөньясына якын кеше булган. Аның шигырьләре, хикәяләре, рус классикасыннан тәрҗемәләре «Акмулла»[6], «Айкап», «Ялт-йолт», «Сөембикә»[7], «Аң»[1], «Кармак»[2], «Шура»[3] журналларында «Бүрекче» че» дигән әдәби псевдоним белән басылган.

---

[1] Әхмәрова Н. Шагыйрьне без дә күрдек / Н. Әхмәрова // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 728.

[2] *Чыңгыз* — Мөхәммәтчыңгыз Габдрахман улы Әхмәров (1912–1995), нәкышьче, график, монументаль сәнгать рәссамы, сәнгать фәннәре кандидаты (1949), профессор (1970), Үзбәкстан ССРның һәм Татарстан Республикасының халык рәссамы (1964, 1992).

[3] Расих А. Ишан оныгы... — Б. 119.

[4] Гыйльметдин Шәрәфкә // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 118.

[5] *«Айкап»* — 1911–1915 елларда Троицк шәһәрендә айга бер, соңыннан ике мәртәбә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журнал. Беренче мөхәррире акын, журналист Мөхәммәтҗан Сералин (1872–1929).

[6] *«Акмулла»* — 1911 елның 15 июленнән 1916 ның 29 гыйнварына кадәр Троицк шәһәрендә айга ике мәртәбә татар телендә нәшер ителгән сатирик-юмористик, рәсемле журнал. Барлыгы 51 саны дөнья күрә.

[7] *«Сөембикә»* — 1913 елның 27 октябреннән 1918 нең 8 гыйнварына кадәр Казанда татар телендә айга ике тапкыр нәшер ителгән хатын-кызлар өчен рәсемле журнал. Барлыгы 115 саны дөнья күрә.

Рәүф Рәсүлев (1902–?) (Зәйнулла ишан оныгы) шагыйрьне җәйләүдә күрүен шулай искә ала: «1912 елның язында минем дәүәни белән Фатиха Аитова апаның әнисен дачага кунакка чакырдылар. Дәүәни мине дә үзләре белән алды. Тарантаслы атка утырып юлга чыктык. Шәһәрдә Габдерахман Рахманкулов йорты яныннан үттек. Байларның дачалары шәһәрнең шау-шуыннан читтә салынган. Шәһәрдән чыккач, уңда «Золотая сопка» дип аталган агачлы таулык калды. Кырдан барабыз. Бераздан яшеллеккә күмелгән калкулык күренде. Шунда дачалар урнашкан. Менә безнең алда бакча белән әйләндереп алынган бер катлы матур йорт. Бу Троицкидагы Габдрахман Рахманкулов дигән мулланың дача йорты.

Соңрак Тукай Троицкига килеп төшә. Габдрахман мулла дачасына киләләр. Анда шау-гөр, «көн дә бәйрәм, көн дә туй» дигәндәй, көн дә кунак яки мәҗлес. Билгеле, Тукай бу мохиттә яшәргә теләми. Дачадан ераста, яшел чирәмле далада аңа аерым чатыр корыла.

Без ат юырттырып даладан барабыз. Шулчак минем дәүәни: «Габдрахман мулла шагыйрь Габдулла Тукаевны Казаннан махсус үзенә чакыртып алдырган. Аның махсус үзенә дип чатыр кордырткан. Әнә карагыз!» — дип бер якка төртеп күрсәтте. Яшел чирәмле далада зур, биек күгелҗем төстәге чатыр күренә иде. Чатырның ишек чабулары күтәрелеп бәйләнгән. Аның янында бер артсыз урындык. Шунда зуррак малай сыман ябык кына бер кеше утырып тора. Дәүәни: «Әнә, кара, улым, Габдулла Тукаев дигән кеше шул була инде», — диде. Без юыртып узып киттек. Ара алай ерак булмаса да, Тукай безгә әз генә дә игътибар итмичә, уйланып утырып калды»[4].

Истәлекләрдән аңлашылганча, Г. Тукай далада чатырда яшәү белән генә чикләнмәгәнгә охшый. Фәгыйлә апа шагыйрьнең кичләрен гел утарга Әхмәтҗан бай өенә кайтуы турында сөйли. Ул шагыйрь мунча кергән саен керләрен юып үтүкләгән, урын-җирен, бит сөлгеләрен алыштырган; кымызны, ашау-эчүләрне вакытында тәэмин иткән.

Г. Тукайның җәйләүдән шәһәргә килгәләп йөргәнлеге турында Ш. Рахманкулов та яза: «Әйтик, ул җәйләүдән кайтып Хәкимҗан Бакировларда куна, шәһәрнең могътәбәр зыялылары булган Габдрахман Әхмәров белән Зариф Рахманкулов дачасына барып берничә көн торып кайта, мәшһүр җырчы Мирфәйзә Бабажанов йортында да кунак була. Г. Әхмәров һәм З. Рахманкуловлар дачасына баруыннан бик

---

[1] *«Аң»* — 1912 елның 15 декабреннән 1918 нең мартына кадәр Казанда татар телендә айга ике тапкыр нәшер ителгән әдәби-фәнни, иҗтимагый-сәяси рәсемле журнал. Барлыгы 123 саны дөнья күрә.

[2] *«Кармак»* — 1915 елның гыйнварыннан 1917 нең сентябренә кадәр Оренбургта татар телендә айга ике тапкыр нәшер ителгән әдәби-сәяси, рәсемле сатирик-юмористик журнал. Барлыгы 60 саны дөнья күрә.

[3] *«Шура»* — 1908 елның 10 гыйнварыннан 1917 нең 31 декабренә кадәр Оренбургта татар телендә айга ике тапкыр нәшер ителгән иҗтимагый-агарту, әдәби-публицистик журнал. Барлыгы 240 саны дөнья күрә.

[4] Рәсүлев Р. Далада / Р. Рәсүлев // Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — Б. 65–67.

канәгать булып, ошатып кайтуы турында җәйләүгә кайткач аш пешерүче Хәдичә апага да сөйли».

Шагыйрь ара-тирә башка җирләргә дә баргалаган икән. Мәсәлән, үз вакытында Троицкида Х. Бакировта приказчик булып эшләгән Хәлим Бикчәнтәев (?–?) исемле кеше дә шагыйрь белән очрашу тәэсоратлары турында М. Бикбулатовка шулай сөйләгән: «1912 елның июнь көннәре иде, мин Троицки байларыннан берсе булган Хәкимҗан Бәкировта приказчик булып эшли идем. Аның моннан йөз километр чамасы ераклыктагы Кушкүл авылында да магазины бар иде. Без шунда сату итә идек. Бер көнне шагыйрь Габдулла Тукай шушы тирәдә, моннан биш-ун чакрымда гына, бер казакъ авылында кымыз эчеп ята икән, якын көннәрдә безнең Кушкүлгә киләчәк икән дигән хәбәр таралды. Бу хәбәрне ишеткәч, без чиктән тыш шатландык. Шуңа күрә дә берничә көн үтү белән шагыйрьне каршыларга бөтен авыл дип әйтерлек чыкты. Гади киенгән ябык кына, ләкин көләч йөзле яшь кеше, тарантастан егетләрчә җиңел генә сикереп төште дә, халык белән исәнләште. Әйе, бу чыннан да ул иде. Без Тукайны таныдык. Чөнки аны китапларда, журналларда басылган фоторәсемнәрдә күп тапкырлар күргән идек.

Кич без аның туктаган фатирына бардык. Шагыйрь авыру, аның өстенә арыган, йончыган иде. Без, хәтта, ул безнең белән сөйләшмәс дип тә уйладык. Бер минутта гына, нигә аны борчып, бүген үк килүебезгә дә үкендек. Ләкин ул без баргач, гүя бөтенләй хәлләнеп киткән төсле, ачык йөз белән сөйләшә башлады. Безнең сорау буенча, үзенең яңа шигырьләрен укыды.

Без иртәгә яңадан килергә булдык һәм Тукайны безнең белән күлдә көймәдә йөзәргә чакырдык. Тукай берсүзсез риза булды. Тукай белән көймәдә йөрергә чыктык. Көн гаҗәп тын. Күл өсте чиксез зур көзге шикелле ялтырап ята. Шагыйрь ерак офыкка карый, ара-тирә көймәдән кулын сузып суны ярдырып бара.

Без күлнең аръяк ярына чыгарга, андагы чәчәкләр дөньясын шагыйрьгә күрсәтергә булдык. Чәчәкләр дигәч, Тукайның йөзе әсәреп киткәндәй булды. «Барабыз, барабыз», — диде ул.

Тукай чәчәкләргә гашыйк булган шикелле, аларга текәлеп карады һәм,

үзе дә белешмичә булса кирәк, шул чәчәкләргә карап бер шигырь әйтеп алды. Бераз болында йөргәннән соң, без авылга кайттык.

Көннәр үтте. Тукайга китәргә вакыт җитте. Ул Троицки аша Казанга кайтырга ашыга иде»[1].

Монда буталчыклар күзгә бәрелеп тора. 100 чакрымдагы Кушкүл авылы ничек Троицкидан 25 чакрымдагы җәйләүгә 5–10 чакрым гына булып чыга? Шактый гына авыру шагыйрьнең «көләч йөзле яшь кеше» кыяфәтендә «тарантастан егетләрчә җиңел генә сикереп төшүе» дә бик үк ышандырып бетерми. Фәгыйлә апа истәлегенә күрә, хәтта, «ике айга якын дәваланыга карамастан, шагыйрьнең хәле җиңеләймми, савыгу сизелми...».

Н. Әхмәрева истәлегендә шулай ук шагыйрьне көймәдә йөздерү теләге булу һәм аның гамәлгә ашырыла алмавы турында бәян ителә: «...Дачадан ерак түгел генә елга ага... Без корган план буенча Тукайны көймәдә йөртү күздә тотыла иде. Шуңа

[1] Бикбулатов М. Троицкида… / М. Бикбулатов // Кызыл таң. — 1961. 26 апр.

дип без көймәне рәткә кертергә тотындык... Аннан соң без Тукай абыйны көймәдә йөрергә чакырдык, ләкин ул баш тартты. Елгага кадәрге араны җәяүләп үтү аңа авыр булгандыр дип уйлыйм»[1].

Г. Тукай үзенең язмасында болай ди: «Ике киез өйдән гыйбарәт шул казакъ авылына өченчегә миңа махсус чатыр тегелде»[2]. Әгәр сүзләре хак булса, Р. Рәсүлев тә шулайрак искә ала: «Яшел чирәмле далада зур, биек күгелҗем төстәге чатыр күренә иде. Чатырның ишек чабулары күтәрелеп бәйләнгән». Фәгыйлә апа мәгълүматыннан да шул ук аңлашыла: «...казакъларның киез өйләре янында, хәзрәт кушуы буенча, Тукайга да бер чатыр корып куелган»[3].

Инде Г. Тукайның Троицкидан китү вакыйгасы истәлекләрдә тасвирланышына игътибар итик. И. Һилалов бу хакта болай дип яза: «Троицк халкы җәйге кичләрен шәһәр бакчасында ял итә. Анда музыка, танцылар була. Шунда яшьләр җыела.

Бер көнне бакчага ак якадан, күбәләк галстуктан, иңнәренә җиңелчә генә накидка салган, инде озын гына үскән чәчле Тукай абый килеп керде. Без, малайлар, аны күрү шатлыгыбыздан ни дияргә дә белми торганда, аны шундук шау-гөр килеп яшьләр әйләндереп алды. Безгә ул көнне Габдулла Тукай абый белән күрешергә насыйп булмады.

Бу — Тукай абыйның кымыздан кайтып, Троицкидан китү вакыты булган»[4].

Г. Тукай Троицкидан киткәндә, Фәгыйлә апа сүзләре буенча, шагыйрьне Әхмәтҗан байның җәйге ялга кайткан улы «Бәхтияр җиңел тарантаска утыртып станциягә илтә һәм бәла-казасыз төнге поездга утыртып җибәрә».

Н. Гафуров исә үзенең истәлегендә вакыйганы шулай тасвирлый: «...Шәһәремдә бер көнне бер иптәшем Фәйзерахман Вәлиев килде. «Бүген кич Тукай китә, шуны озатамыз. Күз күргәннәрдән 15 сумнан акча да җыеп алдык, кая 15 сум акча бир», — диде. Дәррәү ун сум бирдем. Җәмгы 20 кешедән ике йөз сум акча җыелган икән.

Пуйыз кич китәсе. Озатуга вакзалга бардык. Вагунга кереп күрешеп хәлен сораштык. «Инде күп яхшы булдым», — дип сөйләде. Шунда мәгълүм акчаны Вәлиев Тукайга бирсә, алмады. «Минга акча кирәкми. Билит алынган, мин нишләтим аны?», — ди. Кулына алмагач, Вәлиев көчләп акчаны эчке куен кесәсенә салып куйды.

Ул арада свистук, пуйыз кузгала башлады. Тизрәк төшеп калдык. Шул ахыр күрү булды»[5].

Г. Тукайны кымыз белән дәваланырга Троицкига чакырып китергән һәм илтифат күрсәтеп аңа тиешле яшәү шартлары булдырган Г. Рахманкуловның шәхесенә килгәндә исә, ул гарәп илләрендә белем алган, шәһәрдәге 6 мәчетнең өченчесендә икенче имам була. 1912 елдан — шәһәрнең мөселман җәмгыяте хәйрия идарәсе әгъзасы. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында мөселманнар арасында патриотизм тәрбияләүдә зур эш алып бара. Әхлак-этика темасына язган шигырьләре урындагы

[1] Әхмәрова Н. Күрс. хезм. — Б. 728.

[2] Тукай Г. Мәкаләи махсуса... — Б. 64.

[3] Рәсүлев Р. Далада... — Б. 66.

[4] Һилалов И. Күрс. хезм.

[5] [Нигъмәтҗан Гафуров истәлеге]... — Б. 699.

матбугатта басыла. 1928 елда ул янә шул ук мәчеттә имам вазифасын башкара. Р. Рәсүлев истәлегеннән күренгәнчә, «Габдрахман мулла үзе зур гәүдәле, кара чәчле, кара мыеклы, җырлаганда гөрләп торган көр тавышлы, уен-көлке, дан яратучан, һәрчак шат күңелле кеше» кеше була. 1937 елда кулга алына һәм Себергә сөргенгә озатыла.

Язучы Сафа Сабиров (1915–2004) моннан байтак еллар элек бу могътәбәр зат турында мондый фикерләр белдергән иде: «Ә кара реакция вакытында авыру шагыйрьне курыкмыйча казакъ даласына кымыз белән дәваланырга чакырып китергән, аңа уңай шартлар тудырган, аның иминлеге турында кайгырткан Рахманкулов Габдрахманны әдәбиятчылар арасында җылы сүз белән телгә алучы да юк. Хәтта, киресенчә, яманлаучылар да булган. Г. Ибраһимов, мәсәлән, үзенең егерме бишенче елны чыккан «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» дигән китабында башка иттифакчылар белән берәттән, Рахманкуловка да «буржуаз милләтче» дигән мөһер сугып үтә»[1].

Г. Тукайның моннан йөз елдан артык элек булган тарихи сәфәрләрен яңа табылган һәм фәнни кулланылышка беренче тапкыр кертелгән истәлекләр ярдәмендә кыскача менә шулай күзалларга мөмкин. Шагыйрьнең тәрҗемәи хәленә караган ул сәхифәләр киләчәктә тагын да киңрәк һәм тәфсиллерәк ачыкланыр дип ышанасы килә.

V

1913 елның февраль айларында Г. Тукайның хәле кая таба барганын яхшы аңлаган дуслары үзара 350 сум акча җыйнап, Клячкин шифаханәсенә алдан түләп куялар һәм озакламый шагыйрьне шунда урнаштыралар.

Матбугатта Г. Тукайның хәле турында мәгълүмат бирелеп барыла. «Кояш газетасы» 1 март санында шулай яза: «Мәшһүр шагыйрьләремездән кадерле иптәшемез Габдулла әфәнде Тукаев җәнапләре авыруы куәтләнү сәбәпле, Клячкин шифаханәсенә озатылды»[2]. 3 март санында аның хәле берникадәр яхшылуы турында хәбәр ителә. «Берәү» тәхәллүсле бер автор шагыйрь янына махсус баруын белдереп, болай ди: «Шифаханәдә ята башлавына тиздән бер ай була. Янәдән бер ай шунда калып май башларына таба Кырымга яки кымыз эчәргә Уфа тарафына китәргә уйлаганыны аңгартты. «Шифаханәдә татар газета-журналларыны һәммәсене диярлек алдырам, бер дә калмый укыйм, укырга йитми», — ди. Матбугатның барышы, андагы йитешмәгән йирләре хакында кайгыртып сөйли»[3].

1 апрель көнне аның хәле авырлаша. «Шул көндә дуктыр да «Авыруның хәле начар, озак торса, өч көн торыр, алайга да бармас, сез инде аны ташламаңыз, дуслары җыелышып бер тәртип илә һәрвакыт береңез янында булыңыз», — дия тәнбиһ итте[4]. Шуннан соң чиратлашып янында торыла башлады»[1], — дип яза Ш. Әхмәров үзенең истәлегендә.

---

[1] Сабиров С. Алтын балдаклы абыстай / С. Сабиров // Казан утлары. — 2001. — №. 10. — Б. 6.

[2] Габдулла Тукаев // Кояш. — 1913. — 1 март.

[3] Берәү. Авыруларымыз янында // Кояш. — 1913. — 24 март.

[4] *Тәнбиһ итте* — кисәтте.

Г. Тукай кичке 8 сәгать 15 минутта бакыйлыкка күчә.

Шагыйрьне соңгы юлга озату чарасы «Мәктәп»[2] журналының 1913 елгы 4 нче санында «Казанда 4 нче апрель», «Кояш» газетасының шул ук елгы 7 апрель санында «Тукаевны озату мәрасиме», «Йолдыз» газетасының 7 апрель санында «Тукаевны дәфен», «Вакыт» газетасының 10 апрель санында Г. М. имзасы белән басылган «Габдулла Тукаевның җеназа мәрасиме (Үз мөхбиремездән)» мәкаләләрендә бәян ителә.

Ун меңгә якын кеше катнашкан бу кайгылы вакыйгада кемнәр генә булмаган!.. Кызганыч ки, без бу хакта бик аз беләбез. Чөнки үз вакытында һәм аннан соң да әлеге мәсьәлә, нишләптер, тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә кала килгән.

Мәрхүмне соңгы юлга озату эшләрен башкару өчен аның якын дусларыннан, яшьләрдән махсус комиссия төзелә. 3 апрель көнне ул үзенең вазифасын үти башлый. Ул хакта «Йолдыз» газетасы шулай яза: «Бу һәйят аның вафаты хәбәрен Русиядәге мөселман гәзитәләре идарәләренә һәм Истанбул гәзитәләренең бәгъзеләренә телеграм белән белгертте вә дәфен кылу эшләрен мөкәммәл рәвештә йиренә китерде»[3]. Бөтен шәһәр сөекле шагыйре белән хушлашырга әзерләнә.

4 апрель көн вакыйгасы турында әүвәл «Мәктәп» журналындагы мәкаләгә мөрәҗәгать итик. Анда бу хакта менә ни әйтелә: «Җыелган халыктан Габдулла әфәндене күреп калырга теләүчеләргә кереп, күреп чыгарга рөхсәт бирелә.

Халык берсе артыннан берсе керә, Габдулла әфәнде илә видаглашып[4], авыр сулап чыгып китә. Габдулла әфәнде чәчәк эчендә көлгән кыяфәттә, үзенә махсус булган бер голүвият[5] илә ята, ул гүя дөньядан китүенә бер дә кайгырмый, ул аны көлеп кенә каршы ала төсле тоела.

Халык чыгып бетә, шул урында Габдулла әфәнденең йөзе ачык хәлдә ахыргы рәсеме, соңгы ядкяре алына»[6].

Язмадан аңлашылганча, мәрхүмнең җәсәде бина эченнән алып чыгылгач, икенче тапкыр фотога төшертелгән: «Шифахәнә ишек алдында, җеназа җирдән күтәрелгәч, тагы бер мәртәбә рәсеме чыгартыла. Гакыйбәт, җеназа урамга чыга, халык шылт итми, тын»[7].

Мәрасимнең өченче фотосы Печән базары мәчете каршында алдырыла: «...Моннан соң җеназа Университет урамы илә борылып, Печән базарына чыга; монда халык һич урамга сыеша алмый. Өй түбәләре, кибет алдындагы күләгәлек өстләре халык вә тамашачылар илә тула.

---

[1] [Әхмәров Ш.] Габдулла әфәнденең авыруы // Мәктәп. — 1913. — № 4. — Б. 108.

[2] *«Мәктәп»* — 1913 елның 21 февраленнән 1914 нең 17 октябренә кадәр Казанда айга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителгән фәнни-педагогик журнал. Барлыгы 25 саны дөнья күрә.

[3] Тукаевны дәфен // Йолдыз. — 1913. — 7 апр.

[4] *Видаглашып* — хушлашып, саубуллашып.

[5] *Голүвият* — олылык, бөеклек.

[6] Казанда 4 нче апрель // Мәктәп. — 1914. — № 4. — Б. 110.

[7] Казанда 4 нче апрель... — Б. 110.

Женаза нәкъ Печән базары мәсҗеде каршысына килеп туктый, монда аның тагы рәсеме алына...»[1]. «Кояш» газетасында да бу хакта әйтелә: «Печән базары чатына туктап, җеназаның рәсемен алдылар»[2].

Танылган фотограф Зөфәр Бәшировның мәкаләсеннән күренгәнчә, фотода билгеле булганнардан Ә. Урманчиев, Габдулла Гыйсмәти (1883–1938), Фәхрелислам Агиев (1887–1938), Әхмәтгәрәй Хәсәни (1883–1934) төшерелгән. Ф. Агиевтан сул яктагы кешенең Гафур Коләхмәтовка (1881–1918) охшаганлыгы да әйтелә[3]. Ә уң яктагысы аның энесе Каюм Коләхмәтов түгелме икән? Билгеле булуынча, агалы-энеле Коләхмәтовлар шагыйрьнең җеназасында катнашканнар. Бу хакта, мәсәлән, «Кояш» газетасында шулай хәбәр ителә: «Болардан башка урта мәктәп шәкертләре һәм учитель Коләхмәтов тарафыннан да чәчәкләр куелган бу ленталар салынган иде». Ә «Мәктәп» журналында Каюм Коләхмәтовның лентага яздырган шундый сүзләре китерелә: «Якын иптәшем, кадерле дустым Габдулла Тукаевка»[4].

Тикшеренүләребез нәтиҗәсендә фотода иң алда сулда, җеназа тоткасын уң кулы белән күтәргән кешенең Салих Мөхәммәтҗан улы Мөхәммәтҗанов (1881–1930) булганлыгы ачыкланды. Ул Тәтеш өязенә кергән Суыксу (рәсми документларда Казиево-Ключище) авылы (хәзер бу авыл юк) кешесе.

Аның Тукайны җирләүдә катнашуы очраклы гына булганга охшамаган. Чөнки бертуган апасы Хәерелбәнат (1877–1959) һәм җизнәсе сәүдәгәр Шакиржан (1874–1935) Галиевләр Казандагы Яңа Бистәдә яшәгәннәр. Ә үз вакытында нәни Габдулланы асрамага алган аяк киемнәре тегеп сату белән көн күргән һөнәрче Мөхәммәтвәли һәм хатыны, байларга кәләпүш эшләп чыгаручы Газизә нәкъ менә аларга күршедә яшәгәннәр. Шуңа күрә, Салих туганнарына кунакка килгәләгәндә Тукай белән аралашкан булуы ихтимал.

С. Мөхәммәтҗановның язмышы бик аянычлы тәмамлана. Ул совет хакимияте урнаштыру чорында кулак сыйфатында сәяси золым корбаны була. ТАССР Югары суды Президиумының 1962 елның 15 ноябрендәге карары белән аклана.

Юнысов мәйданында Казанның имамнары һәм мөэзиннәре катнашлыгында Яңа Бистә имамы Мөхәммәтзариф Әмирхани (1853–1921) тарафыннан җеназа укыла һәм «...табутны имамнардан күтәртелә вә шунда аның йәнә дә рәсеме чыгартыла»[5]. Аларның хәзергә билгеле булганнары: М. Әмирхани, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен нигезләүче Галимҗан хәзрәт Баруди (1857–1921), Зәңгәр мәчет имамы Ибраһим хәзрәт Халитов (?–?).

Г. Тукайның вафатына егерме биш ел тулу уңае белән Ерак Шәрекъ Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының дини, милли мәркәз мәгариф шөгъбәсе тарафыннан Мукден шәһәрендә нәшер ителгән «Габдулла Тукай. 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән)» дигән китаптагы мәгълүмат бу фотодагы кешеләрне тагын да ачыкларга ярдәм итә. Аерым алганда, китапта ул фото бирелеп, аның астына шулай язылган: «Күтәрүчеләр арасында: Галимҗан әл-Баруди, Ибраһим Халиди, Са-

[1] Казанда 4 нче апрель... — Б. 110.
[2] Тукаевны озату мәрасиме // Кояш. — 1913. — 7 апр.
[3] Бәширов З. Соңгы юлга озатканда / З. Бәширов // Мирас. — 1993. –№ 4. — Б. 69.
[4] Казанда 4 нче апрель... — Б. 112.
[5] Казанда 4 нче апрель... — Б. 111.

лихҗан Баруди, Кәшшаф Тәрҗемани[1], Зариф Әмирхан, Әхмәтҗан Мостафа хәзрәтләр, «Юл»[2] көтебханәсе сахибләреннән[3] — Әхмәд Урманче, «Гасыр»[4] көтебханәсе сахибләреннән — Әхмәдгәрәй Хәсәни, «Сабах» көтебханәсе сахибләреннән — Шиһаб Әхмәр әфәнделәр бар»[5]. Димәк китапны төзүчеләр ул кешеләрне белгән яки мәгълүматны башка чыганаклардан алган.

Дөрестән дә, И. Халидинең сул ягында С. Баруди сурәтләнгән. Ул Г. Барудиның бертуган энесе, Казандагы 10 нчы мәчет имамы һәм мәдрәсә мөдәррисе. Җәдиди мәдрәсәләр өчен мөгаллимнәр әзерләү максатында «Мөхәммәдия» каршында 1907 елның 2 нче маенда курслар оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе була. Хөр фикерләр белдергәне өчен ул 1908 елның 8 нче маенда Вологда губернасына сөргенгә җибәрелә. Анда абзыйсы, Габдулла Апанаев (1862–1919), Габделхәмит Казаков (1877–1938) белән бергә төшкән фотосы саклана. Җеназа вакытында алдырылган сурәтне ачыклауда ул да ярдәм итте.

Китапта бәян ителгәнчә, М.-З. Әмирханиның сул ягында, Г. Барудиның артындагы имамның исеме Ә. Мостафа. Әмма аның нәкъ ул икәнлегенә инану өчен кайбер мәсьәләләрне хәл итү сорала.

«Мәдрәсәләрдә китап киштәсе: Мәшһүр мәгърифәт үзәкләре тарихыннан» (1992) дигән китапта тарихчы Равил Әмирханов (1946–2006) очеркына иллюстрация буларак «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәренең күмәк фотосы урнаштырылган. Беренче рәттә сулдан уңга дүртенче Ә. Мостафин икәнлеге һәм фото 1915 елда алдырылганлыгы язылган. Ләкин шунысы аңлашылып бетми: Г. Баруди анда шактый яшь, хәтта сакалсыз сурәтләнгән. Ә 1913 елда Г. Тукайны җирләгәндә алдырылган фотода ул инде сакалына чал керә башлаган илле алты яшьлек кеше. Ә Ә. Мостафа, киресенчә, өлкән кыяфәттә. Күренә ки, монда ачыклыйсы моментлар бар әле.

Мәкаләдә язылганча, шагыйрьнең гәүдәсе җиргә тапшырылганчы тагын бер тапкыр фото алдырыла: «...табут йиргә куела, тәгаен кылынган адәмнәр тарафыннан Габдулла әфәнде табуттан алына, кабергә индерелгән вакытта аның йәнә бер мәртәбә рәсеме чыгарыла...»[6]. «Кояш» газетасы моны болай тасвирлый: «Гүргә иңдерер алдыннан, ак кәфендә көенчә, соң мәртәбә мәрхүм шагыйрьнең рәсеме алынды»[7].

Шагыйрьне соңгы юлга озатуның ахыры язмада болай тасвирлана:

«...Күмү тәмам була. Ханым вә туташлар тезелешеп чәчәкләр китерәләр, кабер өстенә тәртипләп тезәләр, кабернең тупрагы күренми. Ул хәзер кабер түгел, чәчәк өеме булып әверелә; бу да тәмам була. Зариф хәзрәт «Тәбарәк» укый башлый. Шул вакытта һәркем югалткан кешеләренең кем идекен төшенә башлый, кызулык вә эш

---

[1] *Кәшшаф Тәрҗемани* — Кәшшаф (Кәшшафетдин) Кыяметдин улы Тәрҗемани (Тәрҗеманов) (1877–1943), 1906 елдан Казанда Татар бистәсенең 11 нче мәчете имам-хатыйбы.

[2] *«Юл»* — Казанда 1907–1908 елларда эшләгән китап нәшрияты.

[3] *Сахиб* — ия, хуҗа.

[4] *«Гасыр»* — Казанда 1907–1921 елларда эшләгән китап нәшрияты.

[5] Габдулла Тукай 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән). Тәртип итүчесе һәм нашире: Ерак Шәрекъ Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының дини, милли мәркәз мәгариф шөгъбәсе. — Мукден, 1938. — 82–83 бб. арасында.

[6] Казанда 4 нче апрель... — Б. 111.

[7] Тукаевны озату мәрасиме....

илә сизенмәгән якыннары да аңа киләләр, күп кешенең күзендә яшь тамчылары тәгәри башлый. «Тәбарәк» тәмам була. Дога кылына, догадан соң Касыйм[1] хәзрәт, мәрхүмнең васыяте буенча

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм, бар, юнәл, кит Тәңреңә!

Бирдең аркаңны моңарчы, инде бир бит әмренә![2]

шигырене укый. Соңра берничә кеше тарафыннан нотыклар сөйләнә. Мәрасим тәмам була. Халык югалткан нәрсәсенең кыйммәтен тәкъдир итә-итә, уйланып, таралып китә»[3].

Язмада гәрчә шул моментны фотога алдыру турында хәбәр бирелмәсә дә, ул билгеле. Без анда кайбер кешеләрне дә беләбез: Ә. Урманчиев, Г. Гыйсмәти (нотык сөйләүче), Ә. Хәсәни.

Җеназаның Пләтән (хәзер Салих Сәйдәшев) урамы ахырында алдырылган фотосурәте дә бар[4]. Аның өске өлешендә шундый язуны укырга мөмкин: «Шагыйрь Тукаев җеназасы «Новый стройкада». Моңа кадәр билгеле булган чыганакларда, нишләптер, ул хакта мәгълүмат китерелми.

Рәсемнәр алдыру турында мәгълүмат «Вакыт» газетасында җыйнап китерелә: «Габдулла Тукаевны үлгәч бер кат кәфендә ятканын, аннан соң җеназасын күтәргәч вә өченче кат Печән базары мәсҗеде янына килгәч рәсемен алдырдылар. Бу соңгы рәсем алынуга сәбәп: Тукаевның «Кисекбаш» дигән тасвиры шул Печән базарына күп мөнәсәбәтле булганлыктан булырга кирәк һәм ул йир үзенең торганы «Болгар» һәм «Амур»[5] нумерының да нәкъ янында гына. Актык мәртәбә рәсеме кабергә төшерер алдында алынды»[6].

Нотык сөйләүчеләр турында «Кояш» газетасы шулай яза: «Шуның илә җеназа мәрасиме тәмам булды. Буннан соң Габдулла Гыйсмәти, Фәхрелислам Агиев, Шәехгаттар Иманаев[7] һәм Гыйльметдин Шәрәф мәрхүм Тукаевның эшләре, төрле

---

[1] *Касыйм* — Касыйм (Мөхәммәткасыйм) Габделгалләм улы Салихи (Салихов) (1871–1954), Казанда Апанаев мәчете (2 нче мәчет) имам-хатыйбы.

[2] Г. Тукайның «Васыятем» шигыре.

[3] Казанда 4 нче апрель... — Б. 111.

[4] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3 тасв., 126 сак. берәм.

[5] *«Амур»* — элекке Печән базары комплексында кунакханә тибындагы бина (Мәскәү ур., 70). 1864 елда сәүдәгәрләр бертуган Ибраһим (1806–1886) һәм Исхак (1814–1885) Юнысовлар акчасына табыш йорты буларак төзеттерелә. 1886 елда, мирас буларак, Габделкәрим (1853–1928) Исхак улы Юнысов милкенә күчә. Бертуган Мөбарәкша һәм Гарәпша Рамазановлар тарафыннан арендага алынып төзекләндерелә һәм 1912 елның 26 октябрендә рәсми рәвештә мосафирханә итеп ачыла. Зәкәрия Садретдинов (1880–1930) наширлегендә һәм мөхәррирлегендә 1912 елның 10 декабрендә чыга башлаган бер партия программасына да ияр-ми торган көндәлек тәрәкъкыйпәрвәрлек «Кояш» газетасының редакциясе анда урнашкан була (өченче кат, 40 бүлмә). Анда Г. Тукай 1913 елның февраль аена кадәр эшли.

[6] Г. М. Габдулла Тукаевның җеназа мәрасиме (Үз мөхбиремездән) // Вакыт. — 1913. 10 апр.

[7] *Шәехгаттар Иманаев* — Шәехгаттар Хәсән улы Иманаев (1875–1939), хокук белгече, филолог.

мәсьәләләргә карашлары һәм аның татар әдәбиятында булган әһәмияте хакында нотыклар сөйләделәр»[1]. «Вакыт» газетасында да шундый ук мәгълүмат китерелә.

Җеназада катнашкан Казан имамнары турында «Кояш» газетасындагы хәбәр берникадәр уйланырга мәжбүр итә. Хосусан, анда болай диелә: «Барысы да чакырылган булса да, җеназада Казан муллаларыннан анда Зариф хәзрәт, Касыйм хәзрәт һәм Кәшшаф хәзрәт кенә хазир иделәр[2]». Ә иң соңгы алдырылган фотосурәттә алар унау тасвирланган.

«Мәктәп» журналындагы мәкаләдән аңлашылганча, «Казанның имам вә мөәзиннәреннән берсе дә калмай җеназага хазир булганнар»[3]. Клячкин шифаханәсендә шагыйрь белән хушлашу тәмамлангач, «берничә хәзрәт вә үзенә якын торган аркадашлары тарафыннан тәсбих тәһлил укыла»[4].

Г. Тукайны соңгы юлга озатуда катнашкан Казан имамнары биредә әйтелгән хәзрәтләр белән генә чикләнми, әлбәттә. Димәк, алда әле тагын эзләнүләр көтә.

«Йолдыз» газетасында китерелгән «Габдулла әфәнде зыярәттән кергәч тә уң якка дәфен ителде» дигән мәгълүмат зиратның ул вакыттагы капкасын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә[5].

VI

Габдулла Тукайның каберенә чардуган һәм билге ташы кую мәсьәләсе мәрхүмне җирләгәннән соң ук күтәрелә. Бу хакта, мәсәлән, «Кояш» газетасының 1913 елгы 18 апрель санында мондый хәбәр игълан ителә: «Тукаевның тәдфин[6] вә тәҗһизе[7] белән мәшгуль булган дустлары вә иптәшләре аның кабере өстенә әгъла[8] таш эшләтеп куйдыру тәшәббесатына[9] керешергә торалар. Бу максуд өчен акча табу читен булмас дип уйлаганлыкларыннан, гасырлар буена китәчәк бу хатирәнең мөмкин кадәр мәһабәтле булуына тырышачаклардыр».

Әмма бу юнәлештә эш, күренгәнчә, күзалланылганча тиз генә башкарылмый. Әйтик, Җәлалетдин Уразаев (?–?) дигән бер кеше «Ил» газетасының 1914 елгы 15 март санында бастырган хатында зираттагы шундый картинаны сурәтли: «Мин үткән ел июль аенда Казанда газиз шагыйремез Тукайҗанның каберен күреп, рухына дога укып китмәк нияте берлә зиратка бардым. Стенага кагып куйган язу буенча күп эзләмичә таптым. Минем уйлаганнарымча, Тукайның кабере зиннәтле түгел икән: кабере өстендә кәз җәйгәннәр, тимер винуклары ватылып читтә аунап ята... Шундый газиз кабернең кадерен белмәгәнлекләре өчен, Казан яшьләренә рәхмәт әйтәсе килмидер».

Әмма газета идарәсе Тукай каберенең аяныч хәлдә булуын бер казанлыларга гына сылтамаска, ә барлык татар халкының гаебе итеп карый.

---

[1] Тукаевны озату мәрасиме....
[2] *Хазир иделәр* — катнаштылар.
[3] Казанда 4 нче апрель... — Б. 111.
[4] Казанда 4 нче апрель... — Б. 111.
[5] Тукаевны дәфен // Йолдыз. — 1913. — 7 апр.
[6] *Тәдфин* — җирләү.
[7] *Тәҗһизе* — әзерләү.
[8] *Әгъла* — яхшы.
[9] *Тәшәббесатына* — эшенә.

«Кояш» газетасының 1914 елгы 6 апрель санында басылган бер мәкаләдә әлеге юнәлештә эш һаман уңай нәтиҗәле булмавына борчылу белдерелә: «Тукайның елы булып үтте. Бу мөнәсәбәт белән аның тугрысында һичбер эш эшләнмәгән икәнен яңадан бер кат хәтергә алмый үтәргә мөмкин түгелдер. Кабер һаман әле һичтөрле тәгъмир ителмәгән[1], хәтта бер таш та куйдырылмаган. Тукайның мөфассал[2] тәрҗемәи хәлен язып нәшер итәргә илтизам иткән[3] камиссия дә бу бабта бер юл булсын, бер нәрсә язмаган вә һичбер тәшәббес ясамаган. Әгәр бу камиссия һаман шушы эшсезлегендә дәвам итәчәк булса, Тукай эшләрен фәкать хосусый инициативадан гына көтәргә каладыр».

«Кояш» газетасының шул ук елгы 6 нчы, 1915 елгы 3 нче апрель саннарында да бу хакта борчылулы мәкаләләр дөнья күрә. Аерым алганда, соңгысында болай диелә: «Тукайның кабере хәзергә кадәр ташсыз, ихатасыз тора. Йөз мәртәбә язылган бу тәәссефле мөсаһәләне[4] йөз дә беренче мәртәбә язып тору да уңайсыз инде.

Бу көн шагыйрьне зиярәт итәчәк кешеләр тагы бер мәртәбә Казан халкына рәнҗеп кайтачаклар».

1915 елда Вологда мөселманнары Г. Тукайны искә алу кичәсендә үзара 22 сум 5 тиен иганә җыялар. Алар «Иганә итүчеләр разый булсалар, бу акча вә Тукай җәмгыятенә йибәрелеп тә, җәмгыять булмаганлыктан, идарәдә саклана торган башка акчалар илә Тукайның каберенә яхшы мәрмәрдән таш яздырып куймакчы буламыз. Шулай булмаганда, җәмгыять кайчан булачак та, ул кайчан таш яздырып куячак?» дип белдерәләр. Идарә аларның бу гамәлен югары бәяләп, болай яза: «Мөселман мәркәзләренең һәрберсеннән ераста тора торган вологдалы кардәшләремезнең милли шагыйремезне хәтерләренә төшереп торып, аның намын таәбид итү юлында кулларыннан килгән тәшәббесләрдә[5] булынулары мактап бетерелмәслек кадәр шинаслык[6], бик бөек тәкъдир ителерлек милли аңлылыктыр».

Көндәлек матбугаттан күренгәнчә, шагыйрьнең вафатына өч ел тулганда да аның кабере тиешле тәртипкә китерелмәгәнлеге ачыклана. Мәсәлән, бу хакта «Кояш» газетасының 1916 елгы 29 март санында шундый мәгълүмат белән танышырга мөмкин: «Кирәк бәгъзы бер газета идарәсендә (шул җөмләдән безнең идарәханәмездә дә) вә кирәк хосусый кулларда, Тукай исеме белән багланган берәр изге эшкә тотарга багышланган акчалар бар. Бу акчаларның үзләрен генә бер тәртипкә китерелсә дә, моннан хасыйл була торган сума чибәр генә бер кабер ташы утыртырга вә гомумән шагыйремезнең каберен тәгъмир вә тәҗһиз[7] итәргә җитәрлектер. Шуңа күрә, моның хәзергә кадәр вөҗүдкә чыкмый торуында, фәкать Казан зыялыларының эшсезлекләре вә рухсызлыклары гына гаепледер.

---

[1] *Тәгъмир ителмәгән* — төзекләндерелмәгән.
[2] *Мөфассал* — тулы.
[3] *Илтизам иткән* — үз өстенә алган.
[4] *Тәәссефле мөсаһәләне* — үкенчеле игътибар итмәүне.
[5] *Тәшәббесләрдә* — инициативаларда.
[6] *Шинаслык* — аңлаучылык.
[7] *Тәгъмир вә тәҗһиз* — төзекләндерү һәм әзерләү.

Казан зыялылары даирәсендә бу көннәрдә шул мәсьәлә бик еш сөйләнеп йөри. Бер сыйныф халык шул тугърыда бер тәшәббес ясарга[1] да уйлый вә хәтта кайбер адымнарны инде ясый башларга торалар.

Без хәзер фәкать бер нәрсәне хәтергә төшерергә кирәк табамыз: әтраф шәһәрләрдә Тукайны искә төшерү мәҗлесләре булганда, бу мәсьәлә дә хәтергә алынса һәм шагыйрьнең каберен тәгъмир вә тәҗһиз итү намына[2] тагы беркадәр акча тапшырылса, бик мөнасиб эш эшләнгән булыр иде.

Бу кадәр озак тотып куелган таш вә ясалган тәгъмирнең мөмкин кадәр мәгънәле, таза вә нәфис булучылыгы һәм зәүкы нәфис хезмәт иттерелеп вөҗүдкә чыгарылуы бик мәтлубте[3]. Табигый, бу шартларның яхшы ижраэ ителә[4] алуы шул эшкә тәгъйин ителгән акчаның мул вә камилән йитәрлек булуыннан киләдер. Шагыйремезнең шәхесенә милләтнең соңгы һәдиясе[5] булырга тиешле бу нәрсәнең мөмкин кадәр дәр яхшы булучылыгы, зан итәмез[6], Тукайның ихтирам итә тоган һәрбер кешенең теләгедер.

Шуны да хәтерләргә алырга кирәк ки, шагыйрьнең каберен тәгъмир вә тәҗһиз итү белән генә әле бу бабтагы эшләр тәмам булмыйдыр. Казан җәмгыяте хәйриясе шикелле берәр рәсми вә даими бер мөәссәсә хозурында бу каберне карап тотар, җәй көннәрендә үсемлекләр белән чолгар вә кыш көннәрендә зыяратка килүчеләр өчен юллар ачып торыр өчен бер фонд ясап, шул фондтан килә торган файда белән каберне тәрбияләп тотарга тиештер. Без өмид итәмез, әгәр дахуды шул эшкә йитәрлек бер сума тәшкил итеп тапшырыла калса, җәмгыяте хәйриямез бу эшне үз өстенә алудан абаэ итмәскә[7] кирәктер».

«Сүз» газетасының 1916 елгы 8 апрель санында Тукайның кабере өстенә таш кую өчен Мәскәү укучылары тарафыннан 25 сум акча җыелганлыгын хәбәр итеп, иганәчеләрнең исемнәрен дә китерә: «Мостафа Сәйфелмөлекев — 1 сум, Әминә Яхина — 1 сум, Мәхмүт Терегулов — 1 сум, Хәдичә Зәбирова — 1 сум, Шәйхулла Алкин — 1 сум, Мостафа Сәедшакулов — 1 сум, Мөхәммәтгали Габдерәхимов — 1 сум, Салих Вәлиев — 5 сум, Зиннәт — 1 сум, Галим Биюшев — 2 сум, Габдерахман Хөсәенев — 10 сум».

Танылган сәүдәгәр Акчуриннарның Гурьевкадагы фабрикаларында кызлар мәктәбендә шагыйрьнең вафатына өч ел тулу уңаеннан ясалган «Тукай кичәсе»ндә Гөлсем Акчурина (1889–1957) үзе кушкан 50 сум белән бергә 97 сум иганә җыелып, «Кояш» газетасының идарәсенә җибәрелгән.

Ачыкланганча, Г. Тукайның каберен тәртипкә китереп, анда чардуган һәм таш кую эше 1917 елда да башкарылмаган икән. Чөнки, «Кояш» газетасының шул елгы 4 апрель санында хәбәр ителгәнчә, вафат булганнарны искә алып рух шәрифләренә дога кылу максаты белән 2 апрель көнне каберстанга барган бер төркем мәдрәсә

[1] *Тәшәббес ясарга* — эшкә тотынырга.
[2] *Намына* — исеменә.
[3] *Мәтлубте* — таләп ителәдер.
[4] *Ижраэ ителә* — башкарыла.
[5] *Һәдиясе* — бүләге.
[6] *Зан итәмез* — уйлыйбыз.
[7] *Абаэ итмәскә* — ah итмәскә.

һәм урта мәктәп шәкертләрләре бу аяныч хәлне күреп, җыелган акчаларны табып алып эшкә керешергә дигән карарга киләләр. Шунда катнашкан хаттат, фотограф Кыйвам-карый Зөлфокарый (1870–1921) ташларга алтын белән язуны бушлай эшләргә үз өстенә алачагын белдерә.

Татар каберлеге директоры булып эшләгән И. Мөхәммәтшин «Кызыл Татарстан» газетасының 1939 елгы 24 октябрь санында бастырган мәкаләсендә Г. Тукайның каберен берникадәр төзекләндерүен яза: «Аның кабре өстендә «Шагыйрь Габдулла Тукаев» дигән сүзләр язылган таш булса да, ул таш искереп, кырылып беткән инде. Ташның тәмам янына килеп җитмичә, аңа язылган сүзләрне укып булмый... Шуны искә алып, мин — татар каберлегенең директоры — шагыйрьнең каберен үземчә азрак тәртипкә китерү ниятe белән, аның кабере өстендәге ташны буяттым, кабер өстенә кәзләр җәеп, гөлләр утырттым, кабер бер кадәр матур төскә керде». Автор язмасында алга таба каберне төзекләндерергә, яңа таш куярга һәм аңа шагыйрьнең шигырьләреннән өзекләр язып куярга; бу эш белән Казан шәһәр Советы, тиешле башка оешмалар шөгыльләнергә тиешлеген белдерә. Димәк, моннан аңлашылганча, күрсәтелгән елга кадәр шагыйрь кабере өстенә таш куелган булган икән.

Г. Тукайның каберенә таш һәм чардуган кую тарихы турында шагыйрьнең тууына 60 ел тулу уңаеннан үткәрелгән чараларны яктырткан язмаларда да мәгълүмат китерелми. Мәсәлән, «Совет әдәбияты» журналының 1946 елгы 6 санында бәян ителгәнчә, 16 июньдә партия, комсомол, совет һәм җәмәгать оешмаларының делегацияләре, башка республикалардан килгән кунаклар, язучылар, композиторлар, галимнәр, рәссамнар, студентлар шагыйрь каберенә чәчәкләр сала. Әмма анда кабернең төзекләндерелгән булуы хакында әйтелми. Гәрчә 1946 елда алдырылган бер фотода аның каберенә челтәрләп эшләнгән тимер чардуган һәм гарәп хәрефләре белән «Шагыйрь Габдулла Тукай. 1886–1913. Вафат 2/15 апрель» дигән язулы хатират ташы сурәтләнгән (Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать Институтының Язма мирас фондында саклана — *Р. И.*). Фото үзе күрсәтелгән елның 10 апреле белән билгеләнсә дә, табигать күренеше май урталары – июнь башларын хәтерләтә. Бәлки, бу таш һәм чардуган кую көнедер?

Әмма шагыйрь каберенә беренче мәртәбә таш куелу елы һаман билгесез булып кала. Бәлки, бу хакта берәр чыганакта теркәлгәндер. Эзләүне дәвам иттерергә кирәк. И. Мөхәммәтшин язмасында китерелгән «Тукаев» һәм 1946 елгы таштагы «Тукай» сүзләренең аерымлыклары да уйланырга мәҗбүр итә.

Билгеле булганча, 1956 елда Г. Тукайның тууына 70 ел тулу уңаеннан аның кабере яңартыла. Мәрмәрдән икенче һәйкәл куелып аңа шагыйрьнең барельфы беркетелә, аннан аста кирилл хәрефләрендә «Габдулла Тукай 1886–1913» һәм гарәп графикасында «Г. Тукай» дигән язулар уела. Чардуган да алыштырыла.

Г. Тукайның 125 еллыгына (2011) шагыйрьнең каберенә янә төзекләндерү эшләре үткәрелә. Элек чәчәкләр утырту өчен калдырылган махсус урын мәрмәр таш белән алыштырыла. Анда аның «Өзелгән өмид» дигән шигыреннән «И мокаддәс моңлы сазым уйнадың син ник бик аз» дигән юллары татар һәм рус телләрендә уеп язылган.

VII

Г. Тукайны искә алу мәрасиме аның вафаты көнне үк башлана. Бу хакта «Касыймия» мәдрәсәсенең элеккеге шәкерте Мирза Бәрхиев (?–?) үз истәлегендә болай яза: «Мәдрәсәдә Тукай үлгән көн кайгылы булды. Укулар-укытулар тукталды, кайгылы шигырьләр укылды, тәрҗемәи хәл сөйләнде». Әйтергә кирәк, шагыйрь бу уку йорты шәкертләре белән элек тә дустанә мөнәсәбәттә булган. Бу хакта ул исән чагында «Касыймия», аның шәкертләрен якын күрәм, алар белән утырдаш булу белән рәхәтләнәм», — дип сөйли торган булган.

Шагыйрьнең еллык кичәсе дә башлап анда үткәрелгән икән. Бу турыда М. Бәрхиев шулай дәвам итә: «Тукай үлүенә ел тулгач, аның иҗатына карата мәдрәсә күләмендә беренче мәртәбә Тукай кичәсе мәдрәсәи «Касыймия»дә үткәрелде. Укулар-укытулар туктатылды. Кичәдә Габдерахман Вәлиди тарафыннан доклад ясалды. Хәбиберахман[1], Касыйм Хәмзиннәр[2] һәм башкалар тарафыннан Тукайның күп кенә шигырьләре укылды. Кичәдә Касыйм хәзрәтнең дә катнашы булды, ул да тыңлап утырды»[3].

Оренбургта да Г. Тукайны искә алу чарасы ул вафат булган көнне үк уздырылган. «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте, ватандашлар сугышы ветераны, соңыннан юридик фәннәр докторы Фатих Бакиров (1900–1975) язганча, митинг башта мәдрәсә эчендә була. Анда татар шәкертләре белән бергә үзбәк, казакъ шәкертләре дә чыгыш ясый. Истәлектә алга таба вакыйга шулай тасвирлана: «Аннары барчабыз бергә мәдрәсәдән чыгып, кала үзәгенә таба юл тоттык. Николай урамындагы китап кибете ишеге янына Габдулла Тукайның сурәте һәм аның вафаты мөнәсәбәте белән язылган шигырь урнаштырылган иде. Шигырьне китап кибетендә эшләүче «Хөсәения»нең элекке шәкертләреннән Исхак Әлмәшев[4] язган, диделәр. Без, төркем-төркем булып, шагыйрь сурәте яныннан уздык, яшь аралаш кайгылы шигырь юлларын укыдык. Халык күп иде. Бу — Оренбург халкының Габдулла Тукай белән үзенчә хушлашуы иде...»[5].

Г. Тукайның вафатыннан соң берничә көн үткәч тә, Әстерхан шәһәрендә «Җәмгыяте хәйрия» клубында шагыйрьне искә алу кичәсе үткәрелә. Аны оештыру һәм уздыру эшләрен С. Рәмиев, Хөсни Кәрим (1887–1965), Ш. Гайфи башкара. Бу мәдәни чарада катнашкан Зәйнәп Кәримова (1909–1995) үзенең истәлегендә шулай яза:

---

[1] *Хәбиберахман Хәмзин* — Хәбиберахман Зыятдин улы Хәмзин (1891–1963), мәгърифәтче.

[2] *Касыйм Хәмзин* — Касыйм Зыятдин улы Хәмзин (1895–1976), тел галиме, педагог.

[3] Бәрхиев М. Тукай истәлеге / М. Бәрхиев // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 430.

[4] *Исхак Әлмәшев* — Исхак Мөхәммәтҗан улы Әлмәшев (?–1938), Октябрь түнтәрелешенә кадәр Оренбургта нашир Фатих Кәриминең китап кибетендә эшли. Соңра педагогия техникумында, педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты укыта. Ул үзешчән артист, режиссёр буларак та билгеле. 1919–1928 елларда губерна халык мәгарифе бүлегендә сәнгать секциясен җитәкли.

[5] Рәхимкулова М. Оренбургта кайгылы көн / М. Рәхимкулова // Яңа Вакыт (Оренбург). — 1993. — 10 апр.

«Кичәне Сәгыйть абзый ачып, салмак тавыш белән, бик матур итеп (ул, гомумән, матур сөйли торган кеше иде) Тукайның тәрҗемәи хәлен сөйләде. Ул сүзен тәмамлагач, Хөсни Кәрим җитәкчелегендәге хор түгәрәге Тукайның «Милли моңнар», «Өзелгән өмит», «Алтынга каршы» дигән һәм башка шигырьләрен көйгә салып җырлады. Оркестр түгәрәге, шул ук Хөсни Кәрим җитәкчелегендә, шагыйрьнең исән вакытта яратып тыңлаган көйләрен уйнады. Шагыйрьнең әсәрләрен, бигрәк тә укучы балаларга карата язылган «Гомер юлына керүчеләр», «Кышкы кичтә», «Эш беткәч уйнарга ярый» һәм башка шигырьләрен укыдылар. Бу бүлек Сәгыйть абзый җитәкчелегендә әзерләнгән иде. Кичә бик матур узды»[1].

Танылган фольклорчы, Тукайны күреп белгән Х. Бәдигый истәлегеннән күренгәнчә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре, җитәкчелекнең рөхсәт бирмәвенә карамастан, дәресләр уку урынына шагыйрьнең еллыгын үткәрәләр[2].

«Кояш» газетасының 1914 елгы 6 апрель көнне Казан мәдрәсәләренең күбесеннән шәкертләр Тукай рухына хәтем итеп, дога кылганнар. Сәгать 2 ләрдә бөтен матбугат әһеле, укучы яшьләр һәм җәмәгать хадимнәре хосусый бер ханәгә җыелып, Яңа бистә имамы Зариф хәзрәт Әмирхан һәм «Касыймия» мәдрәсәсенең мөдәррисе, «яшьләр мулласы» исемен алган Касыйм хәзрәт Салихи белән берлектә 10–15 ләп атта зиратка барганнар.

Шагыйрьнең кабере янында күп халык катнашлыгында Касыйм хәзрәт «Тәбарәк» сүрәсен укып, дога кылганнан соң, «Сабах» китапханәсе мөдире Габделвәли әфәнде Әхмәдуллин (1870–1921 елдан соң) ханәсенә кайталар. Чөнки бу көнне ул әйтелгән имамнарны һәм укучы яшьләрне үзенә кунакка чакыра. Бу уңайдан хәбәрдә телгә алынган шундый бер кызыклы деталь игътибарны җәлеп итә: «Әлегә кадәр бер-берсенә нәфрәт итешеп килгән чалмалылар илә зыялыларның бергә, бер мәҗлестә бер-берсенә чын мәхәббәт вә ихлас берлә борадәранә[3] сөйләшеп ултырышты кларын бу мәҗлес соң дәрәҗәдә гүзәл үтте».

Русларның пасха вакыты туры килү сәбәпле, клубларда кичәләр оештыру кичектерелә.

Тукай зираты янында ниндидер бер малайның Габдулла Килдишев (?–?) тарафыннан нәшер ителгән К. Мотыйгыйның «Мәшһүр шагыйрь Габдулла Тукаев хакындагы хатирәләрем» дигән китапны сатып йөрү күренеше бер тупас эш дип бәяләнелә һәм андый гамәлләрдән сакланырга чакыра[4].

«Кояш» газетасының 1914 ел 28 март санында Әстерханда Тукай кичәсе ясалачагы һәм бу эш артыннан мөгаллим Ш. Гайфи йөрүе хакында хәбәр басыла[5]. Газетаның 2 апрель санында исә кичәгә рөхсәт бирелүе әйтелеп, аның программасы да күрсәтелә. Аерым алганда, анда Тукайның тәрҗемәи хәле укылачагы; Тукайның татар әдәбиятындагы хезмәтләре һәм аның шигъриятта тоткан урыны хакында; Тукайның мәктәп галәменә керткән хезмәтләре вә аның шигырьләренең балаларга тәэсире хакында; Тукайның тәнкыйть вә шул юлда хезмәт итүе; Тукайның хосусый

[1] Кәримова З. Истә калганнардан / З. Кәримова // Азат хатын. — 1968. — № 4. — Б. 16.
[2] Бәдигый Х. Бөек халык шагыйре Г. Тукай турында исемдә калганнар... — Б. 316–317.
[3] *Борадәранә* — туганнарча.
[4] Казанда Тукай көне // Кояш. — 1914. — 6 апр.
[5] Мөхбир. Тукай кичәсе. Әстерхан / Мөхбир // Кояш. — 1914. — 28 март.

хәяте, тормышы, халыкның аңа карашы турында сөйләнәчәге бәян ителә. Кичәдә Г. Тукайның төрле, шул исәптән Ш. Гайфи эшләттергән рәсемнәре дә зурайткыч фонарь аркылы күрсәтеләчәге әйтелә[1].

«Сөембикә» журналының 1914 елгы 13 санында дүртенче сыйныф укучысы Фатыйма Мәүлиева (?–?) мәкаләсеннән күренгәнчә, Бохара шәһәрендә Г. Тукайның еллык кичәсе «Мәржания» аптекасы хуҗасы Туктар Диннекәев (?–?) тырышлыгы белән үткәрелгән. Анда Хивага үтеп барышлый К. Мотыйгый да катнашкан. Мәкалә авторы язганча, ул Тукай рухына Коръәннән берничә аять һәм «Салават шәриф» укыганнан соң, шагыйрьнең әсәрләрен укый һәм җырлый. Аның артыннан мөгаллим Камал Нугаевның (?–?) Бохарада укучы татар, нугай балалары да хор белән берничә шигырь әйтәләр. Бу кичәдә Хива ханлыгы җитәкчелеге белән бергә, бохаралы татар байлары була.

1914 елда Г. Тукайның еллыгы уңаеннан 2 апрель көнне Семипалат шәһәрендә яшьләр җыены үткәрелә. Әүвәл Коръән укылып, мәрхүмнең рухына дога кылына. Соңрак Г. Мусин (?–?) тарафыннан Тукаевның кыскача тәрҗемәи хәле, шигърияте һәм татар әдәбиятына керткән хезмәтләре сөйләнеп, кайбер кешеләр шигырьләрен укыйлар. Тукаев исеменә 18 сум 19 тиен иганә җыелып, укытучылыкка әзерләнүче бер фәкыйрь шәкертқә бирелә[2].

Шул көнне шәһәрнең беренче мәхәллә мәктәбендә дә Тукай еллыгы билгеләп үтелгән. М. Еникеева (?–?) исемле кешенең хәбәрендә күрсәтелгәнчә, ул көнне дәресләр булмаган. Шагыйрь һәм нашир, педагог, публицист Фатыймаи-Фәридә Вahапова (Нәүрүзова) (1889–1914) рухына дога кылынгач, әдипнең тәрҗемәи хәле сөйләнелә, шигырьләре укыла[3].

Семипалат өлкәсендәге башка шәһәрләрдә дә Тукайның еллыгын уздырганнар. Мәсәлән, Каркаралыда татар, казакъ, сарт (үзбәк) зыялылары оештырган шундый кичәдә сәүдәгәр, приказчик, мөгаллим, фельдшер, доктор, бай-ярлы, ягъни төрле социаль катлау вәкилләре була. Башта шагыйрьнең тәрҗемәи хәле сөйләнелгәч, мәрхүмнең рухына Коръән укыла. Соңрак мөгаллим һәм шәкертләр шагыйрьнең төрле шигырьләрен укыйлар. Аңлашылмаган урыннары казакъча аңлатыла. Ахырдан мәктәп балаларына конфет, печенье, чикләвек кебек күчтәнәч өләшенә. Габделхәким Атажанов (?–?) һәм Урмановлар балаларга Тукайның «Алтын әтәч», «Күңелле сәхифәләр», «Җуаныч» дигән китапларын бүләк итә. Балаларны шатландырып өйләренә кайтарып җибәргәннән соң, өлкәннәргә чәй бирелеп, анда да сүз гел Тукай хакында була, аның тирәнрәк мәгънәле шигырьләре укыла[4].

«Вакыт» газетасының 1914 елгы 20 апрель санында Истанбулда Тукай кичәсенең ничек үткәрелүе турында языла. Анда сүз 1908 елда барлыкка килгән «Русияле мөселман шәкертләре җәмгыяте» тарафыннан оештырылган клуб тарафыннан әзерләнгән махсус программа буенча башта скрипка, гармун, мандолинадан гыйбарәт кечкенә бер оркестрда төрле милли көйләр уйналуы, аннан соң Г. Тукайның «Теләнче», «Йоклыйлар», «Мулланың зары», «Кызык гыйшык» дип аталган шигырьлә-

[1] Мөхбир. Тукай кичәсе. Әстерхан / Мөхбир // Кояш. — 1914. — 2 апр..

[2] Әбушахмани. Семипалаттан / Әбушахмани // Тормыш. — 1914. — 23 апр.

[3] Еникеева М. Хатын-кыз дөньясы / М. Еникеева // Тормыш. — 1914. — 25 апр.

[4] Юнысов Г. Каркаралыда Тукай көне / Г. Юнысов // Вакыт. — 1014. — 27 апр.

ре һәм башка әсәрләре хор белән һәм аерым рәвештә дә җырлануы, сөйләнелүе турында бара[1].

Булачак танылган тел галиме, әдәбиятчы Нигъмәтулла Хәкимов (1889–1937) хәбәр иткәнчә, Златоуст өязе (хәзер Башкортстан Республикасы) Югары Кыйгы авылында 23 нче мартта Г. Тукайның вафатына бер ел тулу уңаеннан, аның исеменә әдәбият кичәсе үтә. Анда Тукайның тәрҗемәи хәле, аның милләткә, хатын-кызга, ишаннарга карашы һ. б. хакында сөйләнелә. Унлап шәкерт аның шигырьләрен укый[2].

Казалы шәһәрендә Тукай кичәсе Фәйзерахман Хөсәенов (?–?) дигән игелекле затның диварлары шагыйрьнең фотосурәтләре һәм чәчәкләр белән бизәлгән фатирында үткәрелгән. Башта мәрхүм рухына Коръән укыла, кыскача аның тәрҗемәи хәле сөйләнелә, берничә шигыре тыңланыла.

Төнге сәгать икеләргә кадәр сузылган бу мәҗлестә Тукай стипендиясенә кушу өчен 62 сум 30 тиен акча җыйнала һәм почта аша «Ил» газетасы идарәсенә җибәрелә[3].

Омск шәһәре яшьләре Тукайны искә алу кичәсе үткәрүнең программасын әзерләгәч, бу чара турында берәүнең рәсми хакимияткә хәбәр итәчәге беленә. Шулай да, Ш. Измайлов (?–?) шагыйрьнең 10 данә зурайтылган рәсемен, Г. Хәбибуллин (?–?) төрек әдибе Әхмәд Мидхәтнең (1844–1912) бер данә зурайтылган рәсемен бүләк итеп бирәләр. Шул рәсемнәрне мөгаллим С. Черкасов (?–?) белән Шәйхетдин исемле бер кеше сатып йөри һәм «Кояш» идарәсенә берникадәр имзалы тәгъзия телеграммасы җибәрә. Рәсемнәр сатудан һәм башка иганәләрдән җыйналган 20 сум акчаны Тукай ядкәренә тоту өчен берәр җәмгыяте хәйриягә бирәчәкләрен белдерәләр[4].

Саратовта 2 апрель көне мөгаллимә Мәүсүфә Яраеваның (?–?) хосусый кызлар мәктәбендә башта Тукай рухы шәрәфенә Коръән укыла. Аннан соң укучылар шагыйрьнең «Васыятем», «Балалар күңеле» һәм башка китапларындагы шигырьләрен сөйлиләр. Мәүсүфә ханым мәктәпкә берничә данә Коръән бүләк итәчәген әйтә[5].

Нәманган шәһәрендә байтак кына яшьләр, эшләреннән тукталып, көнне шагыйрьнең тәрҗемәи хәле һәм аның шигырьләре хакында сөйләшеп үткәргәннәр, шагыйрьнең бер зирәк бала укытырга кирәк дигән васыятенә кушу өчен акча салышып, Петербургка җибәрергә карар кылганнар[6].

Троицкида күпчелек муллалар каршы килү сәбәпле, Тукайның еллыгы зурлап уздырылмаган. Бары тик кайбер мәдрәсәләрдә генә шагыйрьнең тәрҗемәи хәле сөйләнелеп, балаларга бер көн ял бирелгән. Зур мәдрәсәләрнең берсендә хәзрәт килеп: «Сезгә бу көнне кем бәйрәм итәргә кушты, Тукайны мин биш бармагым кебек бе-

[1] Насыйри З. Истанбулдан / З. Насыйри // Вакыт. — 1914. — 20 апр.

[2] Хәкимов Н. Авылда Тукай / Н. Хәкимов // Тормыш. — 1914. — 23 апр.

[3] Сабирзадә Г. Тукай көннәре Казалыда / Г. Сабирзадә, М. Субаев, М. Шәрәфетдинов // Ил. — 1914. — 27 апр.

[4] Мөхбир. Тукай көннәре. Омскида / Мөхбир // Ил. — 1914. — 27 апр.

[5] Таканаева Г. Тукай көннәре Саратовта / Г. Таканаева, Ф. Бартханова, Х. Галимова // Ил. — 1914. — 27 апр.

[6] Мөкаев Х. Тукай көннәре Нәманганда / Х. Мөкаев // Ил. — 1914. — 27 апр.

ләм. Ул әнә безнең Мирфәйзә шикелле бер кеше», — дип мөгаллимнәрне тиргәп йөргән[1].

Тукай вафатының ике еллыгы уңаеннан Актүбә шәһәренең ир балалар мәктәбендә үткәрелгән «Габдулла Тукай» кичәсендә хәзрәт, мөәзин, мөгаллимнәр, шәкертләр һәм мөсафир Харрас хәзрәт Айдаров (?–?) катнаша. Анда бер шәкерт тарафыннан бу чарага махсус язылган 2 пәрдәлек «Көнче шәкерт» дигән спектакль куела. Аннан соң Г. Тукайның «Исемдә калганнар»ы, хор белән берничә шигыре укыла. Мәҗлес азагында Харрас хәзрәт борынгы милли «Зиләйлүк» көенә башкортларның җир сату хакында әйткән шигырьләрен укып күрсәтә[2].

Акчуриннарның Гурьевкадагы фабрикасында Тукайның вафатына ике ел тулу мөнәсәбәте белән Өммегөлсем Акчурина тарафыннан балалар кичәсе оештырыла. Укучылар шагыйрьнең шигырьләрен укый, аның тәрҗемәи хәле һәм нотыклар сөйләнелә[3].

Бохарада Тукайның ике еллыгын билгеләп үтәргә рөхсәт бирелмәгән икән. Шуңа күрә Бакудан килгән мөселман артист Ханталишский мәхәллә яшьләре белән бергә ике спектакль куярга рөхсәт ала. 17 апрельдә куелган тамаша файдасыннан 50 проценты Петроградта яралыларга ярдәм өчен ачылган мөселман комитетына, 26 апрельдәге кичәнең файдасыннан яртысы Бакуда Карс мохтаҗларына ярдәм өчен ачылган комитетка җибәрелә[4].

«Уфа мөселман ханымнар җәмгыяте хәйриясе» карамагында булган 3 нче мәхәлләдәге кызлар мәктәбендә Тукай вафатына 3 ел тулу уңаеннан кичә үткәрелеп, анда шагыйрьнең шигырьләре укыла, рухына догалар кылына[5].

Татар сәүдәгәре, иганәче Садыйк Ерзин (1858–1936) тарафыннан Мәскәүнең тарихи мәчете ихатасында 1913 елда флигель рәвешендә төзеттерелгән бинада урнашкан мәктәптә шагыйрь вафатына өч ел тулу уңаеннан Тукай иртәсе үткәрелә. Анда балаларга аның тәрҗемәи хәле сөйләнеп, рәсеме күрсәтелә. Соңыннан балалар тарафыннан Коръән укылып, дога кылына һәм шигырьләре сөйләнелә. Ахырда балаларга чәй бирелеп, сыйлап озатыла[6].

Тукайның вафатына өч ел тулган көнне Мәскәүдә Әсәдуллаев мәктәбендә дога мәҗлесе үткәрелә. Шагыйрьнең рухына багышлап балалар Коръән укый, соңыннан балалар «Мәрхүм Мөхәммәтзаһир әфәндегә»не хор белән җырлый. Кыз балалар, берничә төркемгә бүленеп, шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен сөйли. Анда катнашкан Г. Исхакый балаларга «шагыйрь» дигән сүзнең мәгънәсен сөйләп аңлата, аларны мәрхүм шагыйрьнең милләтенә кылган олуг хезмәтләре белән таныштыра.

Мәҗлестән соң балаларга чәй бирелеп, Мәскәү ханымнар җәмгыяте тарафыннан бүләкләр өләшенә. Шагыйрьнең каберенә таш куйдыру юлына тотарга шәкертләр һәм шунда булучылардан иганәләр дә булып, тиешле урынына тапшыру өчен «Сүз»

[1] Мөстәкыйм. Тукай көннәре Троицкида / Мөстәкыйм // Ил. — 1914. — 27 апр.

[2] Габбасов-Бурлинский Ә. Актүбәдә Тукай кичәсе / Ә. Габбасов-Бурлинский // Вакыт. — 1915. — 9 апр.

[3] Баһапова М. Русия эчендә / М. Баһапова // Тормыш. — 1915. — 12 апр.

[4] Нугаев К. Бохара / К. Нугаев // Вакыт. — 1915. — 19 апр.

[5] Тукай кичәсе // Тормыш. — 1916. — 3 апр.

[6] Дунаева Х. Ерзин мәктәбендә Тукай кичәсе / Х. Дунаева // Сүз. — 1916. — 6 апр.

идарәсенә бирелә. Иганә итүче затлар: Габделхак Карамышов — 3 сум; Хәмзә Корбанов, Ибраһимҗан Хәкимҗанов — 2 шәр сум; Әфзалетдин вә Кәшшафетдин Мурзиннар — 1 сум 50 шәр тиен; Габделхәй Галиев, Сәгыйт Ерзин, Габдерахман Хөсәенов, Җәгъфәр Әлтыяр, Әхмәт Галиев, Габделхәким Әбүлмәгъҗанов, Фатыйх Салихҗанов, Әбүбәкер Газизов, Әдһәм Лапков, Хәсән Әшрәтов, Исмәгыйль Хуҗасәитов, Шәрифҗан Янбухтин, Габдуллаҗан Хәкимҗанов, Әмин Мусаев, Габделхак Биккинин, Һәдия Әхмәтсафина, Заһирә Карамышева, Мәрзия Дапкова, Хәерниса Сәфәрова, Фатыйха Әдһәмова, Хәдичә Исхакова, Әминә Фаизова, Сафия Мусаева, Хәдичә Әшрәтова — 1 сум; Камилә Гайсина — 90 тиен; Хөсәен Еникиева — 75 тиен; Хәдичә Зәбирова (рус теле мөгаллимәсе) — 1 сум 75 тиен; Фатыйма Ягъкубова, Мөнәвәрә Нугаева, Зәйнәп Әмирханова (мөгаллимәләр) — 1 сум; Шакиржан Ягъкубов, Сәүбән Бикташов, Гыймадетдин Тимербулатов (мөгаллимнәр) — 1 сум; Сотанмәхмүт Терегулов (рус теле мөгаллиме) — 1 сум.

Читтән килгән кешеләрдән: Гаяз Исхаков — 3 сум, Хәерниса Фәизова, Сабира Салихҗанова, Мәрьям Хәбибуллина, Гыйлемдар Баембәтов, Муллагазиз Гафуров, Хафиз Агиев, намәгълүмнән (билгесезләрдән) — 1 сум. Барлыгы 70 сум акча туплана[1].

1916 елның 8 апрелендә Бакуның татарлар күпләп яшәгән Бибиһәйбәт мәхәллә мәктәбендә Тукай кичәсе уздырыла. Ул мулла Кәмаль Галибәков (?–?) тарафыннан шагыйрьнең рухына Коръән укылып, дога кылу белән башлана. Хәнифә Ханбикова (?–?) җыр, көй вә музыка хакында анда катнашучыларга мәгълүмат бирә, Яхъя исемле мөгаллим Тукайның тәрҗемәи хәлен сөйли.

Мәҗлеснең матди ягын «Электрическая сила»да эшләүче Мостафа Габдуллов (?–?) дигән кеше тәэмин иткән. Ул Тукай исеменә ядкяр буларак мәчеткә бер палас та алып җәйгән. Сөләйман Габдуллаев (?–?) исемле берәү мәктәп диварына элү өчен Тукайның рәсемен зур форматта эшләтеп бирергә вәгъдә итә. Тукай исеменә бер баланы укытырга стипендия билгеләнә[2].

Гурьевкада Тукайның өч еллыгы да билгеләп үтелә. Маһруй Акчурина (?–?) мәктәбендә Өммегөлсем Акчуринаның тырышлыгы белән театр залында балалар кичәсе үткәрелә. Анда русчадан тәрҗемә ителгән ике пәрдәле «Убырлы карчык» дигән балалар әсәре уйнала. Тукайның тәрҗемәи хәле, балаларга карашы, яшь вакыты турында сөйләнелә. Бу кичәне әзерләшүчеләр арасында артист Зәки Баязитский (1889–1959), мөгаллимнәр Фәйзи Сәгыйдов (?–?), Мирзасалих Нугайбәков (?–?), мөгаллимәләр Ләмига Иманколова (?–?), Мәрвия Сәгыйдова (?–?), Маһирә Мөштәриева (?–?), Өммегөлсем Орлова (?–?) да була[3].

Тукайның өч еллыгы Петербургта да зурлап үткәрелә. Аңа багышланган кичә өч бүлектән гыйбарәт булып, аның беренчесендә Коръән укылып, аның рухына дога кылына. Аннан соң яшьләрдән берәү шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен сөйләп, халыкны аның белән җентекле таныштыра. Икенче бүлектә «Тукай — татар шагыйре» дигән темага реферат укыла. Бер студент «Шүрәле» поэмасын сөйли. Шулай ук «Ана до-

[1] Гыйффәт. Мәскәүдә Тукай көне (Мөхтәрәм шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаев рухына дога мәҗлесе) / Гыйффәт // Сүз. — 1916. — 6 апр.

[2] Кулаткый Ф. Бакуда Тукай кичәсе / Ф. Кулаткый // Сүз. — 1916. — 6 апр.

[3] Сәгыйдов Ф. Гурьевкада (Сембер губернасы) / Ф. Сәгыйдов // Сүз. — 1916. — 8 апр.

гасы» һәм «Хасият» дигән шигырьләре дә укыла. Тәнәфес вакытларында «Өзелгән өмид», «Татар кызына» кебек берничә шигырь хор белән җырлана. Өченче бүлектә Тукайның үзе белән таныш булган, шигырьләрен тикшерүдә тәжрибәле бер егет «Тукай мәхәббәте» дигән реферат укый. «Тукай һәм балалар дөньясы» дигән темага янә бер реферат укыла. Аннан соң шигырьләр укыла, җырлар җырлана.

Иртәгесен, 2 апрельдә җәмгыяте хәйрия мәктәбендә «Тукай иртәсе» үткәрелә. Башта мәрхүмнең тәрҗемәи хәле сөйләнелә. Аннан соң «Шүрәле», «Су анасы» һәм башка шигырьләре укыла. Әлеге чаралардан Тукай фондына 75 сум иганә җыйнала[1].

1917 елның 2 апрелендә Пермьнең укучы һәм студентлар түгәрәге тарафыннан Тукайның вафатына 4 ел тулу уңаеннан кичә үтә. Сәхнә алдына рәссам Госман Арсланов (1897–1941) ясаган Тукай рәсеме эленә. Г. Кариевның бер пәрдәлек «Артист» исемле комедиясе уйнала. Курсистка Сара Исмәгыйлева (?–?) шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен сөйли, башкалар тарафыннан төрле шигырьләре укыла[2].

1918 елның 2 апрелендә Мәскәүдә татар яшьләренең «Ташкын» дип аталган түгәрәк оештырган искә алу кичәсендә шагыйрьнең якын дусларыннан берсе, танылган җәмәгать эшлеклесе, хокук белгече, журналист, педагог Ш. Мөхәммәдъяров «Тукай кем?» дигән темага шактый күләмле доклад укый. Күп тә үтми, бу доклад түгәрәк тарафыннан аерым китап итеп бастырыла[3].

Шул ук елның 4 апрелендә Казанда эшчеләр клубы залында драма түгәрәге тарафыннан Тукай кичәсе оештырыла. Анда бер пәрдәлек «Музыкант» драмасы уйнала, шагыйрьнең тәрҗемәи хәле сөйләнелә, төрле шигырьләренә язылган җырлар башкарыла.

1923 елның 16 апрелендә Татар театры бинасында Тукайның вафатына ун ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе уза. Анда башта Мәгариф халык комиссары Микъдәт Борындыков (1896–1965) һәм Татарстан Мәркәз башкармасы рәисе Рәүф Сабиров (1894–1937) тарафыннан нотыклар сөйләнелә. Аннан соң Тукайның әсәрләре һәм шигърият өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре турында Фәтхи Бурнаш (1898–1942) доклады тыңлана.

Докладтан соң кичәнең рәисе М. Борындыков шушы ун еллык хатирә көнендә Тукайга татарның халык шагыйре исемен бирергә лаек булганлыгын игълан итә.

Г. Тукай белән күп мәртәбә очрашкан артист З. Баязитский «Татарның сәүдә капиталыннан төзелгән «Мәгариф», «Сабах», «Гасыр» һәм «Юл» ширкәтләренең, Тукай әсәрләреннән файда күреп тә, аның авыру вакытында бер тиен дә матди ярдәм күрсәтә алмаганлыкларын», «Тукайның Уфага барган вакытында «Сабах» ширкәтенең андагы кибет хуҗасы Х. Зәбиринең Тукайны караңгы һәм эссе бүлмәдәге ящиклар өстендә «кунак» иткәнен...», үз авылына ял итәргә кайтканда мәзкүр[4] наширләрнең Тукайга бер кием дә алып бирә алмаганлыкларын вә шул сәбәптән ша-

[1] Хикмәт. Нева якасыннан. Тукай көннәре / Хикмәт // Сүз. — 1916. — 8 апр.

[2] Хангилдин В. Пермьдә Тукай кичәсе / В. Хангилдин // Тормыш. — 1917. — 27 апр.

[3] Мөхәммәдъяров Ш. Тукай кем? / Ш. Мөхәммәдъяров. — М.: «Ташкын» нәшриятыннан беренче китап, 1918. — 22 б.

[4] *Мәзкүр* — әйтелгән.

гыйрьне Бәдигъ мөәзиннән[1] алган җилән белән юлчылар йөртүче мужикның каткан тунына төреп җибәрергә туры килгәнен сөйли.

Хатирәләр сөйләнеп беткәннән соң, Тукайның кайбер шигырьләре укыла. Композитор Солтан Габәшинең (1891–1942) күптавышлы хоры чыгыш ясый, артист Мөхәммәт Вәлишин (?–?), Терегулов (?–?), Мәҗидов (?–?) һәм һәвәскәрләрдән Хәлил Чамаев (?–?), Мәхмүт Бөдәйли (1895–1975) үзләренең җырларын-шигырьләрен башкара. Ф. Бурнаш «Татарстан» газетасын чыгаручыларның һәм контора хезмәткәрләренең Тукайның туган авылы Кушлавычка шефлык итәргә һәм ул авылга матди һәм мәгънәви ярдәм күрсәтү өчен хезмәт хакларының берничә процентын ай саен биреп барырга карар биргәнлекләрен игълан итә[2].

Узган гасырның 30 еллар ахыры тулаем СССР өчен иң котсыз дәвер булса да, 1938 елда шагыйрьнең вафатына 25 ел тулу Татарстанда киң билгеләп үтелгән икән. Моны шул вакыттагы көндәлек матбугат даими яктыртып барган.

15 апрельдә Татар академия театрында зур кичә була. Аны ТАССР Халык комиссарлары советы рәисе урынбасары Сөләйманов[3] ача һәм Г. Тукайның тормышы, иҗат эшчәнлеге турында доклад сөйләү өчен сүзне Хан Җәмилевкә[4] бирә. Чыгыш, әлбәттә, шул чор рухында, ягъни үткәндәгене сүгүгә, шагыйрьнең әдәби эшчәнлеген хаким идеология яссылыгында аңлатуга корыла.

Төп чыгыштан соң, Сөләйманов ТАССР Башкарма комитеты президиумының Г. Тукай исемен мәңгеләштерү буенча карарын игълан итә: шагыйрьнең вафатына 30 ел тулуга Казанда аңа һәйкәл куярга, элекке «Болгар номерлары»нда музей-бүлмә ачарга, аның өлкә кабинетына Г. Тукай исеме бирергә.

Ахырда Татар дәүләт академия театры артистлары тарафыннан концерт куела. Кичәнең бу өлеше композитор Заһидулла Яруллин (1888–1964) язган «Тукай маршы»н Салих Сәйдәшев (1900–1954) җитәкчелегендә симфоник оркестр башкаруы белән башлана. Заһид Хәбибуллин (1910–1983) үзе исә шагыйрьгә багышлап язган «Истәлек» һәм «Сүнгән дәрт» көйләрен уйный.

Артист Хәким Сәлимҗанов (1903–1981) Г. Тукайның «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш», «Шүрәле», Ибраһимова «Эш беткәч уйнарга ярый», Касыйм Шамил (1892–1981) «Сарыкортларга» дигән әсәрләрен сөйли.

Г. Тукайның «Өйләнү түгел сөйләнү»е Хөсәен Уразиков (1894–1977), «Ысул кадимче»се Шакир Шамильский (1892–1945) тарафыннан сәхнәләштерелә. Концертта яңгыраган җырларның күп өлешен Г. Тукай сүзләренә язылганнары тәшкил итә.

Казандагы жир комбинатының партоешмасы тарафыннан билгеләнгән кешеләр цехларда әңгәмәләр үткәрәләр, күп тиражлы газета шагыйрьгә багышлап махсус сан бастырып чыгара. 10 апрель көнне Ленин исемендәге клубта зур кичә уздырыла, китапханә күргәзмә оештыра.

---

[1] *Бәдигъ мөәзин* — Мөхәммәтбәдигъ Мөхәммәтгалим улы Хөсәенов (1853–1929), Казанның Яңа бистәсе мөәзине.

[2] Г. Л. Тукайга хатирә кичәсе / Г. Л. // Татарстан. — 1923. — 18 апр.

[3] *Сөләйманов* — Сөләйман Хәлил улы Гафиятуллин (1905–1983).

[4] *Хан Җәмилев* — 1902–? елларда яшәп иҗат иткән драматург һәм журналист.

Татарстан радиокомитеты бу чараны 12 апрельдә үк башлап җибәрә. Ул көнне яшь язучылар Нур Гайсин (1914–1995), Сибгат Хәким (1911–1986), Бәян Гыйззәт (1918–1991) микрофон алдында үзләренең әсәрләрен укып ишеттерәләр. Балалар өчен тапшырулар бүлеге Г. Тукайның аерым әсәрләренә көйләр язуны композитор Хәбибуллинга йөкли.

Казанның Сталин районындагы Вахитов исемендәге китапханәдә 12 апрель көнне Тукай турында лекция укыла, шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗатына багышлап альбом эшләнә, күргәзмә оештырыла.

Тукай исемендәге балалар китапханәсендә дә зур эшләр башкарыла. Анда 12, 18 апрельдә шагыйрьгә багышланган лекция укыла. 24 апрельдә исә конференция уздырыла. Китапханәгә йөрүче балалар Тукайның әсәрләре буенча рәсемнәр ясый һәм шул нигездә күргәзмә оештырыла, дивар газетасы чыгарыла.

Үзешчән рәссам Якупов[1] тарафыннан Тукайның фотосыннан күчерелеп, зур рәсеме ясала һәм ул залга элеп куела.

Казан дәүләт курчак театрында артистлар Хәбибуллин һәм Ш. Зәйни (1913–1980) шагыйрьнең «Кәҗә белән сарык», «Шүрәле» әсәрләрен сәхнәләштерә. Аларның беренчесен режиссёр Сөләйман Вәлиев (?–?), икенчесен Сабир Өметбаев (1908–1982) сәхнәгә куя.

14 апрель көнне Казанның Ленин районындагы 1 санлы урта мәктәбе укучылары шагыйрьгә багышланган кичәне зур тырышлык белән уздыра. 8 нчы сыйныф укучысы Фатыйхова шагыйрьнең көйгә салынган шигырьләрен җырлый. «Бишек җыры», «Буран» һәм башка әсәрләре хор белән башкарыла. Шул ук сыйныф укучысы Гафиятуллин «Эш беткәч уйнарга ярый», «Пар ат», «Шүрәле» һәм башка әсәрләренә рәсемнәр ясый һәм алар күргәзмәгә куела. Шулай ук укучылар махсус дивар газетасы да чыгара.

Киров районының 3 нче санлы мәктәбендә һәрбер сыйныфта Тукайның әсәрләрен өйрәнә, шагыйрьгә багышлап үзләре дә шигырьләр иҗат итә. Алар бу чараны 14 нче апрельдә уздыра.

Районның 12 нче санлы китапханәсендә күргәзмә оештыру белән шөгыльләнәләр. Аның мөдире Аблаева җитен комбинаты эшчеләре яши торган тулай торакка барып, шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты белән танышыра.

Шундый ук мәдәни чара шәһәрнең Молотов районындагы 4 нче санлы урта мәктәптә дә үткәрелә.

Татарстанның фәнни китапханәсендә Г. Тукай турында 1905–1937 елларда язылган материаллар нигезендә библиографик белешмә төзи. 14 апрельдә 4 бүлектән гыйбарәт булган зур күргәзмә оештырылып, аның беренчесендә Тукайга кадәр яшәп иҗат иткән татар әдипләренең әсәрләре, шагыйрь турында материаллар, икенчесендә әдип турында истәлекләр һәм аның үзе турында язган әсәрләр, өченчесенә барлык әсәрләре, дүртенчесенә укучыларның фикерләре туплана. Күргәзмәдә шулай ук Тукайның фотолары, рәссамнарның шагыйрь әсәрләренә иллюстрацияләре куела.

---

[1] *Якупов* — сүз киләчәктә ТАССР, РСФСР атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСР, СССР халык рәссамы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Харис Якупов (1919–2010) турында бара булса кирәк.

Тукайның вафатына 25 ел тулуны Мәскәүдәге «Красный богатырь» заводында эшләүче татар эшчеләре дә зурлап билгели.

Г. Тукайга багышланган мондый мәдәни чараларга республиканың башка төбәкләрендә дә зур игътибар бирелә. Мәсәлән, Чистай шәһәрендәге педагогия училищесында һәм башка уку йортларында кичәләр үткәрелә. Теләче районының Казаклар урта мәктәбендә Тукайга багышлап «Яшь көч» дигән кулъязма журнал һәм «Отличник» исемле дивар газетасы чыгарыла. Хаҗиев фамилияле укучы концерт алдыннан шагыйрь турында доклад укый.

Г. Тукайның вафатына 25 ел тулуны билгеләп үтү өчен Апас районы Башкарма комитет янында махсус комиссия төзелә. Халык арасында әдәби кичәләр оештырыла, китапханәдә күргәзмә оештырыла.

Шагыйрьнең тууына 65 ел тулу уңае белән Казанда В. И. Ленин исемендәге үзәк китапханәдә кичә уздырыла. Анда доцент Якуб Агишев (1899–1972) «Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты» дигән темага доклад белән чыгыш ясый. Аннан соң Татар дәүләт академия театры артистлары һәм театр училищесы студентлары зур концерт куя[1].

Күренгәнчә, халкыбыз кайда гына гомер кичерсә дә, нинди икътисади-иҗтимагый шартларда яшәсә дә, аның Г. Тукайга булган игътибары һәм ихтирамы бердәй булган. Шунысы сөенечле, бу күркәм традиция хәзерге вакытта да бәрәкәтле дәвам иттерелә.

Биредә 1913–1938 еллар аралыгында Г. Тукайны искә алу кичәләрен үткәрүнең берникадәр генә тарихы күздән кичерелде. Бу мөкатдәс эш-гамәл аннан соң да дәвам иттерелеп, хәзерге көннәргә килеп тоташа. Мондый мәдәни чаралар бер Россия = СССР киңлекләре белән генә чикләнми, әлбәттә. Туган илдән читтә хәят кичергә мәҗбүр булган милләттәшләребез дә, тугандаш халыклар да сөекле шагыйребезне искә алу мәдәни чараларын зурлап үткәрәләр.

***

Татар халкы кайда гына, хәтта мөһаҗирлектә яшәсә дә, рухани тормышында, академик Миркасыйм Госманов (1934–2010) әйткәнчә, үз Тукае белән аерылгысыз булган. Ышанычлы чыганаклардан күренгәнчә, дөньяның барлык төбәкләрендә, шул исәптән Ерак Шәрекътә горбәтлектә милләттәшләребез шагыйрьнең төрле юбилейлары уңаеннан мәдәни чаралар үткәргән, үзләре чыгарган көндәлек матбугатта мәкаләләр бастырган.

Шагыйрьнең вафатына сигез ел тулу уңае белән Кытайның Хайлар шәһәрендә мөгаллим һәм имам булган Хатип Халиди (1893–1977) «Ерак Шәрекъ»[2] журналының 1921 елгы 22 санында мәкалә бастырып чыгара. Аерым алганда, ул Казанда укытучылык эшенең беренче елында (1908) Г. Тукай белән беренче мәртәбә «Сабах» көтепханәсендә күрешүе турында кызыклы истәлеген китерә. Аннан соң да алар берничә тапкыр очрашканнар[3].

---

[1] Шәех Ә. Тукайны искә алу кичәләре / Ә. Шәех // Яшь сталинчы. — 1951. — 6 май.

[2] *«Ерак Шәрекъ»* — 1920 елның 25 гыйнварыннан 1925 кә кадәр Харбин шәһәрендә татар телендә айга өч тапкыр нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси, фәнни, әдәби басма.

[3] Халиди Х. Габдулла әфәнде Тукай. Вафатына 8 ел тулу мөнәсәбәте белән / Х. Халиди // Ерак Шәрекъ. — 1921. — № 22. — Б. 15–16 (гарәп графикасында).

Г. Тукай вафатына егерме ел тулу уңае белән «Яңа милли юл»[1] журналының 1932 елгы 11 нче санында Г. Исхакыйның мәкаләсендә мондый юллар бар: «Ерак Шәрекътән Хөсәен Габдүш әфәнде, Тукайның 20 еллыгын хәтерләтеп, Харбинда бер рисалә бастырып таратты һәм бу мәсьәләгә дикъкатьне җәлеп итәргә тырышты. Хөсәен әфәнде үз тарафыннан билгеле бер програм тәклиф итмичә[2], фикер эшләтер өчен юллар гына күрсәтә»[3].

Аның күләме 8 биттән гыйбарәт булып, кулдан язылып, махсус машинада күбәйтеп таратылган. Ул «Татар шагыйре Габдулла Тукай (Үлүенә 19 ел тулу уңае белән)» дип атала һәм 1932 ел белән билгеләнгән[4]. Бәясе 15 тиен дип күрсәтелгән. Бу уңайдан автор үзенең максатын беренче биттә үк болай аңлата: «Ошбу китапчыкның мәсарыфын[5] уртаклашучы ханым вә әфәнделәргә тәшәккерләр бәян ителә. Рисаләне сатудан килгән барлык табыш шагыйребезнең нинди дә булса берәр әсәрен бастыру юлына китәчәктер». Аннан соң автор кыскача гына Г. Тукайның авыр тормыш хәлләрен билгеләп үтә.

Г. Тукай әсәрләренең теленә бәя биреп, ул болай ди: «Зур-кечкенәләребез, яшь вә картларыбызның барысы да аңлардай садә, ләкин искиткеч оста бер телдә аңлатып бирде... Кай шигырьләрендә беренче кат туган телебезнең матур музыкасы яңгырады»[6].

«Олуг кешеләрнең туган вә үлгән көннәрен искә алу һәм мондый көннәргә туры китереп алар исеменә файдалы бер эш тудыру мәдәни халыкларда кабул ителгән бер гадәт», — дип, 1915 елда Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) тууына 100 тулу уңае белән Казанда аның турында җыентык басылуын, шушы елда немец шагыйре Гетенең вафатына 100 тулуны бөтен дөньяда билгеләп үтүләрен яза. Шулай ук ул вакытта исән булган М. Гафури, Г. Камал, Г. Ибраһимов, Г. Исхакыйның әдәби эшчәнлекләренә багышланган юбилей чаралары үткәрелүне дә искә төшерә.

Г. Тукайның вафатына 20 ел тулу уңаеннан Ерак Шәрекътә яшәүче милләттәшләребез нәрсә эшли алчак соң дигән сорау куеп, Казандагы «Тукай комитеты» эш планының «Яңа милли юл» журналында басылган күчермәсе белән кыскача гына таныштыра. Шуның белән бергә ул үзенең тәкъдимнәре белән дә уртаклаша. Ягъни Токио һәм Берлин басмаханәләрен файдаланып, Г. Тукайның аерым әсәрләрен кечкенә арзанлы китапчыклар итеп бастыру. Моны, мәсәлән, Харбинда, Хайларда, Токиодагы милли оешмалар һәм аерым кешеләр алынып башкарырга мөмкин. Ул бу мәсьәләне балалар әдәбиятына булган зур ихтыяҗ белән дә аңлата.

---

[1] *«Яңа милли юл»* — 1928 елның 23 декабреннән 1939 ның октябренә кадәр Берлинда, Варшавада татар телендә айга ике тапкыр нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси, фәнни-әдәби журнал. Барлыгы 136 саны дөнья күрә. 1930 га кадәр «Милли юл» исем белән басыла.

[2] *Тәклиф итмичә* — тәкъдим итмичә.

[3] Исхакый Г. Тукай истәлеге. Габдулла Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае белән / Г. Исхакый // Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай / Төз. З. Г. Мөхәммәтшин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — Б. 22.

[4] Габдүш Х. Татар шагыйре Габдулла Тукай (Үлүенә 19 ел тулу уңае белән) / Х. Габдүш. — Харбин, 1932. — 8 б.

[5] *Мәсарыф* — чыгым.

[6] Габдүш Х. Татар шагыйре Габдулла Тукай... — Б. 4.

Китап авторы, шагыйрьне күреп-белгән кешеләргә мөрәҗәгать итеп, аларның истәлек-хатирәләре тупланган бер мәҗмуга да бастыруны күтәреп чыга. Хәбәрләшү өчен Берлинда яшәүче Рәшит Рәхмәтинең (1900–1964) һәм үзенең адресларын күрсәтә.

Х. Габдүшнең (1901–1944) фикерләрен Г. Исхакый да хуплап чыга. Аерым алганда, ул болай ди: «Безнеңчә, бу һичбер сәяси булмаган эш өстендә безнең бөтен мәдәни көчләребез берләшергә һәм, кайда гына булса да, бергәләшеп шул уртак бурычны үтәргә тиеш. Инде бу искә алуның програмына килгәндә, хәзерге көндә Тукайның аерым әсәрләрен бастырып булса да, аның «Мәҗмугаи асаре»н бастырырга безнең мөһаҗәрәттә матди көч юк дигән фикердәбез. Аның кайбер әсәрләрен аерым-аерым бастыру һәм Тукайга багышлап бер китап, бер мәкалә җыентыгы чыгару эше кала»[1].

Бу китап, автор үзе билгеләгәнчә — китапчык — фикеребезчә, берничә юнәлештә кыйммәткә ия. Ул, беренчедән, мөһаҗирлектә Г. Тукайга багышланган беренче басма. Икенчедән, аның эчтәлегеннән күренгәнчә, Харбиндагы милләттәшләребезнең ул вакыттагы матди хәле бик үк яхшыдан булмаса да, аларны олуг шагыйребезне зурлап искә алырга, бу уңайдан файдалы эшләр башкаруда Ерак Шәрекътә хәят кичерүче барлык татарларны берләштерергә омтылыш ачык чагыла.

Ул Г. Тукайга багышланган барлык чараларны үткәрүдә башлап йөрүчеләрнең берсе була һәм аларны үткәрүдә зур активлык күрсәтә. Мәсәлән, шагыйрьнең вафатына 20 ел тулу уңаеннан Харбинда шагыйрьне искә алу кичәсендә Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә», К. Бәкернең «Бәйрәм хатирәләре» дигән әсәрләре турында реферат укый, махсус чыгарылган газетага мәкалә яза.

Г. Тукай вафатының 24 еллыгында багышланган кичәдә ул шагыйрьнең «Милли моңнар»ын «Әллүки» көенә, «Сайра, сандугач», «Сакмар суы» кебек җырларны халык соравы буенча кат-кат җырлый.

Г. Тукай вафатының 26 еллыгын билгеләп үткәрелгән кичәдә шагыйрьнең «Авыл хатынының бала тибрәткәндәге өмидләре» дигән шигыренең дә сәхнәләштерелгән күренеш тәкъдим ителә. Анда Х. Габдүш тә катнаша. Тамаша алдыннан ул Г. Тукай турында кыскача гына нотык та сөйли.

1933 елда Токиода матбагаи исламиядә Г. Тукайның «Мәҗмугаи асар»е биш китап итеп бастырыла (чынлыкта беренче күптомлыгы!)[2].

---

[1] Исхакый Г. Тукай истәлеге... — Б. 23.

[2] Тукай. Мәҗмугаи асәре. Беренче бүлем: җитди шигырьләр. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 209 б.; Тукай. Мәҗмугаи асәре. Мәрхүм милли шагыйремезнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәтилә хатирә уларак басылды. Икенче бүлем: балалар кыйсеме. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 314 б.; Тукай. Мәҗмугаи асәре. Мәрхүм милли шагыйремезнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәтилә хатирә уларак басылды. Өченче бүлем: көлке вә һөҗү кыйсеме. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 89 б.; Тукай. Мәҗмугаи асәре. Мәрхүм милли шагыйремезнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәтилә хатирә уларак басылды. Дүртенче бүлем: нәсер кыйсеме. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 105 б.; Тукай. Мәҗмугаи асәре. Мәрхүм милли шагыйремезнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәтилә хатирә уларак басылды. Бишенче бүлем: тәрҗемәи хәле. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 105 б.

Г. Тукайның вафатына 25 ел тулу уңаеннан 1938 елда Мукден шәһәрендә «Габдулла Тукай»[1] дигән китап нәшер ителә. Ул Ерак Шәрекъ Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының дини, милли мәркәз мәгариф шөгъбәсе тарафыннан төзелә. Күләме 98 биттән гыйбарәт булып, эчтәлеген унике мәкалә, шагыйрьгә багышланган биш шигырь, Тукайның үзенең өч шигыре һәм Х. Зәбири истәлегеннән өземтә тәшкил итә. Китапның тышлыгында әдипнең «Үз-үземә»сеннән шундый юллар китерелгән:

Күңел берләп сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.
Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Бу китапның басылып чыгачагы турында «Милли байрак»[2] газетасы 1938 елгы 22 апрель санында игълан итә. Ул 1939 елда да Г. Тукайны искә алу кичәсендә сатыла.

Кереш алдыннан аерым биттә Ж. Вәлиди 1914 елда бастырган Тукайның «Мәҗмугаи асар»ендәге мәкаләсеннән өземтә китерелә.

Китапны төзүчеләр керештә болай дип язалар: «Рус большевик туфаны белән чит илләргә сибелгәнебездән бирле узып киткән егерме ел эчендә милли, мәдәни барлыкларыбызны, дини, милли үзлегебезне үзгәртми саклаучы мөһаҗәрәттә Тукайны искә алуда еллык «Тукай кичәләре», «истәлек утырышлары»ннан артыкны эшли алмады». Шуңа күрә әлеге китапны бастырып чыгару «шул бушлыкны аз гына булса да тутыру, чит илдә үсә торган яшьлекне Тукай белән таныштыру» максатыннан башкарылган. Аның матди чыгымнарын мәркәз әгъзалары Хөсәен Биглитси (?–?) һәм Сабир Җиһаншаһ (?–?) әфәнделәр күтәргән икән.

Анда әйтелгәнчә, китапны төзүчеләр Ж. Вәлиди бастырган мәҗмуга, Габдерахман Сәгъдинең (1889–1956) «Мохтасар кавагыйде әдәбиягә гыйлава»сы (Уфа, 1911), Ф. Бурнаш төзеп нәшер иткән «Тукай шигырьләре» (Казан, 1926) белән таныш булган. Г. Тукайның Фатих Сәйфи-Казанлы (1888–1937) тарафыннан төзелеп дөнья күргән өч томлы «Әсәрләр»е (1929–31) мәгълүм сәбәпләр аркасында алар карамагында булмаса да, шагыйрьнең Токиода дөнья күргән «Мәҗмугаи асар»е искә алынмавы бераз гажәпләндерә.

Керештән соң Үтәмеш тәхәллүсе белән язучы публицист һәм тәрҗемәче, Мукденда нәшер ителгән «Милли байрак» газетасының җаваплы хезмәткәре, публицист һәм тәрҗемәче Рокыя Мөхәммәдиш (1908–1989) укучыларны кыскача гына Тукайның тәрҗемәи хәле белән таныштыра.

Г. Исхакыйның Варшавадан юллаган мәкаләсендә Ж. Вәлиди бастырган китаптан башка җитди әйберләр дөнья күрмәве ассызыклана. Хосусан, әдип болай яза:

---

[1] Габдулла Тукай 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән). Тәртип итүчесе һәм нашире: Ерак Шәрекъ Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының дини, милли мәркәз мәгариф шөгъбәсе. — Мукден, 1938. — 98 б.

[2] *«Милли байрак»* — 1935 елның 1 ноябреннән 1945 нең август башына кадәр Мукден шәһәрендә татар телендә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси газета. «Ерак Шәрекъ төрки-татар мөселманнарының дини-милли Идел-Урал мәркәзе» органы. Барлыгы 440 саны дөнья күрә.

«Бу егерме биш ел бик җитәрлек мөддәт[1] булса да, Тукайның иҗаты хакында бүгенге көнгә кадәр нә бер җентекләмә, нә бер тәнкыйть китабы язылганыны без белмибез, күрмибез»[2].

Г. Исхакый илдәге вәзгыятьне гаепләү белән бергә, мөһаҗәрәттәге яшьләрнең, аерым алганда Төркия югары уку йортларында укучыларның бу хосуста эш эшләмәүләрен тәнкыйтьли. Чит илләрдә яшәүче украиннарның Тарас Шевченконы (1814–1861), гөрҗиләрнең Шота Руставелине (XII), мөселман булуына карамастан, бөтен дөньяга таныту белән шөгыльләнүләрен үрнәк итеп куя.

Г. Исхакый шагыйрьнең иҗатына берникадәр анализ ясап, аны милләт язмышы белән берлектә карый.

Харбиннан язган Х. Габдүш фикеренчә, Тукайда телебезгә карата булган мәхәббәт Каюм Насыйри (1825–1902) тәэсирендә барлыкка килгән. Ул шагыйрьнең балалар әдәбияты үсешенә керткән өлешенә дә игътибарны юнәлтә.

Сәгадәт Чагатай (1907–1989) (Берлиннан) язмасыннан күренгәнчә, Тукай турында илдә күп мәкаләләр басылса да, ул алар белән танышу мөмкинлеге булмауга борчылуын белдерә. Шуңа күрә, нигездә, төрек галиме Фуат Күпрелезадә (1890–1966) һәм Ж. Вәлиди хезмәтләренә таяна. Г. Тукайның башлангыч чор иҗатына госманлы шагыйрьләренең тәэсирен билгели, шагыйрь әсәрләрендә гаруз вәзене мәсьәләсенә туктала.

Кобе шәһәре имам-хатыйбы Мәдъяр хәзрәт Шәмгуни (1874–1939) Г. Тукайның «Васыятем» шигыре турында сүз йөртеп, аны Коръән Кәримдәге аятьләр белән чагыштыра. Аерым алганда, ул болай яза: «Үз ана телебездә ачык аңлатырлык итеп, Аллаһының әмеренә буен сонарак үлемгә хәзерләнгәнене аңлатадыр. Вә иң мөһиме, бу хәзерлекне тәүбә истигъфар итәрәк, урынына җиткерәдер. Үзенең Аллаһыга кайтачагыны, Аллаһының тәкъдир вә әмеренә разый улыб буен сонганлыгыны кардәш, угылларына вә дустларына белдерәдер вә шул юл белән бөтен милләттәшләрен Аллаһының әмеренә буйсынырга чакырадыр. Бу кабилият Аллаһы тарафыннан шагыйрьгә бирелгән бөек нигъмәттер, юксәк[3] бәхеттер»[4].

Р. Мөхәммәдиш «Тукай иҗатында — ил шәүләсе» дип аталган икенче мәкаләсендә «Тукй яратышын күзебездән уздыру белән туган җиребезнең кадерле шәүләсе күңелебездә тагы бер мәртәбә җанланганга, Тукай безнең күңелебездә тагы да ныграк урнашадыр. Аның туган җирне күренешләндергән әсәрләре аркылы йөрәгебезгә нигезләнгән ил мәхәббәте тагы да яңара, ныгая төшәдер»[5], — дип яза.

Балалар тәрбиясе өчен Г. Тукай иҗатаның әһәмияте турында Мәдинә Салиәхмәт (1897–1964) (Шанхайдан) аның «Сагыныр вакытлар», «Туган тел», «Гомер юлына керүчеләргә» дигән шигырьләре нигезендә сүз алып бара. Мәкалә авторы шагыйрь

---

[1] *Мөддәт* — вакыт.

[2] Исхакый Г. Шагыйрь Габдулла Тукай / Г. Исхакый // Габдулла Тукай 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән)... — Б. 16.

[3] *Юксәк* — зур.

[4] Шәмгуни М. Габдулла Тукайның вафатына егерме биш ел тулу мөнәсәбәтилә / М. Шәмгуни // Габдулла Тукай 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән)... — Б. 47.

[5] Мөхәммәдиш Р. Тукай иҗатында — ил шәүләсе / Р. Мөхәммәдиш // Габдулла Тукай 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән)... — Б. 50.

иҗатында балаларга дини тәрбия бирү, аларга дөньяда яшәү максатын күрсәтү кебек мөһим мәсьәләләргә дә игътибар итә.

Алдагы тема Харбиннан Маһирә Кодәки (?–?) мәкаләсендә дә дәвам иттерелә. Ул тикшеренү материалларын киңәйтә төшеп, Г. Тукайның «Эш», «Һәр ялтыраган алтын түгел», «Шүрәле» һәм башка әсәрләрен анализлый, аларның мәктәп балаларын тәрбияләүдәге ролен билгели. Аерым алганда, ул болай яза: «Балалар әдәбиятына мохтаҗлыгыбыз хәзер дә зур, әмма Габдулла Тукайның әсәрләре зур бер бушлыкны тутыра»[1].

Шагыйрь Әхмәт Виргаз (?–?) (Харбиннан) Г. Тукай турында язган Ж. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш хезмәтләренә күзәтү ясый. Нинди генә бәяләмә бирелсә дә, аның халык шагыйре булып калуын ассызыклый, телебезне үстерүгә керткән өлешен икърар итә.

Г. Тукайның милләтне тәрбияләү мәсьәләсе Хәсән Ибраһим (?–?) (Мукден) мәкаләсендә күтәрелә. Бу уңайдан ул болай яза: «Менә шул Тукай татар милләтен аның теле ачылган сәгатеннән башлап милли, дини рухта тәрбияләде, шул хисләр белән сугарды. Ул үзенең кыска гына булган гомеренең бөтенләен дип әйтерлек төрек-татар милләтенә багышлады»[2].

Мәкаләләр бүлемен Р. М. (Рокыя Мөхәммәдиш) имзасы куелган язма тәмамлый. Анда сүз Г. Тукайга милли матбугатның мөнәсәбәте турында бара. Аерым алганда, «Вакыт», «Тәрҗеман», «Тасвиры әфкяр», «Икъбал», «Милли байрак» гәзитләре, «Шура», «Төрек йорду», «Ислам дөньясы», «Милли юл» журналлары шагыйрь иҗатын киң гавәмгә җиткерүдә башкарган эшчәнлекләре әтрафлы яктыртыла. Автор икенче бер мәсьәләне дә читләтеп үтмичә, болай яза: «Матбугатның бик кыска вакыт эчендә Тукайга югары урын бирүе, көлке вә һәжү шигырьләрендәге каләменең үткенлеге Тукайга дустлар биргән төсле, дошманнар да тудырды»[3]. Бу җәһәттән ул «Йолдыз» гәзитәсен истә тота һәм Г. Ибраһимовны атый.

Г. Тукайга багышлап язылган шигырьләр шәлкемен Харбиннан Солтанның (Әхмәт Виргазның) «Шагыйрьгә», Ләнсидән Исхак Арсланның (1910–?) «Тукайга», Маолиннән Заһидәнең «Сөекле шагыйрьгә», Мукденнан Габдулла углының (?–?) «Тукай рәсеменә карап», Хафиз Шахмайның (?–?) «Тукайга багышлап» дигән әсәрләре тәшкил итә.

«Тукай «Мәҗмугаи асар»енә кертелмәгән шигырьләр» дигән бүлемдә урнаштырылган «Өмидсезлек» дигән шигырьнең «Вакыт» газетасының 62 нче санында бастырылганы әйтелсә дә, текст Г. Сәгъди хрестоматиясеннән алынганлыгы күрсәтелгән. Бу шигырь Ф. Бурнаш төзеп бастырган җыентыкка да кертелгән. «Бер мән» шигыре шулай ук «Вакыт» газетасының 1910 елгы 22 сентябрендә, «Иһтида» шигыре «Шура» журналының 1911 елгы 12 нче санында дөнья күргәнлеге искәртелә.

---

[1] Кодәки М. Тукай һәм мәктәп / М. Кодәки // Габдулла Тукай 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән)... — Б. 67.

[2] Ибраһим Х. Тукай төрек-татар халкының мөрәббисе / Х. Ибраһим // Габдулла Тукай 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән)... — Б. 75.

[3] Р. М. Тукай милли матбугатыбызда / Р. М. // Габдулла Тукай 1913 апрель 1938 (вафатына 25 ел тулу уңае белән)... — Б. 88.

Китапта Г. Тукайның вафатына санаулы сәгатьләр калганда Клячкин шифаханәсендә, табутта, җеназасын Казан имамнары күтәргәч, кабере өстендә алдырган, шагыйрьнең туган авылы Кушлавыч, туган өе, Яңа Кырлай авылында иң әүвәл укый башлаган мәдрәсә, ягъни Фәтхерахман хәзрәт йорты, «Болгар» номерлары фотоларыннан күчермәләр, «Васыятем» шигыре кулъязмасының факсимилесе урнаштырылган.

1946 елда Г. Тукайның тууына 60 ел тулу уңае белән Голҗа шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан шагыйрьнең юбилеен билгеләп үтү планлаштырыла. Әмма ул вакыттагы билгеле иҗтимагый-сәяси сәбәпләр нәтиҗәсендә, бу чара 1947 елга күчерелә. Ул шәһәр уртасындагы «Урыс клубы» дип йөртелә торган зур театрда уздырыла. Мәктәп укучысы буларак анда катнашкан Зифа Табиева (Сәфәргали) үзенең истәлекләрендә бу хакта болай дип яза: «Тантаналы кичәне әткәем (Рәхим Сәфәргали (1904–1970) — *Р. И.*) 40 минутлык доклады белән ачып җибәрде. Аннан соң мин үзем «Тукай маршы» белән «Васыятемне» җырлаган идем, Зия абзый Хөсәеннең скрипкада уйнаганын хәтерлим. Мәктәп балалары Г. Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен сөйләделәр, кечкенә күренешләр күрсәттеләр, мәсәлән, — «Эш беткәч, уйнарга ярый» (Миркасыйм Госманов малай ролендә иде), «Фатыйма белән сандугач» (җырлаучылар: Зифа Сәфәргали — Фатыйма, Сагъдия — сандугач), җырлы һәм биюле «Бала белән күбәләк» — күбәләкләр биюе һәм башкалар. Татар оешмасыннан зурлар Г. Тукайның «Яңа ысулы кадимче»се белән «Шүрәле» поэмасын сәхнәләштереп, күп шигырьләрен дә сөйләгәннәр иде. Хәйрия максатыннан лоторея дә уйналган. Шулай итеп, бик зур концерт бирелгән иде»[1].

Әлеге мәдәни чараның тагын бер әһәмиятле ягы шунда ки, юбилейга 700 тираж белән «Г. Тукай, Сайланма шигырьләре»[2] дигән җыентык та бастырылып таратыла. Яңартылган гарәп алфавитындагы уникаль бу китапның үзендә сакланган бердәнбер нөсхәсен уйгыр шагыйре, публицист Торсын Kahhари (1924–2008) 1986 елда Г. Тукайның тууына йөз ел тулуга багышланган бәйрәм чараларында катнашырга Казанга килгәч университет китапханәсенә бүләк итә[3].

Китап Хәмит Төхфи (1922–1994) тарафыннан язылган «Г. Тукай» дигән кереш мәкалә белән ачыла. Анда шагыйрьнең кыскача тәрҗемәи хәле бәян ителә, иҗатының татар халкы өчен бибәһа кыйммәткә ия булганлыгы ассызыклана. Аннан соң Г. Тукайның егерме ике шигыре урнаштырылган. Бу мәҗмуга, инде әйтелгәнчә, хәзергә билгеле бердәнбер нөсхә булуын истә тотып, андагы әсәрләрнең барысын да әйтеп үтү урынлы булыр. Хосусан, алар: «Шагыйрь», «Әхлаксызлык», «Нәсихәт», «Алтынга каршы», «Сәрләүхәсез», «Милли моңнар», «Чын вә ялган», «Кыйтга», «Шекспирдән», «Толстой сүзләре», «Өзелгән өмид», «Сагыныр вакытлар», «Ваксынмыйм», «Тәләһһеф», «Теләнче», «Буран», «Туган җиремә», «Төлке һәм йөзем җимеше», «Васыятем», «Тәэссер», «Туган тел», «Пар ат».

---

[1] Табиева З. Хәтерлим... / З. Табиева // Казан утлары. — 2007. — № 5. — Б. 165.

[2] Габдулла Тукаев шигырьләре. Шагыйребез Габдулла Тукаевның дөньяга килүенә 61 ел тулу мөнәсәбәте белән бастырылды / Тех. ред. Х. Төхфи; ред. И. Юнич; нашире: Голҗа татарларының мәдәни җәмгыяте. — Голҗа: Инкыйлаби Шәркый Төркестан халык матбагасында басылды, 1947. — 17 б.

[3] Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Т0121828 шифры астында саклана.

Без биредә китапта урын алган мәкаләләргә ниндидер бәяләмә бирүне максат итеп куймадык һәм аның кирәге дә юк. Чит җирләрдә, авыр шартларда яшәп тә, сөекле шагыйребезгә карата булган ихтирам мөнәсәбәте чагылышы булган бу мәҗмуга хәзерге фән югарылыгыннан бары тик уңай кабул ителергә һәм Г. Тукайны өйрәнү юнәлешендә тиешенчә файдаланылырга тиеш.

Шинҗаң-Уйгыр автономлы районында хәят кичерүче милләттәшләребез җәмгыятенең 1987 елның декабрь аенда беренче җыелышы була. Анда катнашкан уйгырларның танылган шагыйре һәм галиме Рәхмитулла Җари (1926–1999) «Мәшһүр татар шагыйре Габдулла Тукай шигырьләренең кайбер үзенчәлекләре» дигән зур доклад белән чыгыш ясый. Аерым алганда ул шагыйрьнең гаруз системасында ижат иткән әсәрләрен анализлый[1].

Әлеге мәдәни чарада катнашкан икенче уйгыр әдибе Абдурehим Үткер (1923–1995) «Уйгыр әдәбияте белән татар әдәбиятенең үзара тәэсире турында» дигән доклад ясый. Аерым алганда, Г. Тукай иҗатының уйгыр каләм ияләренә булган тәэсирен татар шагыйренең «Безне урынсыз яманлыйлар» дигән шигыре белән мәгърифәтче Абдухалык Уйгырның (1901–1933) «Бардур» шигыре мисалында исбатлый:

Йнә йорт пайдисига җәмы булмақлық бәс мөшкүл,
Әгәр бер йәрдә той булса, берип йатқанимиз бардур.
Умумниң пайдисини йүз йылда һәм әсла чүшәнмәймиз,
Зиян қылмақ үчүн болса, әҗәп, чаққанимиз бардур.
Бере бер йахшилиқ қилса, униң йадини қилмақ юқ
Ибе кәлсә, барып әврәтләрен ачқанимиз бардур[2].

Әлеге җәмгыять 1998 елда «Габдулла Тукайның сайланма шигырьләре»[3] дигән җыентык та бастыра. Анда шагыйрьнең тәрҗемәи хәле турында кыскача белешмәдән соң аның кырык сигез шигыре урнаштырылган. Алар арасында «Туган тел», «Туган җирем», «Пар ат», «Бәйрәм бүген», «Шагыйрь», «Бала белән күбәләк», «Фатыйма белән Сандугач» һәм башкалар бар. Җәмгыять шулай ук 2000 елдан «Җуңго татарлары» («Кытай татарлары») исемле махсус хәбәрләр тупламы да чыгара башлады. Аның беренче санында Илче Сайраниның «Габдулла Тукай»[4] дигән, А. Үткернең, Р. Җариның инде әйтелгән мәкаләләре басыла.

Төбәктә хәзерге вакытта да Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗты белән кызыксыну дәвам иттерелә. Әйтик, казакъ авторы Булантай Дусҗан «Шенҗаң газеты»ның 1996 елгы 25 май санында «Татар әдәбиятының таң чулпаны» дигән мәкалә бастыра. Тукайның төрки халыклар өчен дә якын һәм кадерле булуын билгеләп, ул болай дип яза: «Бу көн татар халкы өчен генә куанычлы көн булып калмады, тоташ төрки

[1] Җари Р. Мәшһүр татар шаири Абдолла Тоқай шеирләриниң бәзи алаһидиклери тоғрисида. — Үрүмчи, 1987. — 20 б. (гарәп графикасында, уйгыр телендә).

[2] Өткүр А. Уйғур әдәбияти билән татар әдәбиятиниң өз-ара тәсири тоғрисида. Үрүмчи, 1987. — Б. 20 (гарәп графикасында, уйгыр телендә).

[3] Габдулла Тукайның сайланма шигырьләре. — Ш. У. А. Р. татар тел тәтқиқать җәмгыяте, 1998. — 26 б.

[4] Сайрани И. Габдолла Тоқай / И. Сайрани // Җуңго татарлары. — 2006. — № 1. — Б. 30–36.

телдәге халыклар өчен дә куанычлы көн булып, тугандаш халыклар шагыйрьнең 10 ар еллык бәйрәм көннәрен искә төшереп, күркәм рәвештә билгеләп килә»[1].

Язмада алга таба казакъ халкының бөек акыны Абай (1845–1904) белән Г. Тукай иҗаты арасындагы тематик һәм идея уртаклыклары булган моментларга да игътибар ителеп, кызыклы күзәтүләр ясала. Мәкаләдә шулай ук Тукайның татар телен үстерүгә керткән өлеше дә югары бәяләнә.

«Элә газеты» дигән көндәлек басманың 2004 елгы 18 караша (ноябрь) санында милләттәшебез Гыйззәтулла Хәсәнев «Татар халкының якты йолдызы Габдулла Тукай турында» дигән мәкалә бастыра[2]. Язма авторы укучыларны Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыра. Шунысы кызыклы, ул үзенең фикерләрен шагыйрьнең әсәрләреннән өзекләр белән дәлилли. Мәкаләсе берникадәр үзгәреш-өстәмәләр белән «Шенҗаң газеты»ның 2008 елгы 31 октябрь санында тагын дөнья күрә[3].

Аның янә «Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай» дигән мәкаләсе «Элә кичлек газеты»ның 2006 елгы 13 декабрь санында басылып чыга. Ул, шагыйрьнең тәрҗемәи хәленнән кыскача хәбәр биреп, укучыларны Тукайның «Китап», «Театр», «Туган тел» шигырьләре белән таныштыра. Голҗа шәһәрендә Г. Тукай исемендәге урам булганлыгы турында язмасы да зур кызыксыну уята[4].

Г. Тукайның тууына 120 ел тулу уңаеннан «Болак» исемле журналның 2006 елгы 2 нче санында «Габдулла Тукай шигырьләреннән» дигән мәкалә дөнья күрә. Уйгыр классик әдәбияты һәм фольклоры буенча ике айга бер тапкыр чыга торган бу басмада башта Г. Тукай турында кыскача мәгълүмат бирелә. Аннан соң аның егерме шигыре китерелә. Алар арасында, мәсәлән, «Киңәш», «Татар кызларына», «Шагыйрь», «Мәхәббәт», «Хатыннар хөррияте», «Мөнафыйкка» һәм башкалар бар[5].

Бу юбилей мөнәсәбәте белән «Тарим» журналының 2006 елгы 4 санында Г. Тукай турында шулай ук кыскача белешмә белән шагыйрьнең өч, ягъни «Мәхәббәт», «Мәслихәт» һәм «Китап» дигән шигырьләре басылган[6].

«Элә балалар газеты»ның 2007 елгы 16 көкек (апрель) санында Г. Тукайга тулы бер бит багышланган. Анда шагыйрьнең фотосы һәм «Эш беткәч уйнарга ярый», «Эш», «Эшкә өндәү», «Ай белән кояш», «Карлыгач» дигән шигырьләре урын алган.

---

[1] Досжан Б. Татар әдебиетінең таң шолпаны / Б. Досжан // Шенҗаң газеты. — 1996. — 5 айдың 25 күни (гарәп графикасында, казакъ телендә).

[2] Хәсәнов Ғ. Татар халкының жарық жұлдызы — Ғабдолла Тоқай жөниндә / Ғ. Хәсәнов // Элә газеты. — 2004. — 18 қараша (гарәп графикасында, казакъ телендә).

[3] Әнүәрұлы Ғ. Татар халқының жарық жұлдызы — Ғабдолла Тоқай жөниндә / Ғ. Әнүәрұлы // Шенҗаң газеты. — 2008. — 31 қазан (гарәп графикасында, казакъ телендә).

[4] Хәсән Ғ. Ғолҗа қаласындағы Ғабдолла Тоқай атындағы көше / Ғ. Хәсән // Элә тарихы материалдары. — 2012. — № 29. — Б. 134–137 (гарәп графикасында, казакъ телендә).

[5] Абдолла Тоқай шеирлириндин // Булақ. — 2006. — № 2. — Б. 35–44 (гарәп графикасында, уйгыр телендә)

[6] Абдолла Тоқай шеирлириндин // Тарим. — 2006. — № 4. — Б. 138–139 (гарәп графикасында, уйгыр телендә).

Айга бер тапкыр нәшер ителә торган «Әдәби тәрҗемәләр» дигән журналның 2007 елгы 11 нче санында Г. Тукайның «Исемдә калганнар» автобиографик әсәре «Ядымда калганнар» исеме белән дөнья күрә[1].

«Җуңго татарлары»ның 2007 елгы 1 саны тулысынча Г. Тукайга багышлап чыгарыла.

Мәгълүм ки, элекке буын күп кенә казакъ шагыйрьләре Г. Тукайны үзләренең остазлары дип саныйлар иде. Биредә аларның барысын да билгеләп үтү мөмкинлеге булмау сәбәпле, игътибарны кайберләренә генә юнәлтү белән чикләндек. Мәсәлән, Солтанмәхмүт Торайгыров (1893–1920) «Досыма хат», «Көк өгіз», «Туған еліме», «Түрмысқа», «Әне, міне», «Шал алған қыз», «Тұсімде күрген аянышты хал», «Арыстан мен тышқан», Сабит Дөнентаев (1894–1933) «Ұлтшылдарға» дигән шигырьләрен Г. Тукайның «Милләтчеләргә», «Дустларга бер сүз», «Күк сыер», «Туган илемә», «Тормыш», «Әнә-менә», «Алданган татар кызына», «Төш», «Сөткә төшкән тычкан» шигырьләре үрнәгендә язганнар.

Билгеле булганча, казакъ шагыйрьләре тарафыннан Г. Тукайга багышлап поэмалар, шигырьләр дә иҗат ителгән, чәчмә әсәрләрдә аның образы гәүдәләндерелгән. Әдәбият галиме Бөркет Исхаков (1924–1991) язганча, «Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып йөргән бер казакъ шәкерте 1913 елда, шагыйрь вафат булгач, түбәндәге шигырьне иҗат итә:

Татарда ақын өтті Тоқай деген,
Жетіж боп жас басынан қалған шемен,
Сұм ишан, надан сопы, бай-саудагер
Өлеңін оқығанда қаққан елең...
Қылуға жанын пида даяр болып,
Халықтың, нашарлардың қамын жеген.
Әр сөзі гауһар тастай жарқылдаған,
Шіркін-ай, ақын еді ойы терең[2].
(Татарда шагыйрь булды Тукай дигән,
Ятим булып яшь көе булган шәхес,
Ярты ишан, надан суфый, бай-сәүдәгәр
Шигырен укыганда шаккаткан.
Жанын фида кылырга әзер булып,
Халыкның, юксылларның гамен җыйган.
Һәр сүзе гәүһәр таштай ялтыраган,
Әй, гажәп, шагыйрь иде уе тирән.)

Бу уңайдан янә Әсәт Найманбаевның (1867–1923) « Абдолла Тоқай торалы», Жақан Сыздыковның (1901–1977) «Абдолла Тоқайға», «Тоқай — Қарабалықта» «Тоқай зиратында», Төкен Әлимкуловның (1918–1987) «Абдолла Тоқай», Габбас Жомабаевның (1924–1980) «Тукай җыйган хәрефләр», Изтай Мәмбетовның (1929–

[1] Тоқай А. Ядымда калғанлар / А. Тоқай // Әдәби тержимәләр. — 2007. — № 11. — Б. 66–76.

[2] Ысқақов Б. Қазақ және Еділ бойы халықтары әдебиеттерінің идеялық-творчестволық байланыстары (Шығу тегі мен жолдары) / Б. Ысқақов. — Алматы: Арыс, 2007. — Б. 104.

1974) «Беренче Тукай», Сабит Мокановның (1900–1973) «Гомер мәктәбе» дигән әсәрләрен һәм башкаларны әйтергә мөмкин.

Әлеге күркәм традиция казакъ кардәшләребез арасында хәзерге вакытта да бәрәкәтле дәвам иттерелүе белән игътибарга һәм ихтирамга лаек. Мәсәлән, талантлы яшь каләм ияләреннән берсе Нурбулат Абдыкадыйр «Элә киче» газетасының 2006 елгы 1 март санында үзенең иҗат үрнәкләре белән бергә «Габдулла Тукай турында ода» дигән шигырен дә бастыра[1].

«Элә киче» газетасының 2011 елгы 24 тамыз санында Г. Тукай турында белешмә бирелеп, уналты шигыре казакъ телендә бастырыла.

Г. Тукайның тууына 125 ел тулу уңае белән Г. Хәсәновның «Элә газеты»нда[2], кытай телендә нәшер ителә торган «Элә кичлек газеты»нда[3], Мөнир Ерзинның (1927–2020) «Уйгыр авазы»[4] газетасында күләмле язмалары дөнья күрә. Соңгысының «Тукай һәм хәзерге заман уйгыр әдәбияты» исемле мәкаләсендә кызыклы мәгълүмат китерелә[5].

«Җуңго татарлары»ның 2015 елгы санында Г. Тукайга багышланган ун мәкалә урын алган.

Шулай итеп, Шенҗаң-Уйгыр автономлы районында электә дөнья күргән һәм хәзерге вакытта нәшер ителә торган китапларда, вакытлы матбугат битләрендә Г. Тукай турындагы мәгълүматка багышланган зур булмаган әлеге күзәтүнең нәтиҗәләре киләчәктә шагыйребезнең тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнүдә әһәмиятле өстәмә чыганакларның берсе булырга мөмкин.

Мөһаҗәрәттәге татар диаспорасы тарафыннан Г. Тукайны искә алу чаралары турында профессор Надир Дәүләтнең (1944–2021) аналитик мәкаләсендә[6], әдәбият галиме З. Мөхәммәтшин тарафыннан төзеп бастырылган «Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай»[7] дигән китапта өстәмә мәгълүмат табарга мөмкин. Төркиядә 1965–1968 елларда махсус «Tukay bülteni»[8] («Тукай бюллетене») не») нәшер ителүен дә әйтеп үтү зарур.

---

[1] Әбдеқадыр Н. Ғабдолла Тоқай туралы ода / Н. Әбдеқадыр // Элә кеші. — 2006. — 1 савир (гарәп графикасында, казакъ телендә).

[2] Хәсән Ғ. Ғұлама ақын Ғабдолла Тоқай халық жүрәгендә / Г. Хәсән // Элә газеты. — 2011. — 26 савир (гарәп графикасында. Казакъ телендә).

[3] Хэй джа туоола Эй ни ва ер. Ха бу ду ла Туо хэй де вэнъ чо чуан зуо и шу хэ шен йа // Или Вэнь Бао. — 2011. — 5 июё. [«Тукайның әдәбияттагы урыны һәм тормыш юлы»]

[4] Ерзин М. Шәриқ шеирийитиниң бүйүк намабәндиси (Абдулла Тоқайниң туғулғаниға — 125 жил) / М. Ерзин // Уйғур авази. — 2011. — 22 апр.

[5] Ерзин М. И. Тукай һәм хәзерге заман уйгыр әдәбияты / М. И. Ерзин // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышл. Халыкара фәнни-гамәли конф. материаллары (Казан ш., 25 апрель, 2011 ел) / Төз.: Э. М. Галимҗанова, Г. А. Хөснетдинова; фәнни ред. Р. М. Кадыйров. — Казан, 2011. — Б. 68–70.

[6] Дәүләт Н. Татар диаспорасы һәм Тукай / Н. Дәүләт // Казан утлары. — 1997. — № 5. — Б. 168–172.

[7] Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай... — Б. 128–171.

[8] Миңнегулов Х. Й. «Тукай бюллетене» / Х. Й. Миңнегулов // Габдулла Тукай. Энциклопедия / Баш мөх. З. З. Рәмиев. — Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты, 2016. — Б. 642.

VIII

Г. Тукай турында истәлекләр аның тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнүдә мөһим чыганакларның берсен тәшкил итә. Аларны барлау-туплау, матбугатта бастыру һәм аерым китап итеп нәшер итү юнәлешендә максатчан эш шагыйрь вафатыннан соң башлап хәзергә кадәр дәвам иттерелә. Әмма бу хосуста ирешелгән казанышлар белән бергә башкарыласылары да байтак. Чөнки, мәгълүм булганча, күп кенә чыганаклар үз вакытында хаким идеология таләпләре нигезендә шактый «эшкәртелгән» рәвештә дөнья күргәннәр, ә байтагы, кызганыч ки, һаман хәзерге укучыга билгесез булып кала килә.

«Кояш» газетасының 1913 ел 18 апрель санында «Мәгариф» көтепханәсе тарафыннан хат-мөрәҗәгать басылып чыга. Хосусан, анда сүз «Габдулла Тукаев кем?» исемле бер мәҗмуга нәшер итеп, шуннан килгән файданы аның хакында эшләнәчәк хәер эшкә тотылачагы белдерелә.

Әлеге җыентыкта Г. Тукайның тулы һәм җентекле тәрҗемәи хәле, язган әсәрләре, төрле кешеләргә күндергән хатлары, әсәрләре хакында матбугат битләрендә язылган тәнкыйтьләр, вафаты мөнәсәбәте белән басылган мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар, рәсемнәр, аның турында язылган фикерләр, хатирәләр һәм башкалар урын алачагы белдерелә.

Әйтелгәннәргә карата берәр төрле мәгълүматы булган дуслары, иптәшләре һәм башка затлар шул хакта хәбәр итүләрен, кемгә дә булса язган хатларының асыл нөсхәләрен, әлбәттә, кире кайтарып бирү шарты белән, биреп торулары үтенелә. Бу хат-мөрәҗәгатьне башка газета-журналларның да күчереп басулары сорала.

Күренә ки, анда игълан ителгән программа гамәлгә ашкан булса, кулыбызда XX йөз башында ук тупланган гаять бай эчтәлекле истәлекләр җыентыгы булыр иде. Әйтергә кирәк, ул хәзергә кадәр дә гамәлгә ашырылмаган. Моның объектив һәм субъектив сәбәпләре бар, әлбәттә.

Югарыда китерелгән хат-мөрәҗәгать белән бер үк вакытта «Йолдыз» газетасының 18 апрель санында Г. Тукайның бер төркем дус-ишләре исеменнән тагын бер хат басылып чыга. Анда шагыйрьнең тәрҗемәи хәле белән бергә аның турында хатирәләр бастырып таратырга дигән карарга килүләре, шул хакта мәгълүмат җыю өчен Г. Әхмәдуллин, Ә. Урманчиев һәм Ф. Туктаров җәнабләре тәгаен ителгәнлекләре бәян кылына, хәбәрләшү өчен тиешле адреслар күрсәтелә. Мөрәҗәгатьтә шулай ук әдипнең шигырьләре һәм чәчмә әсәрләре хакында үз кулы белән язып калдырган васыятьнамәсе булса, шуны матбугат аркылы игълан итү үтенелә.

Әмма, озак та үтми, «Мәгариф» җәмгыяте «Кояш» газетасының 21 апрель санында «Ваз кичү» исемле хат бастырып, үзләренең әүвәлге хат-мөрәҗәгатьтәге программаны гамәлгә ашырудан баш тарта. Бу «Йолдыз» газетасында мөрәҗәгать белән чыккан төркем «эшенә каршы килү урынсыз» булу белән аңлатыла.

Г. Тукай турында истәлекләр җыйнау турында «Идел» газетасы да үзенең 1913 елгы 29 апрель санында язып чыга.

Г. Әхмәдуллин, журналист, педагог, язучы, «Ак юл»[1] балалар журналы нашире Ф. Агиев, нашир, журналист һәм педагог Ш. Әхмәрев тарафыннан 1913–1914 елларда рәсми хакимияткә берничә мәртәбә мөрәҗәгать итүгә карамастан, «Тукай җәмгыяте» оештыру тәкъдиме дә патша чиновниклары тарафыннан кире кагыла.

Болгавыр 1917 елда Тукай хөрмәтенә тел өйрәнү җәмгыяте төзү фикере дә кәгазьдә генә кала.

1913–1917 елларда татар көндәлек матбугатында Г. Тукай турында якын дусларының, аның белән турыдан-туры аралашкан кешеләрнең бик күп мәкаләләре дөнья күрә. Мәсәлән, «Йолдыз», «Кояш», «Вакыт», «Ил»[2], «Идел»[3], «Сибирия»[4] газеталарында, «Аң», «Ялт-йолт», «Мәктәп», «Сөембикә» журналларында нашир, «Аң» журналының мөхәррире Ә. Хәсәни, Ш. Әхмәров, күренекле дәүләт эшлеклесе Ш. Әхмәтҗанов (Манатов), С. Рәмиев, Ф. Әмирхан, Ф. Агиев, язучы, әдәбият галиме Гали Рәхим (1892–1943), «Юл» нәшрияты җитәкчесе, «Ялт-йолт» журналы мөхәррире Ә. Урманчиев, язучы Ф. Сәйфи-Казанлы, шагыйрә, журналист, педагог Маһруй Мозаффария (1873–1945), мөгаллим Хәлил Әбелхан (1887–1919), журналист Ягъкуб Байбурин (1880–1914), тәрҗемәче, язучы һәм журналист Солтан Рахманколый (1888–1916), язучы, журналист, сәясәтче, татар милли азатлык хәрәкәт эшлеклесе Г. Исхакый, журналист, партия-совет эшлеклесе Г. Гыйсмәти, талантлы артист, драматург, режиссер, профессиональ татар театрына нигез салучыларның күренеклесе Г. Кариев, язучы һәм педагог Гали Рәфикый (1890–1944), язучы, сәяси эшлекле Шәһит Әхмәдиев (1888–1930), журналист, театр һәм әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче Г. Кәрам, танылган әдип, публицист, телче, тәнкыйтьче, педагог, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Г. Ибраһимов, танылган шагыйрь һәм язучы М. Гафури, нашир, матбага эшлеклесе Г. Шәрәф, тарихчы, филолог һәм журналист Г. Баттал һәм башкалар шагыйрь турында үзләренең истәлекләрен бастырып чыгаралар.

Г. Тукайның Уральскида мәдрәсә сабакташы, тумышы белән Гурьевтан булган Я. Моради шагыйрь турында истәлекләрен әүвәл «Идел» газетасында бастырып чыгара. 1913 елда исә газета мөхәрририяте аны «Тукаев Уральскида» дигән китап рәвешендә нәшер итә[5]. Анда булачак шагыйрьнең шәкертлек еллары, К. Мотыйгыйның «Уралец» газетасы матбагасында эшләгән вакытлары турында кызыклы мәгълүмат китерелә.

---

[1] *«Ак юл»* — 1913 елның 15 апреленнән 1916 ның 22 гыйнварына кадәр Казанда айга ике тапкыр татар телендә нәшер ителгән рәсемле балалар журналы. Барлыгы 74 саны дөнья күрә.

[2] *«Ил»* — 1913 елның 22 октябреннән Петербургта, 1914 нең ноябреннән 1918 нең апреленә кадәр Мәскәүдә татар телендә атнага өч тапкыр нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси газета. Барлыгы 292 саны дөнья күрә.

[3] *«Идел»* — 1907 елның 26 июленнән 1914 нең 27 гыйнварына кадәр Әстерханда татар телендә атнага 2–3 тапкыр нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Барлыгы 623 саны дөнья күрә.

[4] *«Сибирия»* — 1912 елның 18 февраленнән 1913 нең 31 августына кадәр Томск шәһәрендә атнага 3–4 тапкыр татар телендә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Барлыгы 145 саны дөнья күрә.

[5] Моради Я. Тукаев Уральскида. Басылды «Г. Гомәрев вә шөрәкясенең» тиҗарәтханәсендә. — Астрахань: Тип. Т-го Д-ма «А. Умеров и Ко», 1913. — 24 б.

1914 елда К. Мотыйгыйның «Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем» исемле китабы дөнья күрә[1]. Бу чыганакта Г. Тукайның Уральскига килү вакытыннан алып Казанга кайтып киткәнгә кадәрге тормышы җентекле тасвирлана. Соңга таба икесе арасында килеп чыккан аңлашылмаучылыкны да ул объектив яктырта.

Шул ук елда К. Бәкернең «Тукай Петербугта» дип аталган китабы басылып чыга[2]. Анда Г. Тукайның Петербургка килү алшартлары хакында шулай диелгән: «...1912 елның алдында Петербургта бер кыйсем (төркем) яшь дини голәма арасында «Хәбәр» исемендә бер гәзитә чыгару фикере таралды. Шул вакыт Муса әфәнде Бигиев Казанга Тукайны чакырып хат язган. Ул вакыт Тукай бу хатка, ни өчендер, иҗабәт итмәгән (уңай җавап бирмәгән). Яз булгачтын, дәваланырга тугры килеп, шул уңайдан Петербургка да барып китәргә уйлаган...».

Тел-әдәбият галиме Ж. Вәлиди дә шагыйрь турында истәлекләр туплау белән шөгыльләнгән. Чөнки аның тарафыннан төзелеп нәшер ителгән «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» дигән китапның кереш өлешендә Уральск шәһәрендәге Түбән оч мәхәлләсе имамы, ахун, «Мотыйгыя» мәдрәсәсен нигезләүче һәм хуҗасы Мотыйгулла хәзрәтнең хат белән күндерелгән хатирәсе дә урнаштырылуы моңа ачык дәлил[3]. Хәзрәт, хосусан, Г. Тукайның Уральскига килү вакыйгасын, аның мәдрәсәдә укуын, нинди китаплар үзләштерүен, төрек шәкерте Габделвәли белән мөнәсәбәтен, үзенең улы Камил рус телендә «Уралец» «Уральский дневник», татарча «Фикер», «Уклар», «Әлгасрелҗәдит» басмаларын нәшер итә башлагач, шагыйрьнең анда хезмәттәшлек итүен бәян итә.

Г. Тукай Казанга китүенә өч-дүрт ел үтеп остазына хат язмавына Мотыйгулла хәзрәт дипломатик рәвештә «бусы инде аның бер нәни генә косуры булды» дип үзенең берникадәр үпкәләвен дә сиздерә.

Көндәлек матбугаттан күренгәнчә, Г. Тукай турында истәлекләр бастыру 1917 елдан соң да дәвам иттерелә. Әйтик, «Шәрекъ кызы»[4], «Укытучы»[5], «Мәгариф»[6] журналларында Ф. Әмирханның, гарәп мәдәнияте белгече Шәһер Шәрәфнең (1879–1938), Мәрьям Мөхетдиниянең (?–?), Ж. Вәлидинең мәкаләләре дөнья күрә.

---

[1] Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем. Мөәллифе: Мөхәммәдкамил әл-Мотыйгый Төхфәтуллин. Нашире: Габдулла Килдишев Казанда. — Казань: Электро-тип. «Умид», 1914. — 21 б.

[2] Бәкер К. Тукай Петербургта / К. Бәкер. — Оренбург: Электро-паровая Лито-тип. Т-а «Каримов, Хусаинов и К-о», 1914. — 64 б.

[3] Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Җәмаледдин Вәлиди тарафындан язылган Тукайның тәрҗемәи хале һәм әшгаре хакында бер мөляхәзә. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе Казанда. — «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1914. — Б. XX–XXVI.

[4] *«Шәрекъ кызы»* — 1918 елның мартыннан август аена кадәр Казанда татар телендә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси, әдәби хатын-кызлар журналы. Барлыгы 6 саны дөнья күрә.

[5] *«Укытучы»* — 1918 елның гыйнвар-июлендә Казанда татар телендә нәшер ителгән айлык иҗтимагый-сәяси, педагогик, әдәби журнал. Барлыгы 7 саны дөнья күрә.

[6] *«Мәгариф»* — «Мәктәп» журналының дәвамчысы буларак, 1918 елның ноябреннән 1919 ның мартына кадәр татар телендә нәшер ителгән айлык иҗтимагый-педагогик, фәнни-әдәби журнал. Барлыгы 3 саны дөнья күрә.

Г. Тукай Петербургта вакытта аның сәламәтлеген тикшертергә университет табибын алып килгән Ш. Мөхәммәдъяров 1918 елның 2 (15) апрелендә Мәскәүдә татар яшьләренең «Ташкын» исемле музыка һәм драма түгәрәге[1] тарафыннан шагыйрьнең вафатына биш ел тулу уңаеннан үткәрелгән әдәби кичәдә «Тукай кем?» дигән доклад сөйли. Аның бу чыгышы шул ук түгәрәк нәшриятында аерым китап итеп тә бастырыла[2].

Ш. Мөхәммәдъяров, аерым алганда, болай ди: «Мин сүземне бетерер алдыннан «Тукай кем ул?» дигән сөальгә: Тукай — гали җанлы, татар милләте халенә илһам белән вакыйф, татарның һәрбер сыйныф вә табәкасенең хален югарыда китергәнем шигырьләре белән тасвир иткән, моның белән милләткә фәүкыльгадә бөек хезмәт иткән, балаларымыз өчен әллә никадәр дәреслекләр язып исемен мәңге хәер белән яд итәрлек эш эшләгән бөек милләт хадимемез. Шуның белән бәрабәр, үзенең хосусый хәятендә аз гына да тәкъдиреннән ачык йөз, җылы сүз күрмәгән, ана сөтеннән аерылган көненнән ятлар кулына калып, бер сынык нан[3] белән мәдрәсә түрләрендә укып, үсә торган вакытларында ачлыктан зәгыйфь калып, бу уңайсызлыклар сәбәпле чахотка зәхмәтенә дучар булып, ахыргы сулышына кадәр каләмен ташламый, милли моңнарымызны көйләп, ялгызлыкта хастәханәдә вафат иткән аяулы шагыйремез, дим»[4].

Утызынчы елларда Г. Тукай турында бары тик «Совет әдәбияты»[5] журналында язучы һәм журналист Мәхмүт Галәүнең (1886–1938), танылган драматург Г. Камалның һәм шагыйрьнең ата бер, аналары башка апасы Газизә Зәбированың (1876–1963) мәкаләләре басыла. Ул вакытларда шагыйрьнең Уральскида иң якын дусларыннан берсе булган Рәхмәтулла Хәйруллин (?–?), шагыйрь, мөгаллим Миргазиз Укмасый (1884–1948), филолог, педагог Мөхәммәтхан Фазлуллин (1883–1964), фольклор галиме Х. Бәдигый тарафыннан да истәлекләр язылганлыгы мәгълүм, әмма алар кулъязмада калганнар.

Бөек Ватан сугышы алды елларында Г. Тукай хакында истәлекләр туплауда әдәбият галиме Я. Агишев, мәгариф хезмәткәре, шагыйрь Хәсән Шабанов (1901–1956) эшчәнлекләрен билгеләп үтү зарур. Бу чорда «Совет әдәбияты» журналында бары тик артист Касыйм Шамильнең (1892–1981) генә бер мәкаләсе дөнья күрә. Ә язучы Бари Рәхмәт (1897–1957), Барый Әминев (?–?), педагог Шәһид Рәҗәпов (?–?), педагог, полиграфия хезмәткәре Х. Зәбири, шагыйрьнең Уральскида сабакташы булган Шәриф Каюмов (?–?) язмалары басылмыйча кала.

Язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Гали (1893–1952), Татарстан АССР Халык Комиссариатының махсус карары нигезендә, 1944 елның 1–7 февраль көннәрендә

---

[1] 1917 елның октябрендә төзелгән.

[2] Мөхәммәдъяров Ш. Тукай кем? / Ш. Мөхәммәдъяров. — М.: Тип. «Восточная печать», 1918. — 22 б.

[3] *Нан* — икмәк.

[4] Мөхәммәдъяров Ш. Тукай кем?... — Б. 21.

[5] *«Совет әдәбияты»* — 1922 елның маеннан 1930 га кадәр Казанда татар телендә «Безнең юл», 1930–1932 дә «Атака» һәм «Яңалиф», 1933–1965 тә «Совет әдәбияты», 1965 тән «Казан утлары» исеме белән нәшер ителә торган айлык әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал.

Кызыл Юл (хәзерге Татарстан Республикасының Әтнә) районында командировкада булып, Г. Тукай турында материаллар туплый. Чөнки шагыйрьне күреп-белгән һәм аның белән якыннан аралашкан кешеләрнең күбесе ул вакытта исән була. Алар, мәсәлән, Яңа Кырлай авылыннан (тумышы белән Өчиледән булып, шагыйрьнең әнисе Бибимәмдүдә белән бергә үскән) Н. Әхмәтшина, кечкенә Габдулланы Ф. Гобәев мәдрәсәсендә укыткан Х. Гобәев (Хәбри хәлфә), булачак шагыйрьнең балалык һәм мәдрәсә елларында якын дусларыннан С. Мөхәммәтшин, Ахун Сабирҗанов (1886–1960), Камилә Хәлиуллина (1892–1968), Гариф Җәббаров (1887–?), Мөхәммәттаиб Әхмәтшин (1885–?), Гыйлаҗетдин Хөснетдинов (1880–?), Хәлилерахман Гобәйдуллин (1886–1951), замандашларыннан Сафиулла Хәбибуллин (1884–?), Фазылша Мөхәммәтшин (1875–?), Хәким Нигъмәтҗанов (1889–?), Галәветдин Сәйфетдинов (1896–?), Лотферахман Габдерахманов (1888–?), Өчиле авылыннан Кәмалетдин Бәдретдинов (1869–?), Садыйк Мөхәммәдиев (1865–?), Минһаҗ Йөзлекәев (1877–?), Кадыйр Вәлиев (1893–?), Р. Әмирова-Мөхәммәтҗанова. Язып алынган 19 язманың бары тик 3 се, ягъни Н. Әхмәтшина, А. Сабирҗанов, Р. Әмирова-Мөхәммәтҗанова истәлекләре генә шул вакытта «Совет әдәбияты» журналында басылып чыгалар. Аларда да кайбер кызыклы детальләр бар, югыйсә. Мәсәлән, Г. Җәббаров болай ди: «Мин военный службага алынгач Чита шәһәрендә хезмәт иттем. Шул вакытта яхшы гына укыган бер татар солдаты безгә минем туган авылым Кырлай турында язылган бер шигырь укып күрсәтте. Мин аптырап калдым. Ул шигырьне кем язганлыгын, аны язучы Тукаевның кем булганлыгын һичбер башыма китерә алмадым. Ул шигырьне безнең авыл Сәгъди абзыйның балалыкка алган малае, авыл мәктәбендә минем белән бергә укыган Габдулла язганлыгын һәм аның зур шагыйрь булып киткәнлеген тик солдаттан кайткач кына белдем».

Г. Хөснетдинов шулай сөйләгән: «Габдулла мәктәпкә килгәндә мин инде зур шәкерт булган идем. Шулай да ул бик тиз арада безне куып җитеп, узып китте. Без исемен дә белмәгән мәгънәле китаплар укый башлады. Хәбри хәлфә кушуы буенча безнең сабакларыбызны тыңлата һәм өйрәтә иде».

Х. Нигъмәтҗанов истәлегендә менә нинди мәгълүмат табарга мөмкин: «...Бервакыт Сәгъди картның тормышы бик начарланып китте. Зөһрә тәтәй үзе малай тапкач, Тукайга анда тору читенләште. Ул мәктәпкә күчеп тора башлады. Сәгъди картлардан ашарына алып килә алмый иде. Шуңа күрә мәктәптә ач тора иде. Ул вакытта мин бабайларда тора идем. Минем бабай Гыйбадулла исемле булып, авылның бай тормышлы кешесе иде. Мин Габдулланы еш кына бабайларга алып кайтып тамагын туйдырып җибәрә идем. Бабай безне үз янына утыртып чәй эчерә, ашата иде».

Истәлекләрнең барысы да хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгенең Г. Тукай фондында сакланалар.

Бибәһа кыйммәткә ия булган бу истәлекләрне сөйләп калдырган Яңа Кырлай авылы кешеләренең 1944 елның җәй айларында алдырылган күмәк, нәни Габдулла-

ның мәдрәсәдә сабакташларынан берсе Хәбиберахман Әхмәревнең 1886–1966) һәм Камилә Хәлиуллинаның (1892–1968) фотолары, шөкер, сакланып калган[1].

Күмәк фотода Н. Мөхәммәтшина, Х. Гобәев, С. Мөхәммәтшин, А. Сабиржанов, К. Хәлиуллина, Г. Җәббаров, М. Әхмәтшин, Г. Хөснетдинов, Х. Гобәйдуллин, замандашларыннан С. Хәбибуллин, Ф. Мөхәммәтшин, Х. Нигъмәтҗанов, Г. Сәйфетдинов, Л. Габдерахманов, К. Бәдретдинов, С. Мөхәммәдиев, М. Йөзлекәев, К. Вәлиев, Р. Әмирова-Мөхәммәтҗанова сурәтләнгән.

Бу ядкярнең оригиналы шул вакытта колхозның комсомол секретаре һәм вакыйганы тарихка калдыруны оештыручы Рәшидә Кариевада (1927–2011) сакланган һәм кызы Ләйсән ханым тарафыннан 2006 елның апрелендә «Казан» Милли-мәдәни үзәк каршындагы Милли мәдәният музеена тапшырылган[2].

Икенче сурәттә кулчатырга таянып тасвирланган яшь егет Яңа Иябаш авылыннан Хәбиберахман Әхмәрев (?–?). Ул Габдулла белән Яңа Кырлай мәдрәсәсендә бергә укыган. Соңыннан танылган дин эшлеклесе, мәгърифәтче, астроном Шәмсетдин Күлтәсинең (1856–1933) кияве була һәм халык арасында зур абруй казана. Гомере буе мулла вазыйфасын башкарган, хәтта, җәмгыятьтә шәхес культы, дәһрилек котырынган елларда да аңа кагылырга җөрьәт итмәгәннәр.

Өченче фотодагы К. Хәлиуллина — ире Әһлиулланың (1886–1937) Г. Тукай турындагы сөйләп калдырганнарын безгә җиткергән кеше.

С. Мөхәммәтшин уңае белән тарихи кызыклы бер фактны да әйтергә кирәк. Әстерхан шәһәрендә яшәгән һәм әдәбият галиме С. Исәнбаевка күп ярдәм күрсәткән кешеләрнең берсе Солтан Таһиров (?–?) 1961 елның 15 апрелендә язган хатында болай ди: «Хатыгызны һәм бүләгегезне алдым. Бик, бик зур рәхмәт. Зур хезмәт башкаргансыз, китап ошады... Китапта минем исне китәргән ике нәрсә бар: беренчесе, китап минем бабамның, дөресрәге әбиемнең энесе — Сафа Мөхәммәтшин истәлеге белән башлана...».

Бөек Ватан сугышыннан соң Г. Тукай турында истәлекләр җыйнау белән танылган язучы, драматург Кәрим Әмири (1893–1962), Татарстан дәүләт музее хезмәткәре Фатыйма Вагазова (1908–?), журналист Мөхәммәт Яхин (?–?), артист Габдерахман Камал II (1869–1948), укытучы Фатыйх Моратов (?–?) шөгыльләнәләр. Укытучы, журналист, «Әлислах» газетасының рәсми нашире һәм мөхәррире В. Бәхтияровның, беренче татар хатын-кыз артисткасы Сәхипҗәмал Гыйззәтуллина-Волжскаяның (1892–1974), Б. Әмированың (?–?).«Совет әдәбияты» журналында, музыка белгече Антон Эйхенвальдның (1875–1952) «Красная Башкирия»[3] газетасында, мәгариф хезмәткәре Кәшфи Мостафинның (1888–1954) «Әҙәби Башҡорто-

[1] Бу фотолар турында матбугатта беренче тапкыр безнең тарафтан игълан ителде: Исламов Р. Истәлек авторлары — фотоларда / Р. Исламов // Кызыл таң. — 2013. — 4 июль.

[2] Инв. № КП-14874.

[3] *«Красная Башкирия»* — башлангычы «Уфимский рабочий», «Вперёд», «Известия Уфимского губренского революционного комитета», «Власть труда» газеталарына барып тоташа. 1925 елның гыйнвар аеннан «Красная Башкирия», 1951 нең сентябреннән «Советская Башкирия», 2001 дән «Республика Башкортостан» исеме белән Уфада атнага 5 тапкыр рус телендә нәшер ителә торган иҗтимагый-сәяси газета.

стан»[1] журналында мәкаләләре бастырыла. Ул елларада шагыйрьнең Уральскида иң якын дусларыннан берсе булган Нәҗип Нигъмәтуллин (1889–?), мөгаллим К. Кадыйри, Фатыйма Аппакова (1892–1971), педагог Дәүләт Сафин (?–?), журналист Гариф Латыйпов (1886–1962), Барый (Габделбарый) Хәсәнов (1884–1949), Рокыя Ибраһимова (?–?), Галимҗан Вәлиәхмәтов (?–?), педагог К. Мостакаев, китапханә эшчесе Габдулла Вәлиев (?–?), М. Бәрхиев (?–?), нашир Ш. Әхмәров, матбугат эшчесе Галимҗан (Галим) Әмирхан (?–?), журналист, тәнкыйтьче, педагог, Шәриф Байчура (1892–1972) да истәлекләр язган, әмма алар кулъязмада калганнар.

Илленче елларда көндәлек матбугатта Г. Тукайның Уральскидагы дуслары Александр Гладышевның (1891–?) һәм Шәфигулла Курамшинның (?–?) гына мәкаләләре басылганы билгеле. М. Галинең истәлеге аның «Сайланма әсәрләре»ндә урнаштырыла. Әмма язылып та, үз вакытында дөнья күрми калганнардан бары тик Мохтар Сабитов (?–?) истәлеген әйтергә мөмкин.

Алтмышынчы елларда Г. Тукай турында истәлекләр җыйнау белән әдәбият белгече С. Исәнбаев һәм журналист С. Таһиров кына шөгыльләнәләр. Икенчесенең материаллары шагыйрьнең 1911 елда Әстерханга сәяхәте турында бердәнбер тулы чыганак булып тора. «Совет әдәбияты», «Казан утлары», «Азат хатын» журналларында, «Социалистик Татарстан»[2], «Кызыл таң»[3], «Совет Башҡортостаны»[4], «Татарстан яшьләре»[5] газеталарында укытучы, совет һәм сәүдә оешмаларында җаваплы хезмәткәр Г. Хикмәтуллинның, укытучы Таһир Мәхмүдовның (1888–1978), шагыйрь һәм тәрҗемәче Сәгыйть Сүнчәләйнең (1889–1941), мәгариф һәм мәдәният эшлеклесе Мөбарәкҗан Әмировның (1886–1968), Өчиле авылы кешесе Миңлекамал Әхмәдуллинаның (1898–1970), финанс оешмалары хезмәткәре Ибраһим Һилаловның (1895–1982), мәгариф эшлеклесе М. Бикбулатовның, журналист һәм педагог

[1] *«Әҙәби Башҡортостан»* — 1923 елдан «Яңы юл», 1927 дән «Сәсән», 1930 дан «Үктәбер», 1949 дан «Әҙәби Башҡортостан», 1961 дән «Ағиҙел» исеме белән Уфа шәһәрендә башкорт телендә нәшер ителә торган әдәби-нәфис һәм иҗади-сәяси журнал.

[2] *«Социалистик Татарстан»* — 1918–1920 елларда «Эш», 1920–1922 дә «Татарстан хәбәрләре», 1922–1924 тә «Татарстан», 1924–1951 дә «Кызыл Татарстан», 1951–1960 та «Совет Татарстаны», 1960–1992 дә «Социалистик Татарстан», 1992 нең февраленнән «Ватаным Татарстан» исеме белән Казанда татар телендә нәшер ителә торган атналык иҗтимагый-сәяси газета.

[3] *«Кызыл таң»* — 1918 елның мартыннан «Башкортстан», 1924 нең 2 августыннан «Яңа авыл», 1930 ның 1 гыйнварыннан 1941 нең 8 июленә кадәр «Коммуна», 1944 нең 12 мартыннан «Кызыл таң» исеме белән Уфада татар телендә нәшер ителә торган көндәлек иҗтимагый-сәяси газета.

[4] *«Совет Башҡортостаны»* — 1917 елның июненнән Оренбург шәһәрендә «Башҡорт иттифаҡы бюроһының мөхбире», июль аеннан «Башҡорт», 1918 дән «Башҡортостан хөкүмәтенең теле», 1919 дан «Башҡортостан хәбәрҙәре», 1921 нең февраленнән «Ҡыҙыл ҡурай», 1922 нең сентябреннән 1924 кә кадәр Уфада татар һәм башкорт телләрендә «Башкортостан», 1937 дән «Ҡыҙыл Башҡортостан», 1951 нең мартыннан «Совет Башҡортостаны», 1990 нан «Башҡортостан» исеме белән башкорт телендә нәшер ителә торган иҗади-сәяси газета.

[5] *«Татарстан яшьләре»* — 1920–1938 елларда «Кызыл яшьләр», 1938–1956 да «Яшь сталинчы», 1956 дан «Татарстан яшьләре» исеме белән Казанда татар телендә нәшер ителә торган республика яшьләр газетасы.

К. Сәгыйдовның, Касыйм Субаевның (?–?), Галимуллина Һаҗәрнең (1884–?), композитор, педагог Мансур Мозаффаровның (1902–1966), Гөлсем Хәнипованың (?–?), Ф. Рөстәмовның (?–?), Камал Фәхретдиновның (?–?), педагог, лексикограф Гаяз Ишмөхәммәтовның (1891–1971), җәмәгать эшлеклесе Зәйнәп Хәсәниянең (1887–1967), микробиолог, медицина фәннәре докторы, профессор З. Кәримованың, истәлекләре басылып чыга. Журналист, тәрҗемәче Заһид Нуркин (1888–1966), укытучы Заман (Хәйреззаман) Бикбаев (1892–1969), журналист һәм библиограф Исмәгыйль Рәми (1895–1969) истәлекләре дә шул вакытларда языла. Әмма, кызганыч ки, алар кулъязмада килеш калалар.

Җитмешенче елларда көндәлек матбугатта («Азат хатын»[1], «Совет мәктәбе»[2], «Казан утлары» журналлары) Г. Тукай турында Насретдин Хәсәновның (?–?), педагог Касыйм Богдановның (?–?), мөгаллимә, археограф Зәйнәп Максудованың (1897–1980) истәлекләре дөнья күрә.

Сиксәненче елларда да «Азат хатын» һәм «Казан утлары» журналлары битләрендә язучы һәм тәрҗемәче Г. Мөхәммәдованың, табибә Н. Әхмәрованың гына истәлекләре басыла.

Г. Тукай турында истәлекләр аерым җыентык рәвешендә беренче тапкыр С. Исәнбаев тарафыннан төзелеп, «Тукай турында замандашлары: Истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы»[3] исеме белән 1960 елда нәшер ителә. Анда шагыйрьнең «туганнары, бергә эшләгән каләмдәшләре, авылдашлары, дус-ишләре, белеш һәм танышлары тарафыннан язылган истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр»[4] тупланган. Материаллар, нигездә, Октябрь түнтәрелешенә кадәрге татар вакытлы матбугатыннан һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (хәзер Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге) тупланмасыннан алынганнар. Алар, төзүче үзе аңлатканча, язылу датасына карап түгел, шагыйрьнең биографик хронологиясе буенча урнаштырылган. Шуңа күрә җыентыкның композицион корылышы «Тукай Кырлайда», «Тукай Уральскида», «Тукай Казанда», «Тукай сәяхәт иткәндә», «Тукайның үлеме», «Тукай турында шигырьләр», «Тукай турында тәнкыйть» дигән тематик бүлекләрдән гыйбарәт.

Җыентыкта барлыгы 52 берәмлек истәлек һәм мәкалә, янә шагыйрь турында 3 бәет һәм Шәехзадә Бабичның (1895–1919), Мирхәйдәр Фәйзинең (1891–1928), М. Гафуриның, Габдулла Харисның (1893–1931), Габдулла Сөнгатинең (1894–1917 елдан соң), С. Сүнчәләйнең 6 шигыре урын алган.

---

[1] *«Азат хатын»* — 1926 елның августыннан (1941–1957 дә басылмый) нәшер ителә башлаган, 1991 дән «Сөембикә» исеме белән Казанда татар телендә чыга торган хатын-кызлар өчен айлык иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис журнал.

[2] *«Совет мәктәбе»* — «Мәгариф» журналының 1938–1941, 1949–1990 еллардагы атамасы. 1990 нан янә «Мәгариф».

[3] Тукай турында замандашлары: истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы / Төз. һәм текст. хәзер. С. Исәнбай; Г. Халит ред. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. — 296 б.

[4] Күрс. хезм. — Б. 4.

Әлеге китапка, кызганыч ки, галим зур көч куеп туплаган барлык истәлекләр дә урын алмаган. Ягъни, 20 табакка исәпләнелгән күләм нәшриятта 10 табакка калдырыла.

Җыентык басылып чыкканнан соң матбугатта аңа карата әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче И. Нуруллинның бәяләмәсе басылып чыга[1]. Аерым алганда, ул болай яза: «Тукайның үлемсез шигырьләренә гашыйк укучы да, шагыйрьнең иҗаты турында сөйләп имтихан бирәчәк студент та, яшь буынны тәрбияләүче укытучы да, ниһаять, шагыйрьнең мирасын җентекләүче галим дә китаптан азык табачаклар.... Шунысы күңелле: җыентыкка шагыйрьнең Астраханьда булуы турында яңа истәлек кертелгән, һәм нәтиҗәдә Тукай биографиясендәге «ак тап» бетә яза»[2].

Бәяләмәдә бу басманың уңышлы яклары белән бергә аның аерым җитешсезлекләре дә күрсәтелгән. Хосусан, алар — искәрмә-аңлатуларга ярлылык, кайбер фактларның дөреслеккә туры килмәүләре, текстларны «эшкәртүләр» ягъни кыскартулар һәм башкалар. Мәсәлән, галим билгеләгәнчә, «Шагыйрьнең иҗатындагы каршылыкларны шыпырт кына әйтү яисә бөтенләй дәшми үтү. Аны һәр яктан килгән, коеп куйган бер шәхес итеп күрсәтергә тырышу нык кына күзгә бәрелә. Әнә шуның тәэсирендә булса кирәк, төзүчеләр, редактор һәм нәшрият эшчеләре Тукайны «күтәрү», «яхшыртыу» өчен истәлекләрнең һәркайсыннан диярлек юл-юл, абзац-абзац сызып ташлаганнар. Ул гына да түгел, текстны үзгәртүгә кадәр барып җиткәннәр»[3].

1976 елда И. Нуруллин һәм Р. Якупов төзегән «Тукай турында хатирәләр» дигән җыентык дөнья күрә[4]. Аны әзерләгәндә, кереш сүздә әйтелгәнчә, ике принципка нигезләнеп эш ителгән: «Беренчесе: китап Тукайның тормыш юлын теге яки бу дәрәҗәдә тулы итеп күз алдына бастырсын, биографиясенең барлык чорларын да тиешле пропорциядә чагылдырсын»[5]. «Икенчесе: истәлек ышанычлы булсын, фактлардан бик үк читкә китмәсен, тормыш детальләренә бай булсын, шагыйрьнең җанлы сурәтен күз алдына бастыра алсын»[6]. Истәлекләрнең 1917 елга кадәргеләренә өстенлек бирелсә дә, шагыйрьнең тууына илле, алтмыш, җитмеш, сиксән ел тулу уңаеннан язылганнары шулай ук игътибар үзәгенә алынган. Текстларда куелган сынык җәяләр эченә алынган өч нокта мәсьәләсенә килгәндә исә, ул «сызылган урыннарның күпчелеге жанр сафлыгын саклау һәм кабатлаулардан котылу өчен эшләнде»[7] дип аңлатыла.

Җыентыкта тупланган 33 истәлекнең 21 е элекке басмада дөнья күргәннәр. Әмма аларның кайберләре беренчел чыганактан алынган. Яңаларыннан 3 се кулъязма-

---

[1] Нуруллин И. Тукай турында замандашлары / И. Нуруллин // Совет әдәбияты. — 1961. — № 12. — Б. 138–141.

[2] Нуруллин И. Тукай турында замандашлары... — Б. 138–141.

[3] Күрс. хезм. — Б. 139–140.

[4] Тукай турында хатирәләр / Төз. һәм текст. аңл. бирүчеләр: И. Нуруллин, Р. Якупов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — 191 б.

[5] Нуруллин И. Хатирәләр турында берничә сүз / И. Нуруллин, Р. Якупов // Тукай турында хатирәләр... — Б. 3.

[6] Күрс. хезм. — Б. 4

[7] Нуруллин И. Хатирәләр турында берничә сүз / И. Нуруллин, Р. Якупов // Тукай турында хатирәләр... — Б. 3.

дан, 5 се төрле көндәлек матбугаттан, 2 се сайланма әсәрләрдән алынган. Я. Мораданиның «Тукаев Уральскида» дигән китабының тексты да кыскартып урнаштырылган.

Шул ук авторлар 1986 елда «Тукай турында истәлекләр» исемле икенче җыентык та әзерләп нәшер итә[1]. Күләмне арттыру һәм эчтәлекне яхшырту юнәлешендә башкарылган «бусына элеккеге ике китапта урын алган истәлекләрнең барысы да дип әйтерлек кереп бетү белән бергә, вакытлы матбугат һәм архивтан алынып, дистәдән артык материал»[2] өстәлеп, ул барлыгы 51 берәмлекне эченә ала. Аларның яңа урын алганнары: төрле матбугаттан — 10, сайланма әсәрләрдән — 2, җыентыктан — 1. Кулъязмада сакланган һәм киң катлау укучыга һаман да билгесез булып калган язмалар, нишләптер, анда кертелмәгән. Алар бит шактый гына, югыйсә.

Шунысын да билгеләп үтү урынлы: әлеге соңгы ике җыентыкта искәрмә-аңлатмалар шактый баетылган.

Бу җыентыклар гәрчә Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнүдә мөһим роль уйнасалар да, кызганыч ки, алар шул чор хаким идеология кысалары нигезендә төзелгәннәр. Шул сәбәпле аларга, беренчедән, үз вакытында көндәлек матбугатта дөнья күргән бик күп истәлекләр, мәкаләләр һәм башка төрле чыганаклар кертелмәгәннәр. Мәсәлән, «халык дошманы», «эмигрант», «динче» кебек ярлыклар тагылган М. Бигиев, Г. Исхакый, Г. Баттал, М.-Ф. Туктаров, М.-С. Баязитов, хәтта, иҗтимагый-сәяси афәтләрдән котылып калган Ш. Мөхәммәдъяров һәм башка шәхесләрнең язмалары шундыйлардан. Ул җыентыкларда инде акланганнардан, мәсәлән, Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗатын беренчеләрдән булып фәнни нигездә өйрәнгән Ж. Вәлидинең дә бары бер генә истәлеге урын алган, янә дүрт-биш мәкаләсе, нигәдер, игътибардан «читтә» калган.

Шагыйрьнең җеназа мәрасимен яктырткан язмаларның да бер-икесе генә хәзерге заман укучысына мәгълүм. Ә бит алар берничә. Дөрес, табигый ки, аларда кабатланулар да бар, шул ук вакытта бер-берсен тулыландыра торган фактлар да юк түгел.

Икенчедән, югарыда телгә алынган җыентыкларга кергән материалларның байтагы шактый кыскартылган. Кайвакытта андый урыннарны күрсәтү яки билгеләп үтү кирәк дип табылмаган. Алай гына да түгел, сүзләр үзгәртелү, текстлар редакцияләнү күренешләре дә күзәтелә.

Ике том күләмендәге «Тукай — ядкярләрдә»[3] дигән хезмәт бу юнәлештәге бай тәҗрибәгә нигезләнеп башкарылган хезмәт. Анда Г. Тукай турында туганнары, замандашлары, дуслары һәм танышлары тарафыннан язылып һаман киң гавам укучыга билгесез калган, төрле вакытларда көндәлек матбугатта басылып чыккан истәлекләрне, мәкаләләрне мөмкин кадәр барысын да һәм тулысынча туплау максат итеп куелган.

---

[1] Тукай турында истәлекләр / Төз. һәм иск. әзер.: И. Нуруллин, Р. Якупов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 256 б.

[2] Нуруллин И. Кыйммәтле хәзинә / И. Нурулин // Тукай турында истәлекләр... — Б. 6.

[3] Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — 968 б.; — 2 т.: Мәкаләләр, шигырьләр, төрлеләр. — 720 б.

Композицион корылышы ягыннан җыентык Г. Тукайның тормыш хроникасына яраклы рәвештә «Тукай Кырлайда», «Тукай Уральскида», «Тукай Казанда», «Тукай сәяхәт иткәндә», «Тукайның вафаты», «Тукай вафаты уңаеннан тәгъзияләр, телеграммалар», «Тукай турында тәнкыйть», «Тукай кичәләре», «Тукай турында шигырьләр» һәм «Төрлеләр» дигән бүлекләрдән гыйбарәт.

Элгәрге җыентыклардан аермалы буларак, Г. Тукай вафатыннан соң көндәлек матбугатта бастырылган тәгъзияләр, телеграммалар, каберенә таш кую мәсьәләләре; шагыйрьне искә алу кичәләре, аның исемендәге стипендияләр, рәсемнәре һәм башкалар турында биредә китерелгән мәгълүмат — «Революциягә кадәрге татар әдәбиятының үзәк фигурасы булган Тукайны»[1] төшенү юлында моңа кадәр белгәннәребезне тагын да киңәйтергә ярдәм итә.

Профессор И. Нуруллин сүзләре белән әйткәндә, «Нәтиҗәгә карап факт җыюны ташларга вакыт. Фактлар үзләре нәтиҗәгә китерсен. Фән яхшы мәгънәсендә объективлыкка, дөреслеккә корылырга тиеш»[2].

Дөресен әйтергә кирәк: күп кенә истәлекләрдә, мәкаләләрдә кайбер кабатланулар күзәтелә. Бу гайре табигый күренеш түгел һәм ул һәр төбәкнең үз матбугаты, һәр матбугатның үз аудиториясе белән аңлатыла. Әлеге уңайдан тагын шунысын да әйтергә кирәк: алар аерым моментлар, детальләр белән бер-берсен тулыландыралар. Мәсәлән, «Казанда 4 нче апрель» дигән мәкаләдә язылганча, Г. Тукайның җәсәден Клячкин шифаханәсеннән алып чыгар алдыннан «Берничә хәзрәт вә үзенә якын торган аркадашлары тарафыннан тәсбих тәһлил укыла»[3]. Ә «Тукаевны дәфен» дигән мәкаләдә исә бу тагын да ачыклана һәм конкретлаша: «Сәгать бер туларга чирек калганда Зариф, Кәшшаф, Касыйм вә Борһан[4] хәзрәтләр илә бергә җыелган халыкның бәгъзеләре тәһлил укыдылар...»[5].

Мондый төр хезмәтләр Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеген өйрәнү юнәлешендә билгеле роль уйнаса да, мәсьәләнең актуальлеген һәм катлаулылыгын, киләчәктә башкарыласы тагын да күләмле эшләр торганын онытмаска кирәк. Шуңа күрә, бу хакта сүз йөртеп, И. Нуруллин узган гасыр урталарында ук болай дип язган иде: «Мемуар әдәбиятны туплап чыгарудагы беренче тәжрибә безне түбәндәге нәтиҗәгә китерә: Бүтән классикларны әйтмибез дә инде, хәтта Г. Тукайның тормыш юлы, аның турындагы мемуар әдәбият та җитәрлек өйрәнелмәгән икән. Төп сәбәп — бу эш белән шөгыльләнә торган бер гыйльми үзәкнең булмавы»[6]. Мондый фикерне соңра Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев (1930–1995) тә куәтләп чыга: «Тукайны өйрәнү буенча бердәм — Тукаеведение — юклыгы нык сиздерә. Тукай иҗаты белән генә җентекләп шөгыльләнүче гыйльми үзәк булса, күп мәсьәләләр уртак-күмәк көч белән хәл кылыныр иде. Мәсәлән, Пушкин йорты

[1] Нуруллин И. Шагыйрьне өйрәнү юлында... — Б. 124

[2] Нуруллин И. Шагыйрьне өйрәнү юлында / И. Нуруллин // Казан утлары. — 1966. — № 3. — Б. 127.

[3] Казанда 4 нче апрель // Мәктәп. — 1913. — № 4. — Б. 110.

[4] *Борһан* — Мөхәммәтборһанетдин Шиһабетдин улы Мәржани (1856–1916), Казанның беренче мәхәлләсендәге Юнысов мәчете имам-хатыйбы.

[5] Тукаевны дәфен // Йолдыз. — 1913. — 7 апр.

[6] Нуруллин И. Тукай турында замандашлары... — Б. 140–141.

төсле үзәк...»[1]. Соңгы елларда бу мәсьәләнең актуальлеге хакында Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров болай язган иде: «Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, татар халкына шушы максатларны үзәккә алып эшләүче махсус фәнни структура кирәк, иҗат дөньясын ачкан саен зурая баручы шагыйрәбез мондый кайгыртучанлыкка бик лаек. Әгәр күпкә алга карап гамәл кылуны гәүдәләндергән шундый заманча үзәк төзелә калса, ул әдәбият һәм сәнгатебезнең башка мәшһүрләрен дә әтрафлы өйрәнергә җирлек булыр иде. Ә боларны үтәмәү — гафу ителмәслек хәл»[2]. Күренгәнчә, моннан ярты гасырдан артык элек күтәрелгән бу мөһим проблема, ни кызганыч, һаман үзенең уңай хәл ителүен көтә.

IX

Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗат эшчәнлеген өйрәнүдә мөһим юнәлешләрнең берсе — шагыйрьнең фотографияләре. Чынлыкта шагыйрьнең ничә фоторәсеме булган соң? Аларның кайсылары хәзерге вакытта мәгълүм, кайсылары һаман билгесез булып кала? Мәсьәләне хронологик тәртиптә карау мантыйкка ярашлы булыр.

Г. Тукай Уральскида яшәгән вакытта ук берничә тапкыр фотога төшкән икән. Татарстан Милли музееның Тукай мемориаль тупланмасында 1905 елда Җаекта алдырылган шәкертләрнең күмәк фотосының төп нөсхәсе бар[3]. Аны шагыйрьнең мәдрәсә сабакташы, соңыннан РСФСРның атказанган табибы Нигъмәтулла Вәлиев бүләк иткән. Ул әйткәнчә, беренче рәттә уңнан икенчесе — Тукай. Ләкин ул чыганаклар белән расланмаган, истәлекләрдә дә бу хакта мәгълүмат китерелми.

Әдәбият галиме С. Исәнбаев төзеп нәшер иткән шагыйрь турындагы фотоальбомда Г. Тукайның Г. Кариев һәм К. Мотыйгый белән төшкән аерым рәсемнәре бар[4].

Тарихчы Рәфыйк Нәфыйков (1928–2001) үзенең бер мәкаләсендә фотоның беренчесендә Тукай түгел, ә Габдулла Гаделшин (?–?) сурәтләнгән дип яза.

Шул ук чыганакта Г. Тукай типографиядә эшләгән вакытта кулына «Мулла Насретдин»[5] журналы тотып төшкән фотосы да урын алган[6].

Истәлекләрдә әйтелеп, хәзерге вакытка билгесез булып калганнары да бар. Мәсәлән, хәзерге Оренбург өлкәсе, Бурannый районы, Линевка авылында татар теле укытучысы Зәкәрия Әхмәрев (?–?) 1953 елның 12 мартында язучы Ә. Фәйзигә юллаган хатында булачак шагыйрьнең җәй көне Самышев Зәйнулла (?–?) исемле сабакташы белән кунакка кайткач, бергәләп фотога төшүләре хакында яза.

---

[1] Шагыйрь гомере эңгеләре [Мөхәммәт Мәһдиев һәм Зөфәр Бәширов белән әңгәмә] // Соц. Татарстан. — 1986. — 15 окт.

[2] Мансуров З. Дәүләткә торырлык өтер: Тукайның күптомлыкларын чыгаруда кайчан камиллеккә ирешербез? / З. Мансуров // Мәд. җомга. — 2011. — 25 нояб.

[3] Татарстан Республикасы Милли музее (алга таба ТР ММ): № КП-19698–101.

[4] Габдулла Тукай. Фотоальбом / Төз. С. Исәнбаев; махсус ред. Г. Халит. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. — Б. 18, 19.

[5] *«Мулла Насретдин»* — 1906 елдан 1912 нең мартына кадәр Тбилиси шәһәрендә әзәрбәйҗан телендә нәшер ителгән атналык рәсемле сатирик журнал. 1913 нең гыйнварыннан тагын чыга башлый һәм 1914 нең октябрендә ябыла. 1917 дә дөнья күреп ала. 1921 дә берникадәр Тәбриз шәһәрендә (Иран) чыга. 1922–1931 дә Баку шәһәрендә басыла.

[6] Габдулла Тукай. Фотоальбом... — Б. 20.

Тарихчы Р. Нәфыйков хезмәтләреннән күренгәнчә, Г. Тукай җырчы Рәхилә Даутовага (?–?) «Рәхилә туташка» дип язып, бер фотосурәтен бүләк иткән. Ул 1984 елда Уральскидан киткәндә бу ядкярне шәһәрдәге А. Пушкин музеена тапшырган[1].

Галим 1997 елда бер мәкаләсендә Г. Тукай белән аралашкан кешеләрне яхшы белгән Ф. Бәрхиевнең (?–?) Казан университетында укучы оныгы Р. Бәрхиевтә (Алимовта) шагыйрьнең ниндидер кулъязмасы белән фотосурәте сакланганлыгын яза[2].

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә Г. Тукай Уральскида бер төркем дуслары белән 1906 елда алдырылган фотоның оригинал ике төп нөсхәсе саклана (фотограф В. П. Онуфриев)[3]. Аларның берсе әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллинның (1903–1985) хосусый архивы белән 1978 елның 17 ноябрендә кергән. Аның икенче ягында гади карандаш белән гарәп хәрефләрендә шулай язылган: «Бу портретка төштек 1906 елда июль числосында. Уң якта таяк тоткан Сиражетдинев — «Казан» миһманханәсендә буфетчик, Мортаза Гобәйдуллинның ресторане. Икенче, аяк өстендә басып торган, Рәхмәтулла Хәйруллин — Мортаза Гобәйдуллин магазинында приказчик булып торган. Өченче, күзлекле, утырган, Габдулла Тукаев — «Уклар» матбагасында хәреф җыючы, шулай ук «Уклар» журналында шигырьләр язучы. Дүртенче, утырган, Курушкин Григорий — Гобәйдуллин магазинында приказчик. Бишенче, Гобәев Габделгани — Гобәйдуллин магазинында кассир булып торган кеше.

Рәхмәтулла Хәйруллин. 1906 г. 13/VII. Казанда, декабрь ае алдыннан».

Икенче нөсхәнең икенче ягына шәмәхә кара белән кирилл хәрефләрендә татар телендә шундый мәгълүмат теркәлгән:

«1. Нәҗип Зариф улы Нигъмәтуллин («Казан» гостиницасының буфетчысы). 2. Курушкин (Мортаза Гобәйдуллинның бухгалтеры). 3. Хәйруллин Рәхмәтулла (М. Гобәйдуллинның приказчигы). 4. Г. Тукай. 5. Сиражи шәкерт».

Аннан соң гади карандаш белән гарәп хәрефләрендә: «Югары Бәрәскә. Зариф Нәҗип» дип язылган. Астарак янә шәмәхә кара белән кирилл хәрефләрендә шундый сүзләр бар: «Уральскида 1906 елгы рәсеме».

Шунысы кызыклы, Р. Хәйруллин истәлегендә әлеге фотографиянең тарихы китерелә. Аерым алганда, ул болай яза: «1906 нчы елның 13 нче июнендә Тукай, мин, А. Гобәев (кибеттә кассир). Г. Т. Курушкин (приказчик), А. Сиражиев (буфетчик) рәсемгә төштек. Рәсемгә төшкәндә Тукай барыбызга да төрле-төрле киемнәрдә төшәргә кушты, без шулай иттек тә; ә үзе күзлек киде (ул болай да күзлек киядер иде), чәчләрен туздырды — шулай төште»[4].

---

[1] Нәфыйгов Р. Ерагайган саен якынрак / Р. Нәфыйгов // Татарстан. — 1995. — № 11–12. — Б. 33.

[2] Нәфиков Р. Шагыйрьне өйрәнү юлында / Р. Нәфиков // Казан утлары. — 1997. — № 6. — Б. 165.

[3] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3 тасв., 18 сак. берәм.

[4] Рәхмәтулла Хәйрулла улы Хәйруллинның Габдулла Тукай турында истәлекләре... — Б. 133.

Язуларда күзәтелгән аерымлыклар кайбер сораулар барлыкка китерә. Әйтик, Сиражетдинев кем ул — шәкертме, әллә буфетчымы? Фотографиядә сурәтләнгән бишенче кеше Габделгани Гобәевме яки Нәҗип Нигъмәтуллинмы?

Шулай ук Үзәктә Г. Тукайның Казанда 1907 елда «Әл-ислах» газетасы редакциясе хезмәткәрләре В. Бәхтияров, К. Бәкер, Ф. Әмирхан, Ибраһим Әмирхан (Ф. Әмирханның энесе) (1889–1938) белән берлектә алдырылган сурәтнең ике төп нөсхәсе (фотограф Е. И. Иванов) саклана[1]. Беренчесенең артына гарәп хәрефләрендә болай язылган: «Фатыйх апага. Вафа. 1907 сәнә». «Апага» дип адреслауда үзара дусларча ниндидер шаяру күренә булса кирәк.

Икенчесенең арткы ягында исә шулай ук гарәп графикасында мондый мәгълүмат теркәлгән: «Вафа Бәхтияр, Кәбир Бәкер, Фатих Әмирхан, Ибраһим Әмирхан, Габдулла Тукай. «Әл-ислах»ның һәйәте тәхририясе. 1907. 1 — май. Әхмәдмөнир бәк Ирен вөҗүде шәрәфенә һәдия гажизәнәм. К. Бәкер».

Фотоның өченче нөсхәсе Татарстан Республикасының Милли музей фондында бар (А. Р. Мөлеков дигән кешедән алынган) һәм аның арткы ягында шулай язылган: «1 — Г. Тукай. 2 — Ибраһим Әмирханов. 3 — Фатих Әмирханов. 4 — Кәбир Бәкер. 5 — Вафа Бәхтияров («Аң» гәзите редакторы)»[2].

Күренгәнчә, биредә бераз гына ялгышлык киткән. Беренчедән, «Аң» газета түгел, ә журнал. Икенчедән, В. Бәхтияров «Әл-ислах» газетасы мөхәррире.

Дүртенче төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана. Ул В. Бәхтияровның хосусый архивы белән кергән. Фотосурәтнең арткы ягында мондый язу бар: «Вафа Бәхтияров. 1908 сәнә, апрель 17 ндә алдырылган».

1909 елда «Шигырьләр китапханәсеннән» сериясендә «Үрнәк» матбагасында 10 нчы дәфтәр булып «Әдәбият» исемле шигырьләр мәҗмугасе басылып чыга. Әлеге җыентыкның бер нөсхәсен Я. Байбуринга язып бүләк итә. «Ибдәшем Ягкуб Байбуринга ядкяр. 2 нче нуябер. 1909 сәнә. Г. Тукаев»[3].

Моның нигезе бар, әлбәттә. Тәрҗемәче, журналист Я. Байбурин Казанда яшәгәндә Г. Тукай, Ф. Әмирхан белән дус була. Ф. Әмирхан аның турында болай яза: «...мәрхүм Тукайның авыруы вакытында Якубның аңар иткән ярдәм вә хезмәтен бер Алла үзе генә беләдер».

Үзәктә Г. Тукайга нисбәт ителгән тагын зур булмаган форматлы бер дәфтәр бар. Аның тышлыгында болай язылган:

«Тетрадъ
для Списывания
ученика 1го класса
А. М. Тукаева.
Книжный складъ
Уфимскаго Губернскаго Земства».

Кулдан язылган «Списывания», «...ка 1 го», «А. М. Тукаева» дигән сүзләр шагыйрьнең автографы булса да, дәфтәр эчендәге шигырь, җыр текстлары аның кулы

[1] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3. асв., 24 сак. берәм.

[2] ТР ММ: № 119835.

[3] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 1 тасв., 2 сак. берәм.

белән язылганлыгы шулай ук шик уята. Шуңа күрә аларны махсус тикшерү үткәреп, ачыкларга кирәк. Чөнки Г. Тукай әсәрләрен күчереп язу гайре табигый күренеш түгел. Мәсәлән, төрле чыганаклардан күчерелгән шигырьләренең, мәкаләләренең, хикәяләренең, әкиятләренең 125 берәмлеге тупланган бер төпләм бар. Андый күчермәләр археографик экспедицияләр вакытында да табылып тора.

Г. Тукайга бәйле нәшер ителгән күп кенә чыганакларда, альбомнарда бер фотокарточканы күрергә мөмкин. Аерым алганда, анда бүрәнәләрдән ике катлы итеп төзелгән, беренче һәм икенче каттагы өчәр тәрәзә арасынада рус телендә «Редакция газеты «Эль-Ислах» дип язылган һәм шунда ук газетаның гарәп хәрефләрендә татарча исеме куелган элмә такта фонында өч кеше басып тора. Моның аңлатмасы бары тик «Әл-ислах» газетасы урнашкан бина. 1908» яки «1908–1909 нчы елларда Казанда «Әл-ислах» газетасы редакциясе урнашкан йорт (хәзерге Тукай урамы, йорт 63)» дип кенә чикләнелә. Гәрчә бу мәгълүмат дөрес булса да, әлеге фотографиянең тарихы нидән гыйбарәт, анда кемнәр сурәтләнгән соң?

Демократик яшьләр һәм алдынгы шәкертләрнең басма органы буларак, «Әл-ислах» газетасы рәсми рәвештә 1907 елның 3 октябрендә нәшер ителә башлый. Аның рәсми мөхәррире В. Бәхтиярев булса да, төп эшне Ф. Әмирхан алып бара. Анда шулай ук К. Бәкер, И. Әмирхан, Г. Тукай, Зәкәрия Бәхтиярев (?–?), Таһир Мәхмүдев (1889–1978) һәм башкалар эшли.

Газетаның редакциясе башта атаклы «Болгар» кунакханәсе номерларында урнашкан була. 1908 елның 2 мартында идарә Екатерининская (хәзерге Тукай урамындагы уртакул сәүдәгәр Габделшәкүр Апаков (1860–1923) өенә күчә (кызганыч ки, ул өй 1990 елда сүттерелеп, аның урынына 2004 елда башка корылма төзетелә).

Бу хакта Фатыйма Апакованың (1892–1971) (аның әнисе Мәрьямбану (1876–1919) Ф. Әмирхан әтисе Мөхәммәтзариф хәзрәтнең бертуган сеңелесе) Г. Тукай турындагы истәлегендә шундый мәгълүмат китерелә: «Шушы елның (1908 — *Р. И.*) көз якыннарында булса кирәк, безнең йортка, ягъни Тукай урамына (автор урам исемен истәлекне язган вакыттагыча белдерә — *Р. И.*) «Ислах» идарәсе күчте. Минем атам аларга урамга караган зур залын бирде...»[1]. Аңлашылганча, истәлек авторы ел фасылын күрсәтүдә бераз ялгыша булса кирәк.

Ә хәзер инде игътибарны фотокарточкага юнәлтеп, Т. Мәхмүдевнең янә бер истәлегенә мөрәҗәгать итик. Ул, хосусан, болай яза: «Без: Тукай, мин, басмаханәдә хәреф җыючы 14–15 яшьләрендәге Габдулла өчәүләп әңгәмәләшеп утырганда рәсем аппаратын асып Ростовтан реальный мәктәбендә укучы Гани Абыз идарәгә килде. Ул өчәвебезне урамга чыгарып «Әл-ислах» вывескасы урнашкан тәрәзәләре турында рәсемгә төшереп алды. Тукай безне түбән һәм малайлардан санамыйча иркенләп безнең уртабызда басып торды.

[1] Апакова Ф. Бөек шагыйрь Габдулла Тукаев турында исемдә калганнар / Ф. Апакова // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 438.

Бу 1908 нче ел җәй уртасы, Тукай урамы, № 63 өй (урам исеме шулай ук истәлек язылган вакыттагыча — *Р. И.*)»[1].

Димәк, фотодагы кешеләр уңнан сулга: Т. Мәхмүдев, Г. Тукай, Габдулла. Өченче кеше Габдулла Гыймадетдинов (?–?) булырга тиеш. Чөнки ул 1908 елның май ахырларында «Әл-ислах» газетасы хезмәткәрләреннән бер төркем Кабан күле башында урманда ял иткән вакытта алдырылган икенче бер фотокарточкада да сурәтләнгән.

Г. Тукайның кепка киеп йөрүенә килгәндә исә (фотода ул шулай сурәтләнгән) бу хакта күп кенә башка истәлекләрдә дә телгә алына, фотокарточкаларда да күзәтелә.

Бу тарихи ядкярне сурәткә алдыручы кеше Гани Абызов (1890–1940 елдан соң). Ул 1915 елда татар студентларының Санкт-Петербургта оешкан «Татар учагы» җәмгыяте әгъзасы була, совет хакимияте чорында ТАССР дәүләт планлаштыру оешмасында экономист, «Васильево» шифаханәсендә хисапчы вазифаларын башкара.

Г. Тукай, С. Рәмиев, Ф. Агиев 1908 елда бергә төшкән фото булган. Ләкин ул 1966 елда дөнья күргән альбом буенча гына билгеле[2].

Г. Тукайның Казанда тарафыннан 1909 елның җәендә төшерелгән фоторәсеменең (фотограф С. И. Иванов; логтип һәм экслибрис буенча) шулай ук ике төп нөсхәсе Үзәктә саклана[3]. Шагыйрь аның берсен үзенең иң якын дусларыннан берсе К. Мостакаевка бүләк иткәндә икенче ягына шулай яза: «Мөхтәрәм Габделкаюм әфәндегә ядкяр. 1909 сәнә, 12 июль. Габдулла Тукаев». Гәрчә язулар икенче кара белән сызганган булсалар да, аларны укып була. Бу нөсхәне К. Мостакаев Институтка үткән гасырның 60 нчы елларында тапшырган.

Икенче нөсхә Үзәккә шулай ук М. Гайнуллинның хосусый архивы белән кергән. Аның икенче ягына Г. Тукайның үз кулы белән болай язылган: «Иптәшем Вәли Апанаевка ядкяр. Г. Тукаев. 17 нче июль, 1909 сәнә». Галимгә әлеге нөсхәне В. Апанаевның (1889–1922)[4] бертуган апасыннан алып Зәйнәп Апанаева тапшырган. Әлеге фотодан рәсем-открытка ясатылган. Үзәктә саклана торган бер нөсхәсенең алгы ягында гарәп хәрефләрендә «Габдулла Тукай» һәм кириллицада «Адулла Тукаев. Собственность Изд. Тов-ва Васита» дип язылган.

Татарстан Милли музее фондында фотоның өченче төп нөсхәсе дә бар[5]. Аның икенче ягында шулай язылган: «2 гыйнвар, 1909. Гыйффәтле Зәйтүнә Мәүлүдова җәнабе галиләренә һадияне һадия. С. Рахманколый». Ләкин З. Мәүлүдова (1893–1957) үзенең истәлекләрендә шундый ук фотоны Г. Кариев шулай язып биргәнлеген белдерә.

---

[1] Мәхмүд Т. Габдулла Тукай турында истәлек / Т. Мәхмүд // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 551.

[2] Габдулла Тукай. Фотоальбом... — Б. 32.

[3] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3. тасв., 27 сак. берәм.

[4] Гобәйдуллин Х. Музыкант Вәли Апанаев / / Х. Гобәйдуллин // Татарстан яшьләре. — 1990. — 6 янв.

[5] ТР ММ: № КМГ-117.

С. Исәнбаев төзегән фотоальбомда Г. Тукай белән Г. Коләхмәтовның 1910 елгы фотосы бирелгән[1]. Чынлыкта исә алар өчәү булып, өченчесе Газиз Гобәйдуллин (1887–1937). Әмма бу сурәт ныклап тикшеренүне таләп итә.

Г. Тукай 1911 елда Әстерханга баргач ике мәртәбә фотога төшкәнлеге мәгълүм. Аның берсендә шагыйрь ул вакытта «Идел» газетасы редакциясендә эшләгән С. Рәмиев һәм мөгаллим Ш. Гайфи (Гайфетдинев) фотоательедагы бутафор көймәдә сурәтләнгәннәр. И. М. Бочкарев төшергән бу фотоның төп нөсхәсе хәзерге вакытта Үзәктә саклана[2].

Ш. Гайфи бу күмәк фотодан Г. Тукайның гына сурәтен алып, почта открыткасы рәвешендә күбәйттерә. Бу хакта «Кояш» газетасының 1914 елгы 28 нче март санында хәбәр дә бастырыла. Рәсемнең астында шагыйрьнең «Кыйтга» дип исемләнгән шигыреннән шундый юллары китерелгән:

«Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч, шул булды эш,
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым». Г. Тукаев.

Бу рәсем-открытканың бер нөсхәсе хәзерге вакытта Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда саклана[3]. Аның арткы ягында тапшыручының язмасы бар: «ТАССРның Дәүләт музеена хезмәт ветераны, 1910 елда туган Емалиева-Аветисова Хәдичә Гомәревнадан бүләк. Гомель шәһәре, 4.12.1986».

Бу рәсем-открытканы 1938 елда Союзфотоның Татарстан бүлеге янә почта открыткасы итеп бастыра. Анда шигъри юллар урынына «Abdulla Tuqaj (1886–1913) Абдулла Тукай» дип язылган. Аның берәр нөсхәсе Язма мирас үзәгендә, әдәбият галиме һәм археограф Раиф Мәрданов 1988 елда Кукмарадан табып алганы, Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә[4], безнең хосусый архивыбызда саклана.

Казанда 1911 елда, шул ук фотодан булса кирәк, болытлар арасыннан ялтырап чыккан кояш фонында шагыйрьнең башы гына сурәтләнгән тагын бер рәсем-открытка эшләтелгән. Аның алгы ягында гарәп хәрефләре белән «Өзелгән өмид» шигыреннән шундый юллары язылган:

«Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шад яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.
Г. Тукаев».

Бу рәсем-открытканың И. С. Галиуллинадан (?–?) сатып алынган бер нөсхәсе Г. Тукайның әдәби музее фондында саклана[5].

Билгеле булганча, Тукай Әстерханнан китәр алдыннан аның шәрәфенә Зимний театрда шәһәр профессиональ театрына нигез салучыларның берсе Зәйни (Зәйнелгабидин) Солтанов (Сөләйманов) (1882–1952) җитәкчелегендә зур кичә үткәрелә. Аның инициативасы белән анда катнашучылар Г. Тукай белән бергә фотога төшә-

[1] Габдулла Тукай. Фотоальбом / Төз. С. Исәнбаев; махсус ред. Г. Халит. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. — Б. 32.

[2] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3 тасв., 35 сак. берәм.

[3] ТР ММ: № КП-20902.

[4] Татарстан Республикасы Милли китапханәсе Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге (ТР МК КһСКБ): ФР 2.

[5] ТР ММ: № КП-23776–2.

ләр. Анда беренче рәттә утырганнар (сулдан уңга): Рәхим Солтанов (?–1920), Басыйр Габдуллин (?–?), Гадерәхим Адаков (1894–1918), Туктар Диникәев (?–?). Икенче рәттә: Касыйм (Миркасыйм) Туйбактин (1888–1918), Зәйни Солтанов, Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Сафа Биккинин (?–?), Давыд Мөхәммәдев (?–?), Әстерхандагы татар хатын-кызларыннан беренче булып сәхнәгә чыгучы Һаҗәрхан Мөхәммәдева (?–?), Зәйнәп Диникәева (?–?). Өченче рәттә басканнар: Габдерәхим Сәмәки (Әбубәкеров) (?–?), Рәхим Басыйри (?–?), Шәһит Гайфи, Әбубәкер Мәзини (Хәлилов) (?–?), Зөлкәфи Байкин (1888–1936) сурәтләнгән. В. Алиев бу фотоның бик күп кешеләрдә булганлыгын яза[1]. Аның бер төп нөсхәсе Үзәктә саклана[2].

Үзәктә аның икенче нөсхәсе дә бар. Ул 1914 елның 24 нче сентябрендә Җәмбәйте авылыннан (почта мөһере буенча) Уральск шәһәрендә Төркестан мәйданында яшәүче Исхак Калаков (?–?) исемле кешегә адресланган. Язуларның бер өлеше бозылган булса да, аңлашылганча, сүз хәл-әхвәл белешү турында бара:

«Исхаку Г=ну Калакову

Уральск

Туркестанская площадь.

Мөхтәрәм... хатыңда... күндердегем... саг-сәламәт... һәм үзеңезнең яз... хатыңны алдым. Нә язд... мәгълүм булды һәм Габдерахман монда саг-сәламәт йөри шикелле. Күп-күп сәлам диде.

Имза. Тажеддин Хәйбуллин.

1914. IX. 24».

Үзәктә Г. Тукайның Ф. Әмирхан белән төшкән фотоның төп нөсхәсе бар[3]. Чыганакларда ул 1908 елда алдырылган дип күрсәтелә. Сурәтнең арткы ягында шулай язылган: «Вафага. Ф. Әмирхан, Г. Тукай. 1911. 11. III.». Бу фотога төшү вакытымы, әллә бүләк ителгән тарихны белдерәме?

Г. Тукайның шулай ук 1908 ел белән билгеләнгән бер фотосыннан Казанда Рембранд фотоательесында эшләтелгән рәсем-открыткасы билгеле. Арткы ягында шагыйрь үз кулы белән болай язган: «Фатыйх! Күптән сөйләгән яланбашыңны ал инде (ядкяр) Г. Тукаев. 1911 сәнә 15 нче февраль».

Ул фотодан 1912 елда да рәсем-открытка ясатылган икән. Аның бер нөсхәсе Г. Тукайның әдәби музеенда бар[4]. Аның алгы ягына гарәп хәрефләрендә типография ысулы белән «Шагыйрь мәшһүр Габдулла Тукаев» һәм кириллицада «Г. Тукаев» дип язылган. Бу ядкяр 1985 елда Абушева дигән кешедән сатып алынган.

Аның тагын бер нөсхәсе Язма мирас үзәгендә саклана. Арткы ягында гади карандаш белән гарәп хәрефләрендә Маһитап Габдуллина (?–?) исемле кеше бер туташка (исемнең соңгы иҗеге генә күренә) шигырь язган. Әмма рәсем-открытканың аскы ягы киселгән булу сәбәпле, бер өлеше шулай:

---

[1] Габдулла Тукай Астраханьда. Сәгыйть Рәмиев белән (Вәлид Алиев истәлеге) // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 697.

[2] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3. тасв., 44 сак. берәм.

[3] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3. тасв., 29 сак. берәм.

[4] ТР ММ: № КП-19873–22.

«...имә туташка.
...генә дустым, һәр эштә уртагым,
...мдә кайгыручы син генә.
...нә дуслар шат көнемдә шатланыр,
...у килсә, өрдерәләр җил ген.
Сәгадәт талына менсәң, үзең мең,
Ни ярдәм килсә, килсен үзеңдин[1].
... төшсә, түз сер бирми-нитми[2],
Түкмә күз яше, ярдәмгә дә һәр заманда Аллаһ бар.
Ал җәсарәт (кыюлык), алга омтыл, һич ялыкмый алга бар![3]»

Г. Тукайның 1909 елда Г. Якобсон фотоательесында (логотип буенча) ялгыз төшкән бер фотосы билгеле. Әмма аның вакыты чыганакларда төрлечә, ягъни 1909, 1911 еллар күрсәтелә. Шагыйрьнең киеме, фотообъектив каршында үз-үзен тотышы, хәтта, арттагы япмадагы чәчәк тә алда әйтелгән фотодагы сурәтләнеш белән тәңгәл килә. Бер генә деталь уйландыра: монысында аның өске киеме төймәләнгән булса, ялгыз фотода төймәләр ычкындырылган. Әллә икәү бергә төшкәннән соң үзе генә дә төшәргә уйладымы икән дигән сорау да барлыкка килә. Ә ел мәсьәләсенә килгәндә исә, моны тагын тикшерәсе бар.

«Гасыр» матбагасы аның рәсем-открыткасын эшләтеп күбәйткән. Хәзерге вакытта бер нөсхәсе Г. Тукайның әдәби музеенда саклана[4]. Ул 1987 елда Л. А. Хәмзинәдән сатып алынган.

Шул ук рәсем-открытканың тагын бер нөсхәсе Дүшәнбе шәһәрендә яшәүче тажик әдәбияты белгече, филология фәннәре кандидаты Сәлахетдин Салиховта барлыгы мәгълүм[5]. Ул аны 1946 елда Ташкент шәһәрендә Шайхантохур базарында бер татар хатыныннан сатып ала.

Рәсем-открытканың әлегә мәгълүм өченче нөсхәсе Язма мирас үзәгендә бар[6]. Аны 1991 елда Әсма Шәрәф (1906–1993) (Ризаэддин бине Фәхретдиннең кызы) тапшырган. Сурәтнең алгы ягында болай язылган: «Мөхтәрәм Әхмәдгәрәй вә Габдерахман әфәнделәргә ядкяр. 5 нче август, 1912 сәнә. Г. Тукаев».

«Социалистик Татарстан» газетасының 1978 елгы 23 апрель санында Татарстан дәүләт музее әдәбият бүлеге мөдире Дания Баһаветдинова (1932–?) тарафыннан «Тукайның яңа табылган автографы» дигән мәкалә басыла. Анда сүз Казанда яшәү-

---

[1] Бу Г. Тукайның «Тормыш» дигән шигыренең тугызынчы бәете:
Сәгадәт талына менсәң — үзең мен;
Ни ярдәм килсә дә килсен үзеңдин.

[2] Бу Г. Тукайның «Тормыш» дигән шигыренең беренче бәетенең беренче юлыннан: *Авырлык төшсә түз, сер бирми-нитми...*

[3] Бу Г. Тукайның «Киңәш (Чикмә гамь...)» дигән шигыренең соңгы бәете:
Түкмә күз яшь: ярдәмендә һәр заманда алла бар;
Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!

[4] ТР ММ: № КП-20974–2.

[5] Салихов Б. Бер рәсемнең тарихы / Б. Салихов // Казан утлары. — 1968. — № 4. — Б. 120.

[6] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3 тасв., 49 сак. берәм.

че 81 яшьлек Шакир ага Хәкимҗанов әдипнең «Гасыр» матбагасы почта открыткасы итеп бастырган рәсемен тапшыруы турында бара. Аның үзенчәлеге тагын шунда ки, шагыйрь үз кулы белән рәсем өстенә мондый сүзләр язган: «Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй вә Габдрахман әфәнделәргә ядкярем. 5 август, 1912 ел Г. Тукай».

Д. Баһаветдинова, күрсәтелгән язуларга нигезләнеп, аны Г. Тукайның 1912 елда Троицкига кымыз белән дәваланырга бару вакыйгасы һәм аны чакырып китерткән Габдерахман хәзрәт Рахманкулов исеме белән аңлата. Чөнки ул Троицкида туып-үскән, Г. Тукайны күргән Исмәгыйль Һилаловтан белешеп, Г. Рахманкуловның Зыя (Зыятдин) һәм Әхмәтгәрәй исемле туганнары булганлыгын ачыклый.

Дөрестән дә, чыганаклардан күренгәнчә, Зыятдин (1881–1952) 1945 елдан Ырынбур мәчетендә имам вазифасын үтәп, 1952 елда вафат була. Димәк, Г. Тукай Троицкига килгәндә аңа 31 яшь була һәм аның да шагыйрьне күрүенә шикләнмәскә мөмкин. Әхмәтгәрәй (Әхмәт Таҗетдин Рахманкулов (1886–1939) исә, соңыннан журналист, драматург, публицист, прозаик, 1917 елда Троицк шәһәре мөселман бюросы нәшер иткән «Хөр милләт» газетасының мөхәррире була. Пьесалары 20 нче елларда сәхнәләрдә еш куела.

Язуларны игътибар белән укысаң, шундый сораулар барлыкка килә: әдәп кагыйдәләрен яхшы белгән Г. Тукай исемнәрне язуда ни өчен абзый тиешле Габдерахманнан түгел, ә аның энесе Әхмәтгәрәйдән башлаган? Шагыйрь Троицкида 5 нче августка кадәр торганмы?

Рәсем-открытка «Гасыр» нәшриятында бастырылганны истә тотып, җавапны шуннан эзләү, фикеребезчә, мантыйкка муафыйк булыр. Билгеле булганча, аны оештыручылар Ә. Хәсәни һәм әдәбиятта Г. Кәрам буларак билгеле театр тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче Г. Рәхмәтуллин була. Нәшрият 1908 елның җәендә Иске Татар бистәсенең уртасында Евангелистлар (хәзерге Татарстан) урамында бертуган Ибраһимовлар йортында ачыла. 1912 елда алар атнага ике тапкыр матур әдәбият, нәфис сәнгать һәм әдәби тәнкыйть «Аң» журналы да чыгара башлыйлар.

Журналга исемне дә Г. Тукай тәкъдим иткәнлеге мәгълүм. Басманың беренче саны аның «Аң» дигән шигыре белән ачыла.

Г. Тукай журналда хезмәттәшлеген хәтта вафатына санаулы гына көннәр калганда да дәвам иттерә. Моңа 1913 елның 20 һәм 28 нче мартында Клячкин шифаханәсеннән Ә. Хәсәнигә, аның хатыны, «Аң»ның сәркәтибе Зәйнәп Хәсәниягә (1888–1967) юллаган хатлары ачык дәлил.

Г. Кәрам шул чор көндәлек матбугатында, шул исәптән «Аң» журналында да, театр уеннарына күпсанлы бәяләмәләр язган. Казанда беренче тапкыр рәсми куелган татарча спектакльгә (1906) язылган бәяләмәнең авторы да ул була.

Ә. Хәсәни һәм Г. Кәрам 1917 елда Никитин типографиясен сатып алып, «Аң» дигән типография оештыралар. Ләкин ул 1918 елда совет хакимияте тарафыннан вакытлыча файдаланырга алына, ә 1919 елда хуҗалар аны рәсми рәвештә «үз теләкләре белән» яңа дәүләткә тапшырырга мәҗбүр булалар.

Ә. Хәсәни 1926 елда «Яңа китап» дигән хосусый басмаханә оештыра. Әмма аның эшчәнлеге 1929 елда туктатыла. Үзе 1931 елда кулга алынып, 1932 елда хөкем карары нигезендә Ак диңгез – Балтыйк каналы төзелешенә эшкә җибәрелә. 1934 елда срогын тутырып кайтканда юлда тиф авыруыннан вафат була.

Г. Кәрам исә Октябрь түнтәрелешеннән соң типографиядә корректор булып эшли. Театр белгече В. Креженцевнең «Творческий театр» исемле хезмәтен татар теленә тәрҗемә итеп, 1921 елда китап итеп бастырып чыгара. Матбугатта сирәк булса да мәкаләләре дөнья күрә. 20 нче еллар азагында Пролеткульт идеологлары тарафыннан «буржуаз милләтчелектә» гаепләнеп, публицистик эшчәнлектән читләштерелә. Ул 1947 елда Казанда вафат була.

Димәк, рәсем-открыткадагы язулар Ә. Хәсәни һәм Г. Кәрамга адресланган һәм фотоның оригиналы аларга бүләк ителгән булуына ышанырга тулы җирлек бар.

Татарстан Республикасының Милли музее фондында Г. Тукайның 1912 елның 26 нчы июлендә алдырган фотосының төп нөсхәсе (фотограф Г. Якобсон; логотип буенча) бар (Р. Б. Хәсәновадан 1993 елда сатып алынган)[1]. Аның арткы ягында болай язылган: «Иптәшем Мәхмүдкә ядкяр. 3 октябрь, Г. Тукай, 1912». Ягъни адресат шагыйрьнең иң якын дусларыннан берсе Мәхмүт Дулат-Алиев (1889–1920) була. Бу хакта аның кызы Ләйлә истәлегендә болай диелә: «Әти белән Тукайның дуслыгы гомерләре буе дәвам итә. Габдулла Тукай әтиемә үзенең рәсемен дә бүләк итә»[2].

Шагыйрьнең тууына 100 ел тулуына 1986 елда «Габдулла Тукай» дигән фотоальбом басылып чыгу уңаеннан биргән интервьюсында Зөфәр Бәширов бу фото турында болай ди: «Г. Тукайның 1911 елда төшкән фоторәсемен эзләгәндәге хәл алда әйтелгәннәремә дәлил була ала. Шагыйрьнең үз фотосын, артына язып, Дулат-Алиевка (1889–1920) бүләк иткәнлеге билгеле. Шул фото кызында калды микән, дип, эзләп барган идем, «Әти аны үзе музейга тапшырды», дигән җавап алдым. Дәүләт музеенда булып чыкмады, М. Горький музеенда да табылмады. Ниһаять, ул фоторәсемне Кырлайдагы музейда табу бәхетенә ирештем. Кырлайга ничек барып ирешкән? Моңа ачык кына җавап юк»[3].

Бу фото турында матбугатта иң әүвәл Ибраһим Искәндәров (?–?) (Ләйлә ханымның ире) игълан итә[4] һәм 1970 елда язучы Габдрахман Әпсәләмовка (1911–1979) бүләк итә[5].

Бу уңай белән берникадәр буталчыклар күренә. М. Дулат-Алиев «үзе музейга тапшырган» ул фотосурәт ничек янә аның кызында пәйда булып, аннары Кырлайга, соңра Милли музейга барып эләккән, монысы әлегә билгесез кала.

Истәлекләрдә Г. Тукай Троицкида фотосурәткә төшүе турында да мәгълүмат китерелә. Мәсәлән, Разия Мәҗитова (?–?) болай дип яза: «Ул (Тукай) кымыздан шактый озак йөреп кайтты. Кайткач та абзыйларга (Габдулла Бикчурингa) килде. «Менә мин шулай ял иттем», — дип абзыйга бер карточка күрсәтте. Мин дә алып карадым аны. Киң далада Габдулла абый кәзәкидән, ботинкадан сузылып кырын яткан.

---

[1] ТР ММ: № КП-22849–13.

[2] Дулат-Алиева Л. «Ир-ат эше» / Л. Дулат-Алиева // Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — Б. 58.

[3] Шагыйрь гомере энҗеләре [Мөхәммәт Мәһдиев һәм Зөфәр Бәширов белән әңгәмә] // Соц. Татарстан. — 1986. — 15 окт.

[4] Искандеров И. «Товарищу моему…» / И. Искандеров // Сов. Татария. — 1965. — 21 нояб.

[5] Әпсәләмов Г. Шагыйрьнең тагын бер рәсеме / Г. Әпсәләмов // Казан утлары. — 1970. — № 1. — Б. 156.

Тирә-ягы алай матур түгел, әмма үзенең йөзе шат. Ул рәсемне күрсәтте дә, аннан кире алды. Киткәндә үзе белән алып китте»[1].

Г. Манафова язмасыннан күренгәнчә, 1949 елга кадәр аларның гаиләсендә дә Г. Тукайның Троицкидан кайткач та алдырган бер фотосы сакланган икән. Бу хакта ул менә нәрсә ди: «Фоторәсеме әле дә күз алдыбызда: объективка туры карап утырган, кыскарак чәчле, юллы ак күлмәгә төймәләнгән кара костюм чабулары арасыннан күренеп тора. Йөрәк ягында өстән аска: «Мөхтәрәм Минһаҗ әфәндегә ядкарь, 1912 сәнә, җәй, Г. Тукаев», дип язылган иде. Тукайның йөзе тулы гына, күз карашында да артык йончулык күренми. Шуңа күрә, без Тукай далада дәваланып кайткач та Казанда төшеп, әтигә почта белән җибәргәндер дип тә уйлыйбыз. Кызганычка каршы, фото бирелү вакытын әтинең үзеннән сорап калмаганбыз. Мин Москвага аспирантурага укырга киткәч, 1949–1953 еллар арасында, Казаннан бер кеше килеп, искечә язылган журналлар белән бергә, бу фотоны да алып киткән (фамилиясен, адресын язып калырга уйламаганнар)».

Мондагы тасвирланыш белән Байназар Әлминовның (1909–1976) «Г. Тукай Троицк далаларында» дигән картинасының эчтәлегендә берникадәр охшашлык сизелә. Шуңа күрә, рәссам фотоның оригиналы белән таныш булмадымы икән дигән сорауга да урын кала.

Бу уңайдан 1912 елда алдырылган ниндидер күмәк фотодан ертып алынган өлешендә Гафур һәм аның энесе К. Коләхмәтовлар, Ф. Әмирхан белән бергә сурәтләнгән Г. Тукайның[2] кыяфәте, утыру рәвеше (киеменнән башка, әлбәттә) алда сөйләнелгән рәсемнәре белән шактый охшашлыгы турында әйтеп үтү урынлы булыр.

З. Бәширов бу фото турында үзенең шундый фикерләрен белдерә: «Фотографиядә кабул ителгән стандарт буенча (рәсем горизонталь булган очракта) аның иңе 27,5 сантиметр булырга тиеш. Әгәр дә Г. Тукай уртада утырган дип исәпләсәк, бөтен фоторәсемдә тагын 6 кеше булырга тиеш»[3].

К. Бәкер карамагында шагыйрьнең бер фотосы булганлыгы ачыклана. Ул «Тукай Петербургта» (1914) дигән китабының тышлыгына бастыра һәм бу хакта шулай аңлатма бирә: «Бу рисаләнең башына Тукайның кыскача тәрҗемәи хәле илә буңа кадәр һич йирдә табгы ителмәгән[4] рәсеме дәреҗ кыйлынып[5], ахырына Петербург ахунды Сафа Баязидов илә Хәбиберхаман әфәнде Зәбиревнең хатирәләре дә гыйлавә ителмешдер[6]». Бу фотоның язмышы әлегә билгеле түгел.

Үзәктә Г. Тукайның Клячкин шифаханәсендә вафатыннан егерме сигез сәгать кенә элек 1 нче апрельдә төшерелгән иң соңы фотографияләренең ике төп нөсхәсе бар. Аның берсе шагыйрь караватта утырган, икенчесе аркасына мендәрләр куеп яткан хәлендә алдырылган[7].

---

[1] Мәҗитова Р. Габдулла абыйны күргән көннәрем / Р. Мәҗитова // Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — Б. 62.

[2] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3 тасв., 57 сак. берәм.

[3] Бәширов З. Киселгән язмышлар / З. Бәширов // Шәһри Казан. — 1995. — 26 апр.

[4] *Табгы ителмәгән* — бастырылмаган.

[5] *Дәреҗ кыйлынып* — теркәлеп.

[6] *Гыйлавә ителмештер* — өстәмә ителде.

[7] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3 тасв., 67 сак. берәм.

Икенче фотоның[1] шагыйрьдән башка өлеше ниндидер үткен предмет белән кисеп алынган һәм кара кәгазь ябыштырылган. Ул 1926 елда Ф. Бурнаш төзеп бастырган «Г. Тукаев шигырьләре» дигән китапта да шулай бастырылган. Әмма 1927 елда «Яңалиф» журналының 3 нче санында дөнья күргән бу фотода шагыйрьнең баш очында аның якын дусларыннан танылган артист Г. Кариев, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Ф. Сәйфи-Казанлы һәм Ш. Әхмәрев бар.

Җеназа мәрасименнән җиде фото булганлыгы ачыклана. Аларның 5-се хәзерге вакытка килеп ирешкән. Чөнки Клячкин шифаханәсенең ишек алдында җеназа җирдән күтәрелгәч, кабергә иңдерелгән вакытта алдырылган фотосурәтләрнең язмышы әлегә билгесез кала. Ә җирләү тәмамлангач чыгартылган фото беркайда да телгә алынмый. Ул кайбер чыганакларда кабергә иңдерелгән вакытта чыгартылган рәсеме[2] дип тәкъдим ителә. Иң соңгы алдырылганы шундый тасвирлау белән тәңгәл килә: «Күмү тәмам була. Ханым вә туташлар тезелешеп чәчәкләр китерә, кабер өстенә тәртипләп тезелә, кабернең тупрагы күренми, ул хәзер кабер түгел, чәчәк өеме булып әверелә…»[3].

Аның тагын бер төп нөсхәсен 1936 елның декабрендә Гобәйдулла Сиражи (?–?) исемле кеше Нурмөхәммәт Абдусабировның (?–?) гаилә альбомыннан алып, Оренбургка Фатих Солтановка (?–?) җибәргән. Аңардан Гөлсем Хәсәнова (?–?) алган. Шул нөсхәдән 1988 елның 8 маенда Мәдинә Рәхимкулова (1916–2004) күчермәсен ясата һәм матбугатта игълан итә[4].

«Кояш» газетасында Юнысовлар мәйданында «Җеназа укылганнан соң, бу урында да рәсемнәр алынды»[5], дип әйтелә. Димәк, билгеле фотодан башка тагын бүтән төрләре дә булган.

Шулай итеп, тикшеренүләребез күрсәткәнчә, әлегә Г. Тукайның барлыгы 29 фотосы булганлыгы ачыклана. Хәзерге вакытта аларның 14 төп нөсхәсе бар (кайберләре берничә данәдә).

Шагыйрьнең фотоларыннан эшләтелгән 8 рәсем-открыткасы булып (шулай ук кайберләре берничә данәдә), 2 сенең язмышы билгесез кала.

Фотоларда, китапта, конфертта, дәфтәр тышында 6 автографы сакланып калган.

Шагыйрь каберенә башта куелган таш һәм чардуганның 1946 елда алдырылган рәсеменең ике төп нөсхәсе Үзәктә саклана.

Биредә китерелгән мәгълүмат, тулылыкка дәгъва итми, әлбәттә. Шагыйрьнең башка фотолары һәм рәсем-открыткалары да киләчәктә тагын табылыр дип ышанасы килә.

X

Г. Тукай иҗаты инде шактый гына өйрәнелсә дә, бер мәсьәлә һаман да үзенең ачыклавын көтә. Ул — шагыйрьнең кулъязмалары һәм автографлары. Алар хәзерге вакытка килеп ирешкәнме? Ирешсәләр, алар ничә һәм кайда саклана?

---

[1] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 3 тасв., 62 сак. берәм.

[2] Казанда 4 нче апрель // Мәктәп. — 1913. — № 4. — Б. 111.

[3] Казанда 4 нче апрель // Мәктәп. — 1913. — № 4. — Б. 111.

[4] Рәхимкулова М. Күрс. хезм.

[5] Әлиф Би. Тукаевны озату мәрасиме / Әлиф Би // Кояш. — 1913. — 7 апр.

Әдип әсәрләренең төп нөсхәләреннән, мәсәлән, төрки-мөселман дөньясында татар хатын-кызларыннан беренче артистка Сәхипҗәмал Гыйззәтуллина-Волжскаяга (1892–1974) багышлап язган «Ике кояш!» дигән мәдхиясе Татарстан Республикасының Дәүләт архивында саклана. Аның тексты мәгълүм булса да, биредә тагын бер тапкыр искә төшереп үтү артык булмас:

Ике кояш!

Күр: ничек, иртә кояш чыкса, җиһанда нур тула, –
Һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззәтуллина.
Бу икәүгә Тәңре биргән бертигез зур мәртәбә;
Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге тупланмасында Г. Тукайның «Толстой сүзе» шигыренең төп нөсхәсе саклана[1]. Ул зур булмаган кәгазьгә кара белән язылган. Ахырда «Г. Т. 4 март 1913 сәнә. Шифаханә» дип куелган. Ә кәгазьнең арткы ягында янә шундый бер шигъри юл бар:

Артык ул алганга нәмәгълүм гарибең актыгын.

Үзәк тупланмасында тар итеп киселгән зәңгәрсу төстәге кәгазьгә көрән кара белән язган «Толстой сүзләре», «Буш вакыт», «Мәктәп» дигән шигырьләре бар[2]. Текстлардан аста болай язып куйган: «Г. Т. 28 март 1913 сәнә. Шифаханә». Ул аларны шул ук форматлы кечерәк күләмле кәгазьдә «Аң» журналы сәркятибе З. Хәсәниягә күндергән хат[3] белән юллый. Хат гади карандаш белән язылган:

«Мөхтәрәмә Зәйнәб ханым!

8 нче санга бар кадәремне җибәрдем. Беренче корректурын үземә күрсәтсәңез икән. Андан соң шушы язылган микъдар шигырьнең һәммәсе бер нумерга кереп бетсә иде. Шулай булганда, ул шактый көч булырлык. Хәер, «Толстой сүзләре»нең бер-икесен цензор бозар кеби сизәм. Ул вакыт һәммәсе дә басылуы мәҗбүри үк булыр. Г. Тукаев. 1913, 28 март».

Үзәк тупланмасында шагыйрь үз кулы белән язган «Пожар вакытында кызгану» исемле сатирик парчасы бар[4]. Текстның иң өске өлешендә «Ялт-йолт»ка дип куелган. Кәгазь нәрсәдәндер шактый зарарланган. Ахырда «Шүрәле» имзасы куелган һәм җәяләр эчендә «Мөнтәзам кыйраәт» китабыннан» дип язылган.

Бу парчада, аңлашылганча, сүз «Бәянелхак» газетасы нашире һәм шул исемдәге типография хуҗасы, икенче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Сәйдәшев (1865–1914) һәм Оренбургтан килеп, шул басмага эшкә урнашкан бер кеше турында бара. Ә аның кем булуын әлегә әйтүе кыен, тикшеренәсе бар.

Билгеле булганча, Г. Тукай «Сатирикон», «Будильник» дигән һәм башка рус сатирик журналларын даими укып барган һәм андагы әсәрләрне үзенең иҗатында киң файдаланган. «Будильник»ның 1912 елгы 40 нчы санының соңгы бите артында кырыйларга ул ике шигырь дә язып куйган. Тематик яктан алар бер-берсенә бәйләнмәгән. Ике юллык кына булган берсе болай:

---

[1] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 1 тасв., 6 сак. берәм.
[2] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 1 тасв.8 6 сак. берәм.
[3] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 1 тасв., 8 сак. берәм.
[4] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 1 тасв., 22 сак. берәм.

Бәлки белгәндер аны тау сырты диб,

Бәлки Муллин Борһан аты бүрке диб.

Биредә әйтелгән Борһан Муллин (1834–1917) — Казан сәүдәгәрләренең берсе. Ул шагыйрьнең «Ялт-йолт» журналында (1913 елгы 49 нчы сан) «Счет төймәсе» имзасы белән бастырган «1912 нче елның онытылганнан калган гына хисабы» дигән мәкаләсендә дә телгә алына: «1912 нче елда гакылы тагы да күбәеп, артып, ташып киткәнлектән, Муллин Борһан абзыйның бүреге тагы да бер подаука кадәр генә зурайды».

Ә икенчесе Балкан сугышы вакыйгаларына багышланган. Монысы «Вакыт» газетасының 1912 елгы 7 нче ноябрь санында «Гъ. Т.» имзасы белән «Тәмсил» дип басылган[1].

Журналның Г. Тукай үз кулы белән язган әлеге бите хәзерге вакытта Үзәктә саклана.

Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург кулъязмалар институтында шагыйрьнең ике хаты саклана. СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты Ленинград бүлеге тарафыннан оештырылган археографик экспедиция Уральскида вакытта (1935 елның 28 нче августы), Г. Тукайның мәдрәсә сабакташы Гайнетдин Туприев (?–?) шагыйрь 1909 елның 13 нче мартында аңа язган хатын тапшыра. Ул факсимилесе белән беренче тапкыр «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 5 нче санында бастырыла[2].

Шагыйрьнең әстерханлы Пирмөхәммәт Ниязовка (?–?) юллаган хатын шул ук экспедиция вакытында Габдерахман Ниязи исемле кешенең китаплары арасыннан табыла. Хат ачык открыткага язылган.

Хаттан аңлашылганча, П. Ниязов «Тәмәдден, яхуд Мәгарифе исламия» дигән китап соратып, акчасын да түләгән. Әмма китап цензурага инде өченче тапкыр бирелгән. Басылып чыккач та, мотлакан җибәреләчәге вәгъдә ителә. Ахырда «Уральск шәһәрендә Мөхәммәд Камил әл-Мотыйгый Төхфәтуллин өчен кантурщик Габдулла Тукаев. 1904 сәнә 11 декабер»[3].

Үз вакытында Г. Тукайның дусларыннан берсе, журналист, җәмәгать эшлеклесе К. Сәгыйдов архивында шагыйрь тарафыннан «Мәгариф» матбагасы хуҗаларыннан берсе Г. Шәрәфкә Уральскидан 1907 елның 9 нчы июнендә җибәрелгән (почта мөһере буенча) хатның төп нөсхәсе сакланган. Бу хакта галимнең кызы филология фәннәре кандидаты, библиограф, китап белгече Энҗе Сәгыйдова (1921–1997) язып чыга[4]. Почта открыткасына язылган бу зур күләмле булмаган хатны без бары тик матбугатта басылган фотокүчермәсендә генә күрәбез. Аның эчтәлеге болай:

«Хөрмәтле Гыйльметдин Шәрәф әфәнде!

---

[1] Гъ. Т. Тәмсил // Вакыт. — 1912. — 7 нояб.

[2] Tatar xalьq şaoqire Cabdulla Tuqaj turьnda jaŋa materiallar // Sovet ədəbiatь. — 1936. — № 7. — B. 73–77 (факсимиле), 78–80 текст.

[3] Tatar xalьq şaoqire Cabdulla Tuqaj turьnda jaŋa materiallar… — B. 79 (факсимиле), 81 (текст).

[4] Сәгыйдова Э. Тукайның ике җыентыгы / Э. Сәгыйдова // Казан утлары. — 1970. — № 1. — Б. 150–155.

Тарафыңызга, заказной бандероль уларак, «Әшгар мәҗмуга»мны җибәрдем. Шигырьләрнең мөкатдәм муаххар[1] басылуын рәкымнар[2] илә яздым. Үзеңез аерырсыз. Зинһар, яхшылап тәсхих итеп[3] басыңыз. Азсынсаңыз, ошбу арада тагы бәгъзе тәхрират[4] җибәрермен. Үзеңез дикъкатьләп карап чыгыңыз да, нәшер итәргә разый булсаңыз, миңа тизлек берлә 50 тәңкә акча җибәреңез. Ихтимал, аннан соң Казанга үзем барып, китабымны лично тәсхих итеп бастырырмын. Әгәр разый булмасаңыз, китапны кире үземә кайтарыңыз. Инде мин сезгә бөтенләй тапшырдым. Ничә мәртәбә бастырсаңыз да рөхсәт. Җавап көтәм. 7 нче июньдә мәктүбеңезне алдым. Шартыңызны кабул итәмез димешсез. Бәндәңез Г. Тукаев.

Адресым. Въ г. Уралскъ. Гост. «Казань» А. Тукаеву».

Г. Шәрәфнең бер хатында «1907 елның җәендә «Мәҗмуга»сын нәшер хакында 5–6 мәктүп[5] яза»[6], истәлегендә исә «1907 нче сәнә август 9 нда язган мәктүбендә үзенең озакламый Казан әтрафына каралу өчен (призывка) кайтып, аннан Казанга килүен яза»[7] дигән сүзләрне укырга мөмкин.

Бу ядкярнең язмышы хәзерге вакытка билгесез калса да, аны эзләп карарга кирәк иде. Чөнки Э. Сәгыйдова гомере буе Санкт-Петербургтагы М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәдә эшләде. Вафатыннан соң хосусый архивы шунда алдырылмадымы икән?

Г. Шәрәф аннан соң да Г. Тукайның хатлар язуын, алар белән әсәрләрен җибәрүен яза[8].

Каенсарда яшәгән апасы С. Хәбибуллинага Уральскидан 1903 елның 30 июнендә язган хатының төп нөсхәсе Үзәктә саклана[9].

Шул ук апасына язган икенче хатында (күчермәсе[10] генә сакланган — *Р. И.*), елы куелмаган, Г. Тукай эне-сеңелләренә, жизнәсенә, бабасы Зиннәтуллага күп сәламнәр юллаганнан соң, үзенең хәлләренә күчеп, ничек укуын, Гурьевкадагы бай туганнары, ахун җизнәсе ярдәм итүен, апасы Бибигазизә белән аралашып торуын яза.

«Вә кянә үзеңезнең йибәргән әманәтеңез сәламәт тапшырылды» дигән сүзләрдән аңлашылганча, Сажидә аңа ниндидер әйберләр дә җибәргән булса кирәк. Г. Тукай да апасына ярты кадак чәй, бер яулык һәм исле сабын җибәргәнлеген яза.

Г. Тукайның Гурьевкадагы бай туганнарына язган хатының төп нөсхәсе булмаса да, аның язучы Кави Нәҗми (1901–1957) тарафыннан язылган күчермәсе билгеле[11].

---

[1] *Мөкатдәм муаххар* — басылу тәртибен.

[2] *Рәкымнар* — саннар.

[3] *Тәсхих итеп* — төзәтеп, дөресләп.

[4] *Тәхрирәт* — язу, хат.

[5] *Мәктүп* — хат.

[6] Сәгыйдова Э. Тукайның ике җыентыгы / Э. Сәгыйдова // Казан утлары. — 1970. — № 1. — Б. 151.

[7] Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар... — Б. 266.

[8] Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар / Г. Шәрәф // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 265–266.

[9] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 2 тасв., 10 сак. берәм.

[10] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 2 тасв., 13 сак. берәм.

[11] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 2 тасв., 19 сак. берәм.

Шагыйрь Бари Рәхмәт (1897–1957) үзенең истәлегендә шул хат турында мәгълүмат китерә. Аннан күренгәнчә, ул аны кайсыдыр елда Гурьевкада яшәүче Хәйрелбәнаттан[1] ала. «Хатның кай елны язылуы билгесез. Ул аны Гурьев шәһәренең байлары Әүхәди[2] һәм Әхмәди Абдуловларга яза. Тукайның алар белән мөнәсәбәтенең сәбәбен мин аңлый алмадым, әлбәттә»[3], — дип яза истәлек авторы. Бу хат турында икенче истәлегендә шулай әйтә: «Ул хатны мин 1927 нче елларда Кави Нәҗмигә биргән идем (ул хат хәзер югалган бугай). Ул хатның күчермәсен мин әллә Гыйльми Камайгамы[4] яки Тел, әдәбият институтыннан берәүгәме биргән идем. Ул күчермә хәзердә исән булса кирәк»[5].

Казан (Идел буе) федераль университеты Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Г. Тукайның китап бастыру һәм китап белән сәүдә итү ширкәте хуҗасы Габдерахман Дәүләтшингә (?–?) язган хаты саклана[6]. Ул гарәп хәрефләрендә «Габдулла Тукаев» һәм кириллицада «А. М.-Г. Тукаевъ» дигән логотиплы кәгазьдә язылган. Аның эчтәлеге болай:

«Хөрмәтле Габдерахман әфәнде!

Менә Сезгә актык мәртәбә мөрәҗәгать итәм: әгәр Сездә миңа тиешле акча, үзеңез әйткәнчә, беткән булса да. Пожалуйста, Сез хәзер 25 сум акча биреп йибәреңез әле. Мин Сезгә, вәгъдәм буенча, тиздән бер китап бирермен.

Ошбу көннәрдә Оренбургка хат яздым. Анда барсам, баргач та акчаңызны йибәрермен. Китап та минем өсттә калыр.

Китап басылып беткәч, «Сабах»тан үзеңез күпме барын алырсыз. Әле Гыйльметдиндә дә алачак бөтен. Пожалуйста, (сүземне) кире кайтармаңыз, бер җәйге пальто алмакчы идем бу көннәрдә.

Г. Тукаев.

1908, 9 июнь».

Г. Тукайның Ф. Әмирханга язган ике хаты саклана. Беренчесенең[7] күләме ике биттән гыйбарәт. Өске өлешендә гарәп хәрефләрендә «Габдулла Тукаев» һәм кириллицада «А. М.-Г. Тукаевъ» дигән логотип куелган. Көрән кара белән язылган текст болай:

---

[1] *Хәйрелбәнат* — Г. Тукайның атасы Мөхәммәтгарифның бертуган энесе Шакиржан хатыны.

[2] *Әүхәди* — Г. Тукайның атасы ягыннан булган әбисе Мәргубә (?–?) абыстайның (Мөхәммәтгалим мулланың җәмәгате) бертуганы Мөхәммәди (?–?) улы.

[3] Рәхмәт Б. [Истәлек] / Б. Рәхмәт // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 153.

[4] *Гыйльми Камай* — Гыйлем Хәйри улы Камай (1901–1970), химия фәннәре докторы, профессор.

[5] Бари Рәхмәт иптәш белән сөйләшү // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 169.

[6] К(П)ФУ СКһКБ: № 345Т (5556).

[7] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 2 тасв., 1 сак. берәм.

«Фатих әфәнде! Сәлам конечно.

Хатыңызны алдым. «Әл-ислах»да «Кызык гыйшык» шигырен яратдыңызмы? Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән төсле, мин дә сөю хакында бер нәрсә язсам, ялган имзалар астына сыгынам. Язам шунда. Үзем хәзер бер нәрсәне дә бер кемне дә сөймим. Күңел эчү белән тәмаман бозылган.

Уянды (хандра) күңлемдә инде

Караңгылык күңелдә нурны җиңде!

Торам, торам да: «Я Раббы! Ятимлекәр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да саклап килдегем истигъдад очкынын шушы исереклекләр, исерек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?» — дим.

Тәмам бер сәнә җон агызып йөрим бит!

Бу хәл туйдырды инде тәмам. Оренбургка Фатих Кәримев чакырган иде. Анда барсам, бәлки, үземә мөгайян[1] эш булуы һәм серьезный кешеләр тирәсе файдалы булыр иде, дим. Нишлим? Барыйм микән?

Монда «Әл-ислах» худка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем. Ләкин бу да бәгыйд[2]. Шушы минем кайгым тугрысында бер-ике юл языңыз әле. Һаман үземне генә сөйлим икән. Сезнең кәефле насыл[3] әфәндем? Анда баргач тәәсереңез ничек булды? «В.-К.»да[4] «Татарин» имзалы бер зат теге Касыйм Уралецка җавап язды. Сезгә кирәк булса, шул нумер гәзитәне җибәререм.

Монда хосусый минем хәл искечә. Көндез «Ислах» идарәсенә барып утырам. Кич «Швейцария»[5], «Аркадия»[6], «Панаевский»ләргә[7] барам. Мин әле кая барам.

Соңгы нумерга бер нәрсә дә яза алмадым. Бик озын бер хат языңыз әле, зинһар.

Г. Тукаев.

23 июнь 1908»[8].

---

[1] *Мөгайян* — билгеләнгән.

[2] *Бәгыйд* — ерак.

[3] *«В.-К.»да* — сүз 1907 елның 1 декабреннән 1908 нең 30 сентябренә кадәр Казанда нәшер ителгән көндәлек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби «Волжско-Камская речь» газетасы турында бара.

[4] *Насыл* — ничек.

[5] *«Русская Швейцария»* — Казанда хәзерге М. Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркы урнашкан урын.

[6] *«Аркадия»* — бакча, Казан халкының Кабан күле буенда ял итә торган урыны. 1895 елда нигезләнеп, үткән гасырның 20 еллары азагына кадәр булган.

[7] *«Панаевский»* — «Панаев» бакчасы *«Аркадия»* Казанда хәзерге өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы «А. Алиш исем. Балалар иҗат шәһәр сарае» һәм «Динамо» стадионы урынында булган.

[8] Бу хатның табылу тарихы турында: Агишев Я. Г. Тукайның хаты / Я. Агишев // Совет әдәбияты. — 1941. — № 12. — Б. 67–69.

Икенче хат[1] тар итеп киселгән көрәнсу төстәге кәгазьдә. Беренче дүрт юлы кызыл, калган өлеше гади карандаш белән язылган:

«Фатих!

Мәкаләне бик сирәк нәрсәне баскан кеби зурлап баскансыз. Рәхмәт. Тагы да язмый булмас, ахры, дип торам әле.

Хәтереңдә булса, Шиһаб хәзрәтнең[2] әллә кайсы гарәп шагыйрендән алып Болгар гар манарасына язган бәетен язып җибәр әле. Хәзер үк.

«Кояш» тәртипсез килә. Соң килә. 72 нче нумер бер көндә өчәү килде. Бүгенге нумер ике килде. 73 не исә бөтенләй күргәнем юк. Зинһар, хәзер бер нумерын йибәрсәңезлә! Зәкәрия абзыйга[3] сәлам.

Бәндәңез Тукай.

1913 сәнә 18 март».

Кардәше Камалетдин Хисаметдиновка (1882–1966) хат ачык открыткага язылган[4]. Адресы һәм эчтәлеге болай:

«Кара-Тюбинский базар Уральской области. Камалетдину г-ну Хисамутдинову.

Бөрадәр Кәмаледдин әфәнде!

Һәр өч хатыңны да алдым. Җавап язмаганым өчен гафу итәсез. Чөнки һичкемнең хатына да каршы җавап язмыйм. Әллә нигә ялкауландым. Хәзер бер җирдән дә хат килми. Барысы да миндән җавап булмаганга туктадылар.

Хатыңны «Юл» көтепханәсенә күрсәттем. «Дөруссеш шифаһиянең» ничәнче җөзьәләрен һәм нәхүнең[5] нинди нәхү вә кем тәэлифе[6] икәнлеген аерым язуыңызны үтенәләр. Дәфтәрдә чынлап та җибәргән акча вә маркаларыңыз күренми.

Шулай да хат язып, нәрсә вә ни сумага китап сораганыңызны язсаңыз, Сезгә ышанып китаплар җибәрелер.

Бакый ихтирам. Г. Тукаев. 25 синтәбер. 1910».

Билгеле булганча, адресат — Кушлавыч авылы кешесе, Г. Тукайны Кырлайдагы Сәгъди абзыйлардан алып Уральскига озатып җибәргән Бәдретдин Хисаметдинов улы булып, Уральскида яшәгән. 1953 елның кышында Казандагы Закир Зарипов (?–?) дигән кешегә язган хатыннан аңлашылганча, ул соңыннан Кыргыз ССРның Күк-Җангак шәһәрендә гомер кичергән.

Г. Тукай 1910–1912 еллар арасында Сәгыйть Сүнчәләйгә (1889–1937) 12 хат язганлыгы мәгълүм. Әмма аларның 4 се адресат үзе исән вакытта ук югала. 1923 елда С. Сүнчәләй шагыйрьгә багышлап җыентык әзерләргә уйлый һәм анда бастыру өчен хатларның күчермәләрен булдыра. Ләкин, ул җыентык дөнья күрми кала һәм хатларның төп нөсхәләре дә югала.

---

[1] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 2 тасв., 5 сак. берәм.

[2] *Шиһаб хәзрәт* — сүз Шиһабетдин Мәрҗани турында бара.

[3] *Зәкәрия абзый* — Зәкәрия Садретдинов (1880–1930), «Кояш» газетасының мөхәррире, соңрак нашире.

[4] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 2 тасв., 15 сак. берәм.

[5] *Нәхү* — синтаксис.

[6] *Кем тәэлифе* — кем әсәре.

С. Сүнчәләйнең агасы Шәриф Сүнчәләй (1885–1959) әнә шул күчермәләрдән алты хатны «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә тапшыра һәм алар басманың 1960 елгы 1 нче санында бастырыла[1].

Хәзерге вакытта Үзәктә Г. Тукай 1911 елның 20 октябрендә С. Сүнчәләйгә язган бердәнбер оригинал хат кына саклана[2]. Ул буйлы дәфтәр битенә кара белән язылган:

«Мелла Сәгыйд! Бу хат белән теге вәгъдә иткәнем Садриның ачык хатын җибәрәм. «Шура»да һәм «Идел»дәге «Мусульманство»ны яклаган мәкаләләреңне укыдым. Балаларга ярдәмгә килүем тугрысындагы дөрест фикереңә тәхсин[3]. Бүген сигезенче көн инде, авыруым килми. Авыруына кайгырмаганым шикелле, сәламәтләнүенә дә куанмыйм. Барыбер. М.-гә мин, яхшы тәэсир калдырганмындыр. Чөнки аның алдында мин һаман көлдергечлек ролен уйнадым. Һәм аның безнең Казанның бәгъзе интеллигенләрендән аерым булуына вә укып та чукынмаганлыгына, һаман татар булып калуына таянып, андан бер дә тартынмыйча, алдына рухымны ачып салдым.

«Мусульманство» һәм «Мусульманин»[4] кешеләре хакында монда төрле сүзләр сөйләнгәнгә генә тәвәкъкыф итәм[5]. Югыйсә, миндә «Мусульманство»ның татарчасына бастырырга шигырьләр бар.

Син аларны кемләр дип таныйсың? М. ул кавказлыларга алданып йөрми микән?

Мин хәзергә шул кадәр генә язам. Вакытым аз.

Бакый сәлам вә ихтирам. Г. Тукаев.

1911 сәнә 20 үктәбер».

Хатта башта Мирсәяф дип язылып, соңыннан аны сызылып, М. дип кенә калдырган кеше исә укытучы һәм шагыйрь Мирсәяф Кәримбаев (?–?).

Кызганыч ки, Г. Тукайның 1912 елның 24 апрелендә Петербургта язылып, «Ялт-йолт» журналының шул ук елгы 39 нчы санында басылган «Яңлыш уйланмасын» дигән мәкаләсе һәм 1912 елның 11 маенда Уфадан әйтелгән басманың мөхәррире Ә. Урманчиевка язган хатының әле 70 нче елларда кулда булган төп нөсхәләрен дә хәзер шагыйрь «Әсәрләр»енең 1977 елда нәшер ителгән дүртенче томында фотокүчермәләрен генә күрә алабыз.

Петербургтан кайткач К. Бәкергә язган хаты белән бары тик адресатның мәгълүм китабыннан гына танышырга мөмкин[6].

Шагыйрь Клячкин шифаханәсеннән Ә. Хәсәнигә тар форматлы зур булмаган кәгазьгә язган хатының[7] эчтәлеге шулай:

«Мөхтәрәм Гәрәй әфәнде!

---

[1] Сүнчәләй Ш. Габдулла Тукайның Сәгыйт Сүнчәләйгә хатлары / Ш. Сүнчәләй // Совет әдәбияты. — 1960. — № 4. — Б. 136–141.

[2] ТР ФА ТӘҺСИ ЯМҮ: 9 ф., 2 тасв., 8 сак. берәм.

[3] *Тәхсин* — мактау.

[4] *«Мусульманин»* — 1908 елда Парижда чыга башлаган фәнни-популяр, әдәби һәм иҗтимагый журнал.

[5] *Тәвәкъкыф итәм* — тукталам.

[6] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 55–56.

[7] ТР ФА ТӘҺСИ ЯМҮ: 9 ф., 2 тасв., 17 сак. берәм.

«Бер мөхәрриргә» шигыремдә «Аң»га лаек дәрәҗәдә үк нәфасәт[1] күрмәгәнемә күрә, «Мәктәп» журналына бирдем. Анда да ул шигырьне баш сәхифәгә керттермәдем. Ахырда вә незаметныйрак җирдә китәчәк. 7 нче санда минем шигырь бик аз вә кешегә сизелерлек аз кергән. Өстәп йибәрергә бер нәрсәм бар иде. Инде, әлбәттә, соңдыр. Инша Алла, 8 нчедән дә гафил калмам. Бер шәй язармын. Шулай да 7 нчегә өстәргә материал алып китсәң, ярыйдыр иде. Көн дә сине көттем. Хәер ула.

Г. Тукай. 1913 сәнә, 20 март».

Үзәктә беренче битенә «Мәктәп шигырьләре. Г. Тукаев. 1909 сәнә 12 үктәбер» дип язылган юка гына дәфтәр саклана[2]. Анда көрән кара белән «Мөкаддәмә», «Китаб», гади карандаш белән «Кечкенә музыкант», кара белән «Читен халь» (астында «Г. Т. 14 июль 1911» дип куелган), «Сез дә, и мөһлик мәрызлар! Урныңызны ташлаңыз...» (Г. Т.) дип башланган, «Яшен яшьнәгәндә» (Г. Т. 26 июнь, 1911 сәнә) шигырьләр тупланган. Ләкин болар шагыйрьнең үз кулы белән язылган нөсхәләргә бик үк охшамаган.

«Сез дә, и мөһләк мәрызлар! Урныңызны ташлаңыз... » дип башланган юллар Г. Тукайның «Өмидсезлек» дип аталган шигыреннән. Кулъязма дәфтәрдә ул тулысынча түгел, ягъни аның алдагы 5 бәете юк. Моны дәфтәр битенең югалган булуы белән дә аңлатырга мөмкин. Әмма китерелгән кадәрлесе дә тулысынча түгел. Биредә тагын ике бәет төшереп калдырылган. Шагыйрь үз кулы белән язса, шундый буталчыклар барлыкка китерер идеме икән?

Бу шигырь беренче тапкыр «Вакыт» газетасының 1910 елгы 22 май санында басылып чыга. Аннан соң Ф. Бурнаш төзеп нәшер иткән «Г. Тукай шигырьләре» җыентыгына урнаштырыла. Ләкин анда текстның сүзләренә, грамматикасына сизелерлек үзгәрешләр кертелгән.

Г. Тукайның хатлар алышуы, башка кайбер кулъязмалары булганлыгы турында кайбер истәлекләрдә мәгълүмат теркәлеп калган. Әйтик, Уральскида мәдрәсәдә бергә укыган сабакташы Я. Моради җәйге ял вакытында Гурьевкада булганда Габдулланың аңа хатлар язганлыгын, аның башка кешеләрдән дә хатлар алуы турында яза[3]. К. Сәгыйдов үзенең истәлегендә шулай яза: «Габдулла әфәнде Тукаев белән минем арадагы мөнәсәбәт 1905 елдан башланды. Ул вакыт мин Оренбургта, ул Уральскида иде. Шул вакыт мин «Фикер» белән «Әлгасрелҗәдит»кә язган нәрсәләренә карата аңардан өч-дүрт мәртәбә хат алдым. Мөнәсәбәт фәкать шуннан гына гыйбарәт иде. Ул көннән бирле минем тормышта төрле-төрле үзгәрешләр булып үткәнгә, табигый, аның хатлары сакланмаган, югалганнар»[4].

Р. Әмирова-Мөхәммәтҗанова үзенең истәлегендә шундый мәгълүмат китерә: «Киткәндә (Өчиледән — *Р. И.*) бездә беркадәр кулъязмалары калган иде. Ирем аларны 1930 нчы елларга кадәр саклады. Шул елларда безне өебездән чыгарып, үзебезнең бөтен китапларыбызны алдылар. Шунда аның кулъязмалары да китте. Са-

[1] *Нәфасәт* — гүзәллек.

[2] ТР ФА ТӘһСИ ЯМҮ: 9 ф., 1 тасв., 1 сак. берәм.

[3] Моради Я. Тукаев Уральскида. Басылды «Г. Гомәрев вә шөрәкясенең» тиҗарәтханәсендә. — Астрахань: Тип. Т-го Д-ма «А. Умеров и Ко», 1913. — Б. 15, 16, 17, 22.

[4] Сәгыйдова Э. Кәрим Сәгыйд архивыннан / Э. Сәгыйдова // Казан утлары. — 1968. — № 4. — Б. 115.

җидә[1] апасында да аның байтак кына кулъязмалары бар иде. Хәзер сакланадырмы, юктырмы, анысын белмим»[2].

Димәк, Г. Тукайның хәзерге вакытта 7 әсәренең (әлегә ышанычлы дип уйланылганнары) һәм билгеле булган 34 хатының 12 төп нөсхәсе бар. Калганнары бары тик китапларда, журналларда басылган факсимилеләре яки текстлары нигезендә генә мәгълүм. Максатчан эзләнүләр, бәлки, киләчәктә бу саннарны арттырыр дип ышанасы килә.

Г. Тукайның сакланып калган фотоларының, кулъязмаларының факсимилеләре белән эшләнгән сыйфатлы матур альбом төзеп бастырылса, беренчедән, ул ядкярләр белән киң җәмәгатьчелек тә танышыр, икенчедән, шагыйрь үз кулы белән язган язмаларның «гомерләрен» озынайтуда бер игелекле гамәл булыр иде. Моның инде берникадәр тәҗрибәсе дә бар, югыйсә[3].

XI

Г. Тукайның шигырьләре хәзерге вакытка күп кенә телләргә тәрҗемә ителгән. Әмма, алар, әдип иҗатын өйрәнүдә мөһим тармакларның берсе булса да, ни кызганыч, тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Бу хакта без, нигездә, академик Әбрар Кәримуллинның (1925–2000) узган гасырда дөнья күргән тикшеренүләре буенча гына фикер йөртәбез. Ә тәрҗемәләрнең саны елдан-ел арта бара...

Г. Тукайның әсәрләрен ныклап тәрҗемә итү эше, билгеле булганча, шагыйрьнең вафатыннан соң ук башлана. Мәсәлән, Лондонда чыга торган «Рашшиан ревью» журналының 1913 елда дөнья күргән 3 нче томының беренче санында шагыйрьнең «Пар ат» шигыре В. Вильямсон тәрҗемәсендә инглизчә «To Kazan (On a Pair). Bay Abdullah Tukaev» исеме белән басылып чыга.

Шул ук елда Истамбулда нәшер ителә торган «Төрек йорды» журналының 16 нчы санында әдипнең берничә шигыре төрек телендә дөнья күрә.

Г. Тукай төрки халыклар арасында үзенең шигъри мәктәбен булдырган шагыйрь. Гәрчә 1917 елга кадәр аның әсәрләре оригиналда укылса да, соңыннан алар бу иҗатны үз телләрендә үзләштергәннәр. Мәсәлән, 1913 нче елда уйгыр эшкуары Мәхсүт Мөхиди (1885–19330 тарафыннан мөгаллим Хәйдәр Сайрани (1886–1944) ярдәмендә Торфан наһиясендәге Астана шәһәрендә беренче уйгыр дөньяви «Мәктәбе Мәхсүдия»не ача. Бу уку йортының 90 еллык бәйрәменә багышлап нәшер ителгән «Астана мәркизи башлангуч мәктәп» дигән махсус журналда (2003) язылганча, үз вакытында аның уку программасында Г. Тукайның «Туган тел» шигыре дә булган һәм ул шәкертләр тарафыннан яратып кабул ителгән.

Әдип шигырьләренең төрки халыклар арасындагы күп сандагы тәрҗемәләренең иң күбе башкорт телендә булса кирәк. Алар даими рәвештә газета-журнал битлә-

---

[1] *Саҗидә* — сүз Г. Тукайның әнисенең сеңелесе Бибисаҗидә Хәбибуллина турында бара.

[2] Рабига Әмирова-Мөхәммәтҗанова [истәлекләре]... — Б. 59–60.

[3] Ядкярләрдә — Тукай рухы = В реликвиях — душа Тукая = The Redics Keep the Soul Tukay: Татарстан Республикасы Милли музее җыелмасында татар халык шагыйре Габдулла Тукайның мемориаль тупланмасы каталогы. — Казан: Заман-Татар. кит. нәшр., 2012. — 144 б.

рендә урын ала килгән, 1936 елдан башлап аерым китап булып 9 тапкыр басылып чыккан.

Казакъ теленә тәрҗемәләр аерым китап булып җиде тапкыр нәшер ителгән. Алар арасында «Таңдамалы өлеңдери мән дастандары» (1953, гарәп хәрефләрендә), «Жезтырнақ» (1957), Жақан Сыздықов (1901–1977) тәрҗемә иткән «Таңдамалы шығармалары» (1975), Төкен Әбдирахманов (1917–1990) башкарган «Көңіл жұлдызы: Өлеңдер, дастанлар, ертегілер» (1986) бар.

Танылган үзбәк шагыйре Солтан Джура (1910–1942) утызынчы елларда ук Г. Тукай әкиятләрен тәрҗемә иткән. 1946 елда шагыйрьнең тууына 60 ел тулу уңаеннан Үзбәкстан дәүләт нәшриятында әдипнең «Танланган асарлар»ын бастырып чыгара.

1961 елда үзбәк язучысы, милләттәшебез Әсгать Мохтар (1920–1997) төзегән «Абдулла Тўқай. Танланган асарлар» җыентыгы дөнья күрә.

Төрекмән телендә «Абдылла Токай. Гошуглар хем хекаялар» (1961), кыргыз телендә «Габдулла Тукай. Тандалган чыгармалар» (1962), каракалпак телендә «Ғ. Тоқай. Шғармаларыннан» (1960), «Муңлы саз» (1981, тәрҗемәчеләре Ибраһим Йосыпов (1929–2008) һәм Бабаш Исмаилов (1926–1985), уйгыр телендә «Абдулла Тоқай. Шеирлери вә дастанлар» (1955, гарәп хәрефләрендә) дип аталган аерым китап-җыентыклар нәшер ителделәр.

Төрек галимәсе Фатма Өзкан тарафыннан әзерләнгән «Abdullah Tukay'ın Şiirleri. İnceleme-Metin-Aktarma» дигән хезмәт (1994) үзенең фәнни яктан эшләнеше белән дә, шагыйрь әсәрләренең төрек теленә тәрҗемә ителгән булулары ягыннан да кызыклы. Анда Г. Тукайның 369 шигыре урын алган. Әнкара шәһәрендә «Tukay A. Seşilmiş Eserler. Şiirler ve Makeleler» (2006), «Tukay A. Şiirler: Doğumunun 130. Yılında 130 Şiir» (2016) исемле китаплар дөнья күрә.

Әзәрбәйҗан телендә «Tukayla dörüş», «Tukay A. Samanbazarı, yaxud Yeni Kəsikbaş», «Tukay A. Seçilmiş əsərləri» (барсы да 2011 елда) дигән китаплар нәшер ителә.

Г. Тукайның шигырьләре тәрҗемәләренең күпчелеген, әлбәттә, рус телендәгеләр тәшкил итә. 1911 елның 23 нче июлендә Казан жандармерия идарәсе башлыгы шагыйрь иҗатының җинаятьчел эчтәлеген билгеләү өчен[1], аның шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итү кирәклеге турында тәкъдим кертә. Шул уңай белән губернаторның тюрколог, профессор Н. Ф. Катановка (1862–1922) шагыйрьнең «Ишан» дигән шигырен тәрҗемә итүен сорап үтенүе мәгълүм. Алга таба шагыйрьнең алты шигыре рус телендә Мәскәүдәге Шәрекъне өйрәнүче Лазарев исемендәге институт язмаларының 1914 елгы 43 нче санында бастырыла.

Шагыйрьнең «Габдулла Тукаев. Избранные стихи» дип аталган беренче русча җыентыгы 1920 елда Ташкент шәһәрендә дөнья күргән. Аны Валентин Вольпин (1891–1956) дигән шагыйрь, библиограф тәрҗемә иткән, ә «Биографический очерк» исемле кереш мәкаләне чыгышы белән Касыйм ягыннан булган Ибнеәмин Янбаев (?–1967) язган. «Разбитая надежда» исемле икенче җыентык исә Павел Радимов

[1] Гайнанова Л. Тукай жандармерия документларында (Шагыйрьнең бер җыентыгы тарихына яңа материаллар) / Л. Гайнанова // Безнең мирас. — 2019. — № 4. — Б. 40–49.

(1887–1967) тарафыннан башкарылган һәм 1921 елда бастырылган. Ул 1939 елда «Шурале» исемле тагын бер китап бастырып чыгара.

Г. Тукай әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләре, Ә. Кәримуллин билгеләгәнчә, барлыгы 36 китап тәшкил итеп, гомуми тиражы 2 миллион данәгә якынлаша. Дөрес, хәзерге вакытта бу сан инде тагын да артты һәм аларның барысын да бер мәкалә кысаларында яктырту мөмкин түгел.

Эстониянең «Сирп я вазар» («Урак һәм чүкеч») әдәби газетасының 1986 елгы 11 нче июль санында Аен Каалеп (1926–2020) тарафыннан турыдан-туры татарчадан эстон теленә тәрҗемә ителгән «Шагыйрь» дигән шигыре басыла.

Милләттәшебез Гай Сабитов (1915–1993) тәрҗемәсендә Г. Тукай әсәрләре удмурт телендә «Нылпиослы кулбуръёс» исеме белән аерым китап итеп бастырыла (1963).

Яков Ухсай (1911–1986) тарафыннан чуаш теленә тәрҗемә ителгән «Тукай Г. Шурелĕ: Юмахсем» ике тапкыр нәшер ителде (1961, 1985). Ә 2011 елда чуаш халык шагыйре Валерий Тургай әдипнең «Халăхăм, сана юратрăм» дип аталган җыентыгын бастырылды. Анда Г. Тукайның 46 шигыре урын алган.

Педагог, лексикограф Гаяз Ишмөхәммәдев (1891–1971) 1969 елда Тукайның «Шүрәле» поэмасын Мәскәүдә гарәп телендә «Әл-гауләт = Шурали» дигән исем белән аерым китап итеп басытырып чыгарды.

Тукай шигырьләре 1961 елга кадәр украин телендә төрле җыентыкларда, журналларда дөнья күреп килде. Бөек әдибебезнең тууына 75 ел тулу уңаеннан шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Павло Тычинаның (1891–1967) тырышлыгы белән Киевта әдипнең «Вибране» дигән күләмле җыентыгы нәшер ителде. Соңыннан Александр Шокола тарафыннан шагыйрьнең әсәрләре «Поезії» исеме белән дөнья күрде (1986).

2006 елда әдипнең «Шүрәле» поэмасы Татарстан китап нәшриятында татар, башкорт, үзбәк, уйгыр, казакъ, төрек, фарсы, гарәп, тажик, рус, венгр, инглиз, немец, француз, кытай телләрендә бер китап булып нәшер ителде.

Шагыйрьнең татар, рус, башкорт, чуаш, удмурт, мари телләрендә 20 шигыре тупланмасы 2011 елда басылып чыга. Шул ук елда янә «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык», «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрләре татар, рус, төрек, инглиз телләрендә дөнья күрә.

Шагыйрьнең «Су анасы» әсәре 2009 елда фин телендә, матур рәсемнәр белән аерым китап булып чыга.

2012 елда Г. Тукай әсәрләре фарсы телендә дә «Ашенайи әз дийар-е ашена. Монтәхеб-е асар Абдуллаһ Тукай шаер-е милли-йе Татарестан» («Таныш төбәктән таныш тавыш. Татарстан халык шагыйре Габдулла Тукай әсәрләренең сайланма җыентыгы») исеме белән аерым җыентык булып дөнья күрә[1]. Күләм ягыннан ул 224 бит тәшкил итә. Хезмәт Иран Ислам Җөмһүриятенең Казандагы Баш консуллыгының мәдәният буенча Атташаты тарафыннан әзерләнә. Җыентыкта шагыйрьнең 108

[1] Бу хакта тулырак: Исламов Р. Тукай — фарсы телендә / Р. Исламов // Тулпар. — 2013. — № 5. — Б. 20–21.

шигыре һәм «Исемдә калганнар» («Ан че әз худ бе йад дарәм (бе нәсер)») дигән автобиографик әсәре урын алган, аларга рәсемнәр ясалган.

Әдипнең шигырьләре грузин, молдован, белорус, литва, латыш, авар, осетин, даргин, лак, иврит, балкар һ. б. телләрдә газета-журналларда, төрле җыентыкларда басылган. Ә. Кәримуллин язганча, совет хакимияте елларында Г. Тукай әсәрләре илебезнең 26 халкы телләрендә дөнья күргән, ә аерым китап булып 13 телдә нәшер ителгән.

Гомумән, Г. Тукай әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә итү киләчәктә дә максатчан башкарыласы зарури эшләрнең берсе булып кала. Шуңа күрә бу мәсьәләгә җитди игътибар итү сорала.

XII

Г. Тукай әсәрләрен барлау-туплау, аларны текстологик яктан эшкәртеп бастыру өлкәсендә башкарылган эшләргә килгәндә исә, аның өч томлы «Әсәрләре»н (1929–1931), «Сайланма әсәрләре»н (1938), «Академик басма»сын (I т., 1943, II т., 1948), «Сайланма әсәрләр»ен (1946), дүрт томлы «Әсәрләр»ен (1955–1956), дүрт һәм биш томлы «Әсәрләр»ен (1975–1977, 1985–1986), «Сайланма әсәрләр»е (2003, 2010), ике томлы «Сайланма әсәрләр»е (2006), алты томлы «Әсәрләр»енең академик басмасын (2011–2016) күрсәтергә мөмкин.

Шагыйрьнең 1914 елда нәшер ителгән «Мәҗмугаи асар»е[1] кирилл хәрефләрендә, 1910 елда дөнья күргән «Күңелле сәхифәләр»[2] китабы гамәлдәге татар графикасында факсимилесе белән бастырылды.

Татар әдәбияты гыйлемендә беренче тәҗрибә буларак, ниһаять, Г. Тукайның «Энциклопедия»се (2016) дә басылып чыкты[3].

Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗат мирасын өйрәнү юнәлешендә хәзерге вакытка шактый казанышларыбыз бар. Аерым алганда, болар: Г. Халитнең «Халык шагыйре Тукай» (1939), «Габдулла Тукай и татарское литературное движение начала XX века» (1956), «Тукай үткән юл (Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында очерк)» (1962), «Тукай и его современники (в борьбе за реализм и народность татарской литературы)» (1966), Я. Агишев һәм И. Пехтелевнең татар һәм рус телләрендә «Габдулла Тукай (Биографик очерк)» (1946), Я. Агишевнең «Габдулла Тукай — патриот» (1942), «Творчество Габдуллы Тукая: (Общественно-политические мотивы)» (1948, 1954), «Халык шагыйре Габдулла Тукай» (1956), «Народный поэт Г. Тукай» (1961), «Халык шагыйре Г. Тукай: (Тууына 75 ел тулуга карата» (1961), И. Пехтелевнең «Эстетические идеи в поэзии Г. Тукая» (1946), «Пушкин-Лермонтов-Тукай» (1949), «Литература и время: Статьи и очерки» (1964), «Тукай и русская литература» (1966), И. Нуруллинның «Тукай эстетикасы турында мәкаләләр» (1956), «Тукай иҗаты: (Беренче рус революциясе чоры)» (1964), «Тукай

[1] Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре / Төз., текст., иск., аңл. әзерл. Г. Төхвәтова; фәнни мөх. Э. Галимҗанова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. — 510 б.

[2] Тукай Г. Күңелле сәхифәләр: балалар өчен шигырьләр һәм чәчмә мәсәл / Төз. Г. Төхвәтова / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2022. — 39 б.

[3] Галимуллин Ф. Энциклопедияле Тукаебыз / Ф. Галимуллин // Мәдәни җомга. — 2017. — 21 апр.

турында хикәяләр» (1966), «Поэт из деревни Кырлай: Рассказы о Габдулле Тукае» (1967), «Напевы мятежного саза: Повесть о жизни и творчестве Г. Тукай» (1981, 1986), М. Галинең «Шагыйрь баскан эзләрдән» (1957), Р. Башкуровның «Тукай һәм рус әдәбияты. Шагыйрьнең тәрҗемәләре турында» (1958), Ә. Исхакның «Тукайның шигъри осталыгы» (1963), Й. Туишевның «Общественно-педагогическая деятельность Габдуллы Тукая» (1963), Р. Ганиеваның «Сатирическое творчество Г. Тукая» (1964), «Шагыйрьнең рухи дөньясы: («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан)» (2002), Р. Башкуров белән В. Воздвежинскийның татар һәм рус телләрендә «Һәрвакыт халык йөрәгендә: (Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлы)» (1966), З. Ишмөхәммәтовның «Тукай атеизмы» (1971), С. Хәкимнең «Габдулла Тукай: Шагыйрьгә 90 яшь тулу уңае белән» (1975), Н. Лаисовның «Лирика Тукая» (1976), «Габдулла Тукай (1886–1913) (Краткий очерк жизни и творчества. К 100-летию со дня рождения)» (1985), З. Рәсүлованың «Тукай эзләреннән» (1985), Ф. Әгъзамовның «Тукай — журналист» (1986), Р. Нәфыйговның «Тукай и его окружение» (1986), «Наш Тукай: Новые страницы из жизни поэта» (1998), С. Поварисовның «Мәктәптә Г. Тукай әсәрләре телен өйрәнү» (1992), «Сравнения в поэтике Г. Тукая: Учебно-методическое пособие» (2004), О. Кадыйровның «Стихотворения «Русский язык» И. С. Тургенева и «Туган тел» («Родной язык») Г. Тукая» (2004), Р. Исхакова-Вамбаның «Тукай и татарская музыка» (1997), З. Шәйхелисламовның «Аңлыем дип шагыйрь җанын... (Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай)» (2001), Н. Гафиятуллинаның «XX гасыр татар шигъриятендә Тукай» (2002), Х. Салихҗанның «А. Пушкин һәм Г. Тукай иҗатында Коръән аһәңнәре» (2002), Н. Хисамовның «Тукайны төшенү юлында («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә материаллар)» (2003), З. Рәмиевнең «Тукай һәм замандаш әдипләр («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә материаллар)» (2004), К. Габбасованың «Изображение природы в поэзии Габдуллы Тукая» (2010), М. Фридерихнең «Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы» (2011), Р. Исламовның «Тукайны өйрәнүдә яңа чыганаклар: фәнни мәкаләләр» (2016) дигән хезмәтләре.

С. Сафуанов «Туҡай Башҡортостанда» (1966), Ә. Алиева һәм Ф. Ибраһимова «Тукай Г. Тормыш һәм иҗат елъязмасы» (2003), З. Мөхәммәтшин «Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай» (2006), Р. Акъегет «Тукай...: Дөнья халыклары Тукай турында» (2006) дигән хезмәтләр төзеп бастыра.

К. Галиуллин һәм Р. Кәримуллина тарафыннан ике китапта «Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек-Габдулла Тукай: Язык поэзии: Словарь» (2009) төзелә.

Г. Тукай әсәрләренең тел үзенчәлекләрен, шагыйрьнең идея-эстетик һәм әдәби-тәнкыйди, педагогик карашлары, рус әдәбиятыннан тәрҗемәләре, аның иҗатында сатира, лирикасы һәм башка проблемалар турында Г. Әмиров (1968) докторлык, И. Нуруллин (1953), Й. Туишев (1954), Р. Башкуров (1958), Р. Ганиева (1964), Й. Вәлитова (1966), Н. Лаисов (1970), Л. Җамалетдинов (1993), З. Шәйхисламов (1999), Н. Гафиятуллина (2002), Д. Абдуллина (2005), К. Габбасова (2009) кандидатлык диссертацияләре яклана.

Шагыйрьнең юбилейлары уңаеннан гыйльми конференцияләр үткәрелә, укулар оештырыла. Аларның материаллары, мәсәлән, «Габдулла Тукай: Шагыйрьнең туу-

ына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары» (1948), «Межвузовская студенческая научная конференция, посвященная 75-летию со дня рождения Г. Тукая: кр. содер. докл.» (1961), «Габдулла Тукай» [Материалы науч. конф., посв. 80-летию со дня рожд.] (1968), «Габдулла Тукай: материалы науч. конф. и юбил. торжеств, посв. 90-летию со дня рожд. поэта» (1979), «Поэт свободы и правды: материалы Всесоюз. науч. конф. юбил. торжеств, посв. 100-летию со дня рожд. Габдуллы Тукая» (1990), «Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конф. материаллары (25 апрель, 2011 ел)» (2011), «Тукаевские чтения = Тукай укулары» (Апрель, 1999 г.) (1999, 2000), «Творчество Тукая в контексте евразийской культуры» (2002) дигән аерым җыентыклар итеп бастырыла.

Әдипкә багышланган «Габдулла Тукай. Фотоальбом» (1966, төз. С. Исәнбаев), «Габдулла Тукай: Фотоальбом» (1986, төз.: З. Бәширов һәм М. Мәһдиев) дигән өч фотоальбом нәшер ителә.

Г. Тукайның әсәрләрен бастыруда булгалаган кайбер хаталар, төгәлсезлекләр дә киң җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калмый. Шагыйрь үзе дә «Шүрәле» имзасы белән 1907 елда ук «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер»[1] дигән мәкалә язып чыга, югыйсә. Мәсәлән, басмаларда, матбугатта «Туган тел» шигыренең дүртенче куплеты еш кына төшереп калдырылды[2]. Кайвакыт аерым шигырьләрне Тукайныкы дип тәкъдим итү очраклары күзәтелә. Бу уңай белән әдәбият галиме Нил Юзиев (1931–1996) шулай язды: «XX гасыр башы татар шигърияте белән якыннан таныш булганнар гына аның Тукай әсәре түгеллеген, шул чорда яшәп иҗат иткән икенче бер шагыйрьнең әсәре икәнлеген белә»[3]. Журналист Ирек Бәдретдинов үзенең мәкаләсендә шигырь текстларын үзгәртеп бастыру күренешләрен конкрет мисаллар белән күрсәтә[4]. Г. Тукай әсәрләренең алты томлык академик басмасы чыгу уңае белән Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуровның «Дәүләткә торырлык өтер: Тукайның күптомлыкларын чыгаруда кайчан камиллеккә ирешебез?»[5] дигән күләмле мәкаләсе белән танышуны укучыларның үзләренә калдырам.

XIII

Г. Тукайны өйрәнүдә бер мөһим моментка игътибар итәргә кирәк: «Революциягә кадәрге истәлекләр шагыйрьгә кагылышлы факт, вакыйга һәм мәгълүматларның нигезле һәм ышанычлы булулары белән аерылып торалар… Революциядән соңгы истәлекләргә килгәндә исә, шагыйрьнең олылыгын раслау, аны күтәрү һәм мактау җитәрлек. Әмма бу истәлекләрнең күбесендә Тукай бизәлгән, ул «грим сөртелгән» кыяфәттә күз алдына килеп баса»[6]. Шуңа күрә, 1944 елда Г. Тукай турында истә-

[1] Шүрәле. Тәнкыйть — кирәкле шәйдер / Шүрәле // Әл-ислах. — 1907. — 1 гыйнв.

[2] Кәримов М. Тукайны рәнҗетмик / М. Кәримов // Соц. Татарстан. — 1990. — 7 окт.

[3] Юзиев Н. Тукай шигырьләреме? / Н. Юзиев // Ватаным Татарстан. — 1994. — 15 июль.

[4] Бәдретдинов И. Бозмыйк Тукайны! / И. Бәдретдинов // Шәһри Казан. — 2013. — 15 гыйнв.

[5] Мансуров З. Дәүләткә торырлык өтер: Тукайның күптомлыкларын чыгаруда кайчан камиллеккә ирешербез? / З. Мансуров // Мәд. җомга. — 2011. — 18, 25 нояб.

[6] Нуруллин И. Хатирәләр турында берничә сүз / И. Нуруллин, Р. Якупов // Тукай турында хатирәләр... — Б. 4.

лекләр туплаганда, аларның кайберләрен, дөреслеккә туры килми дип, авторларына кире кайтару очраклары да булгалаган[1].

Шулай да, моңа кадәр шагыйрьне хаким идеология күрсәтмәсе һәм юнәлтмәсе буенча гына өйрәнү өстенлек итте. Мәсәлән, аңардан атеист[2], педагог[3], ахыр чиктә ниндидер ревоюцион-демократ[4] ясарга тырышылды. Шуңа күрә, алман галиме Михаэль Фридерих образлы язганча, «Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле һәм иҗаты һәр-кем үз максатында файдалану өчен «ташын» кубарып алган таш чыгару карьерын хәтерләтә»[5].

Я. Агишев тарафыннан 1940 елның 11 мартында Р. Хәйруллиннан (?–?) сөйләтеп язып алынган истәлектә укыйбыз (вакыйга Уральскида бара): «1905 нче ел восстаниесе алдында Тукай бу восстаниенең буласын ничектер белә иде, әллә сизенә иде. Восстание көнне халык белән бергә Тукай белән без дә урамга чыктык һәм читтән генә карап йөрдек. Бервакыт казаклар демнострацияне тарата, ә халык кача башлады. Без дә Тукай белән качтык. Бик тыгыз килгәч, Функ дигән сәүдәгәрнең магазины баскычы астына качып, урам тынычланганчы шунда тордык. 1905 нче ел восстание бастырылгач та, без (мин һәм берничә приказчик) Тукайның бүлмәсенә йөреп тордык. Кичләрен утыра, сөйләшә идек. Восстание бастырылуга карамастан, Тукай тагын да революция булуына ышана иде. Ул: «Байлар бетәргә тиеш», — ди иде. Тукай бер көн безгә мондый тәкъдим ясады: «Без, — диде Тукай, — 50 шәр тиенләп булса да акча җыйныйк, шул акчага револьверлар алыйк, кирәк булыр»[6].

Яучы К. Әмиригә 1946 елның 19 февралендә Габдулла Гаделшин (?–?) исемле кеше шулай сөйли: «Болай сөйләшеп утырганда да әдәби мәсьәләләр белән бергә сәяси темаларга сөйләп йөри башлады һәм кайбер вакытны, шәкертләр иптәшләре белән бергә җыелудан файдаланып, сөйләшеп утыруны сабрания төсенә кертеп җи-

---

[1] Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге: 9 ф., 4 тасв., 30, 31 сак. берәм.

[2] [2] Ишмөхәммәтов З. А. Тукай атеизмы / З. А. Ишмөхәммәтов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. — 72 б.

[3] Ибраһимов Ф. Габдулла Тукай педагог булганмы? / Ф. Ибраһимов // Совет мәктәбе. — 1965. — № 5. — Б. 57–58; Исламов Ф. Габдулла Тукай — педагог / Ф. Исламов // Яңа юл. — 1986. — 10 июль; Туишев Ю. А. Общественно-педагогическая деятельность Габдуллы Тукая / Ю. А. Туишев. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1963. — 111 с.

[4] Кальтиев А. М. Революция мәктәбендә / А. М. Кальтиев // Соц. Татарстан. — 1961. — 21 апр.; Нафигов Р. И. Тукай и его окружение / Р. И. Нафигов. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. — 208 с.; *Его же*. Наш Тукай: Новые страницы из жизни Поэта / Р. И. Нафигов. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1998. — 168 с.

[5] Фридерих М. Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы / М. Фридерих / Пер. с нем. И. А. Гилязова. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. — С. 16.

[6] Рәхмәтулла Хәйрулла улы Хәйруллинның Габдулла Тукай турында истәлекләре // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 131.

бәрә иде дә, тәрәзәләргә юрганнар каплап, ривәлүтсиәнирләрнең көрәше, байларның эксплуататсиәсе турында сөйли иде»[1].

Г. Тукайның ниндидер фиркаләргә мөнәсәбәте мәсьәләсенә килгәндә исә, Уральскида ук иң якын дусты булган Г. Кариев ул хакта болай яза: «Тукаев шул кышны дүрт ай чамасы сул партияләргә ихлас куеп йөрде, вә шуның тәэсире илә язылган, сулрак рухта булган берничә шигыре «Тавыш»[2] газетасында басылды.

Камил Мотыйгыйның китап магазины[3] ябылгач, мин китапларын алып «Казан» нумирларында торып сатадыр идем. Табыш Габдулла әфәнде илә уртак иде. Әлбәттә, китап сатар өчен разрешение-фәләнем юк иде һәм аның кирәк икәнен дә белмидер идем. Бераз вакыт сату иткәч, разрешением булмаган өчен, палитсиә китапларымны алып китте. Үземне бер кич частьтә[4] кундырдылар. Шуннан соң Тукаев партия кешеләре берлә араны тәмам өзде, икебез дә тәүбә иттек»[5].

Г. Тукай 1912 елның язында Петербургка баргач, ул вакытта медицина институты студенты, киләчәктә сәяси һәм җәмәгать эшлеклесе, башкорт халкының милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе булачак Ш. Манатовка үзенең социализмга карашларын шулай аңлата: «Шулай да сатсиализмны тормышка татбикъ[6] кылган ган тәкъдирдә дә инсан сәгадәттә[7] яшәр дип инана алмыйм. Безнең өчен иң тугры вә иң файдалы юл — милли булу, урта юл илә барудыр», — диде. Бу хакта арамызда бераз сүзләр булып үткәч, шагыйрь көлемсерәп: «Мин үзем сатсиалист түгелмен, шуның өчен дә ул мәсләктәге кешеләр хакында артык сүз сөйли алмыйм. Фәкать, һәркем үз мәсләген гүзәл аңлап, чыннан халыкка, ватанга хезмәт итсен», — диде»[8].

Г. Тукайның дингә карашы турында сүзне артык озынга сузмыйча, әүвәл замандашы Ш. Шәрәфнең истәлегенә игътибарны юнәлтик: «Син милли шагыйрь бит, дини хисләргә дә шул дәрәҗәдә әһәмият бирәсеңме?» — дип сорагач, Тукай: «Дөньяда динсез бер милләт тә юк, бөтен милләтләр динле булганда, без генә динсез булып кала алмамыз. Халкымызда миллиятьләре сакланган мөддәттә[9], диннәре дә сакланачагына ышанам. Миллиятьләрен яхшы саклый алуларында гына азрак

---

[1] Габдулла Тукай турында Габдулла Гаделшин иптәшнең истә калганнары // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 162–163.

[2] *«Тавыш»* — Мөхәммәдгариф Биккинин (?–?) һәм Хөсәен Әбүзәрев (?–1917) наширлегендә һәм мөхәррирлегендә Казанда 1907 елның 23 апреленнән 5 июненә кадәр нәшер ителгән атналык татарча газета. Социалист-революционерлар фиркасенең татар төркеме органы булган «Таң йолдызы» газетасының дәвамы.

[3] *Китап магазины* –ул китап кибете «Прогресс» дип аталган.

[4] *Часть* — полиция бүлеге.

[5] Кариев Г. Габдулла Тукайның Уральскидагы тормышы / Г. Кариев // Мәктәп. — 1913. — № 4. — Б. 105.

[6] *Татбикъ* — яраштыру, яраклаштыру.

[7] *Сәгадәт* — бәхет, рәхәтлек.

[8] Әхмәтҗанов Ш. Искә төшерү (Габдулла Тукаев Петербургта) / Ш. Әхмәтҗанов // Сибирия. 1913. — 26 май.

[9] *Мөддәттә* — вакытта.

шөбһәм бар. Мин һәрвакыт дин берлә миллиятънең һәр икәвесенә тигез әһәмият бирү тарафындамын», — диде»[1].

Киләчәктә сәясәтче, тарихчы, тюрколог булып танылачак Әхмәтзәки Вәлидигә (1890–1970) болай дигән: «Ишаннарны инде бик күп сүктек. Син ни әйтсәң дә әйтерсең, әмма мин соңгы вакытта яхшы ишаннарда халыкның рухы илә бер мөнәсәбәт күргәндәй булам»[2].

Гомеренең ахырында ул үзенең язган әсәрләренә дә тәнкыйди карый башлый. Бу хакта янә Ш. Шәрәф истәлегенә мөрәҗәгать итик. Ул шулай яза: «Тукай берлә озак утырышуымның иң соңгы, вафатыннан кырык көн кадәр мөкаддәм[3], «Мәгариф» көтепханәсе тарафыннан булган сорау буенча, үзенең бөтен язган шигырьләрен бер тәртипкә тезеп, бәгъзы йирләрен төзәтеп, «Мәҗмугаи асәр» бастырырга хәзерләнгән вакыты иде. Шул вакыт бәгъзы шигырьләрен бозып, төзәтеп: *«Яшьлек берлә әллә нәрсәләр язылган, кайсыбер шигырьләремне күрәсем дә килми, халыкның дини яки милли шогурларына[4] тукына торган нәрсәләрне бер дә яратмыйм, шунарга күрә «Исабәт»[5] чыгаручыга каршы да бер шигырь язып ташлаган идем», — диде»*[6].

Г. Тукай балалар өчен шигырьләр язган икән, анда укырга, белем алырга, эшкә өйрәнергә өндәүләр яңгырый икән, «Яңа кыйраәт», «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән китаплар төзеп бастырган икән — бу әле ул чын мәгънәсендә педагог булган, педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнгән дигән сүз түгел. Әгәр без мондый аңлау белән гамәл кылсак, XX гасыр башындагы татар «педагогларының» санына-исәбенә чыгу мөмкин булмас иде.

Гомумән, югарыда әйтелгәннәр турында сүз барганда, профессор И. Нуруллинның моннан байтак еллар элек язылган, әмма актуальлекләрен хәзерге вакытта да югалтмаган кайбер хезмәтләренә игътибарны юнәлтү урынлы булыр иде[7].

Ниһаять, биредә тагын бер четерекле мәсьәлә хакында беркадәр аңлатма бирү сорала. 1917 елга кадәр һәм аннан соң да Г. Тукай турында дөнья күргән истәлекләрдә, мәкаләләрдә шагыйрьнең яшьли авырып вафат булуы хакында төрле фикерләр әйтелгән. Берәүләр аны комсыз наширләр талады дисә, икенчеләр исә аның ва-

---

[1] Шәрәф Ш. Габдулла Тукай хакында бәгъзы хатирәләрем (Вафатына биш ел тулу мөнәсәбәтилә искә төшерү) / Ш. Шәрәф // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 291.

[2] Әхмәтзәки. Тукаев илә сохбәтләремнең хатирәсе // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 251.

[3] *Мөкаддәм* — элек.

[4] *Шогурларына* — аңнарына.

[5] *«Исабәт»* — («Хаклыкка ирешү»), Галиәсгар Гафуров-Чыгътайның (1867–1948) Казанда 1910 елда нәшер ителеп, татар җәмәгатьчелегендә зур шау-шу куптарган публицистик китабы.

[6] Шәрәф Ш. Габдулла Тукай хакында бәгъзы хатирәләрем (Вафатына биш ел тулу мөнәсәбәтилә искә төшерү)... — Б.

[7] Нуруллин И. Шагыйрьне өйрәнү юлында / И. Нуруллин // Казан утлары. — 1966. — № 3. — Б. 120–127; *Аныкы ук*. Ближе к истине!: Критические заметки на полях одной книги / И. Нуруллин // Сов. Татария. — 1986. — 16 нояб.

кытсыз әҗәлендә байларны гаепләде, хәтта халык адресына да «таш атты». Әлбәттә, аңа ярдәм итмәгәннәр түгел, иткәннәр. Бу турыда истәлекләрдә дә ачык әйтелгән. Мәсәлән, фабрикант Х. Акчуринның аны үзенә чакырып китереп кунак итүе күптән мәгълүм факт. Шагыйрьне Петербургка табибка күрсәтү максатыннан оештырылган сәфәрнең матди ягын сәүдәгәрләр Салих Гобәйдуллин (1867–1935), Мөхәммәтсадыйк Галикәев (1847–1919), Сөләйман Аитов (1862–1922), нашир Ә. Хәсәни, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Баруди күтәрешкәне мәгълүм[1]. Г. Тукайның якын дусларыннан берсе Х. Зәбири бу мәсьәләгә ачыклык кертү уңае белән матбугатта 1914 елда ук чыгыш ясый[2]. Ул Тукайның Казанда мохтаҗлыкта яшәвеннән зарланганны күреп Оренбургка «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатыйх Кәримигә ярдәм итүне сорап 1908 елның 7 мартында хат яза. Шул ук елның 15 мартында «Ашау, эчү, фатир үземнән булып 40 сум жалуния бирелер» дигән уңай җавап та ала[3]. Җәй көннәрендә аның Оренбургка бару нияте булган. Мәсәлән, Г. Дәүләтшингә шул елның 9 июнендә язган хатында шундый юллар бар: «Ошбу көннәрдә Оренбургка хат яздым. Анда барсам, баргач та акчаңызны йибәрермен»[4]. 23 июньдә дә Ф. Әмирханга язган хатында да үзенең шул ниятен белдереп, киңәш сорый: «Оренбургка Фатих Кәримев чакырган иде. Анда барсам, бәлки, үземә мөгайян[5] эш эш булуы һәм серьёзный кешеләр тирәсе файдалы булыр иде, дим. Нишлим? Барыйм микән?»[6].

Әмма Тукай, Х. Зәбири язганча, «...Фатыйх Әмирхан һәм Вафа Бәхтияровлар берлә бергә бик хозур итеп дачада торачакларын төшенеп, шул кызыклардан айрыласы килмәвен сәбәп итеп Оренбургка бармаска була». Бу төп сәбәп булганмы, юкмы, анысы икенче мәсьәлә.

Журналист Габдерахман Фәхретдинов (1887–1937) язмасында да кызыклы факт теркәлгән. Алтын приискалары хуҗасы, эшкуар Шакир Рәмиев[7] Тукайны үз хисабына Кырымга җибәрергә карар кылып, Казандагы бер кешедән бу тәкъдимне Тукайга җиткерүне сораган[8]. Билгеле булганча, ул кеше шагыйрьнең якын дусларыннан берсе Габдулла Гыйсмәти була. 1912 елның апрель башларында «Свет» номерларында бу хакта ике арада булган сөйләшү турында ул шулай яза: «Кырымга бару-

---

[1] Гыйсмәти Г. Ике елдан соң бер хисап (Г. Тукаев хатирәсе) / Г. Гыйсмәти // Йолдыз. — 1914. — 2 апр.

[2] Зәбири Х. Кечкенә бер тасхих (Тукаев хәятенә гаид) / Х. Зәбири // Вакыт. — 1914. — 19 апр.

[3] Таҗетдинов Н. Яңа табылган бер хат турында / Н. Таҗетдинов // Совет әдәбияты. — 1964. — № 1. — Б. 138–140.

[4] Габдрахман Дәүләтшингә // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 85.

[5] *Мөгайян* — билгеләнгән.

[6] Фатих Әмирханга // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — Б. 87.

[7] *Шакир Рәмиев* — Мөхәммәдшакир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев (1857–1914), сәүдәгәр, алтын приискалары хуҗаларыннан берсе, җәмәгать эшлеклесе, иганәче.

[8] Фәхретдинов Г. [Миңа мәгълүм] // Вакыт. — 1914. — 19 апр.

ның яраганлыгы исбат ителде. Моңа күндек». Әмма шагыйрь аңа шундый шарт куя: «Син барсаң гына ул якка барам, башка кеше белән китү ихтималым юк»[1].

Г. Гыйсмәтинең язуына күрә шагыйрьнең «иганә рәвешендә акча алуны яратмаганлыгы» да мәгълүм. Кыскасы, бу четерекле мәсьәлә хакында фикер йөрткәндә кайбер даһи иҗатчыларның яшәү рәвешен, холкын да исәпкә алырга кирәк.

«Шәһри Казан» газетасының 2001 елгы 13 июль санында тарих фәннәре кандидаты Марат Фәйзрахмановның «Тукай мәхәббәте» дигән мәкаләсе басылып чыга. Анда шулай язылган: «Габдулла Тукайның Зәйтүнәне өзелеп яратуы, ниһаять, кызның әти-әнисенә дә билгеле була. Зәйтүнәнең әнисе турыдан-туры бу турыда ишетү белән: «Баланы авылда калдырасыбыз юк. Әнә, Уфага Тукай Мәҗит Гафури янына килгән, ала диген, ярәштек диген, ал да кайт, атасы!» — дип эшне бик каты һәм кыска тоткан» (!). Беренчедән, Г. Тукайның Уфага 1912 елда килүе мәгълүм. Икенчедән, Зәйтүнәгә алты яшь вакытта, ягъни 1899 елда ук әтисе Хәйдәр абзый вафат була[2]. Мәкалә белән танышуны дәвам итәбез: «Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң Зәйтүнә Бишенде авылы мәдрәсәсенә мөгаллимә итеп билгеләнә. Әтисе аны Уфага Тукайга ярәшергә алып бара. Ләкин бу көннәрдә шагыйрьнең кабат авырып китүе Зәйтүнәнең әтисенә бу мәсьәләне хәл итәргә мөмкинлек бирми. Зәйтүнә кабат мәдрәсәгә, Бишенде авылына (аның кайсы төбәктә икәнлеге әйтелми — *Р. И.*) кайтып, мөгаллимә хезмәтен башкара тора. Габдулла, ни сәбәптәндер, терелгәч, Бишенде авылына Зәйтүнәне кияүгә чыгарга сорарга килми». Моны бары тик шагыйрьнең үз сүзләре белән шәрехләү урынлы булыр. Мондый хәлнең «булганы юктыр гомер...». Алга таба тагын да сәеррәк мәгълүмат китерелә: «Соңыннан билгеле булганча, Зәйтүнә кияүгә чыккач, ул онытылып Әминәне ярата башлый. Ул... Әминәнең онытып калдырган перчаткаларын үбә, редакциядә күңелләре йомшап, елап җибәргәндәй була. Ә үзе аның белән очрашудан качып йөри». Зәйтүнәнең улы, язучы А. Расих әнисе белән әтисенең өйләнешү вакыйгасы турында шулай яза: «Туй мәҗлесләре бик тантаналы рәвештә уза. Ул [мең тугыз йөз] ундүртенче елның жиденче февралендә була, унөченче февральдә әни кияү йортына күчеп китә»[3]. З. Мәүлүдованың истәлек дәфтәрендә моны ныгыта торган өстәмә дәлил теркәлгән: «1914 сәнә, июнь башлары, минем никахыма да 4 ай була инде»[4].

Башкортстан Республикасы Туймазы районының Югары Бишенде авылы кешесе, укытучы Әнвәр Низаметдинов «Казан утлары» журналының 1996 елгы 4 санында бастырган мәкаләсендә шулай яза: «Менә шушы авылда (Каран Бишенде) 1901 нче елда кирпечтән салынган мәдрәсә ачыла. Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, авыл бае Зиннәтулла улы Мөхәммәтша, аның хуҗасы була. Үзе белән бергә укыган шәкертләрдән мөгаллимнәр чакырта, араларында Зөләйха (!) исемле мөгаллимә дә була»[5].

---

[1] Гыйсмәти Г. Ике елдан соң бер хисап (Г. Тукаев хатирәсе) / Г. Гыйсмәти // Йолдыз. — 1914. — 2 апр.

[2] Расих А. Ишан оныгы... — Б. 82.

[3] Расих А. Ишан оныгы... — Б. 139.

[4] Расих А. Ишан оныгы... — Б. 141.

[5] Низаметдинов Ә. Габдулла Тукайның мәхәббәте / Ә. Низаметдинов // Казан утлары. — 1996. — № 4. — Б. 148.

Ләкин язгы бер көндә «Челтерәп кыңгырау тавышы ишетелә һәм ат җигелгән кошовка капка төбенә килеп туктый». Аннан кыска сакаллы бер кеше төшә. Ул «Зөләйханы Уфага алып киткән икән. Аны Габдулла Тукайга ярәшкән булганнар, ди. ...Шулай итеп, Мөхәммәтша мулла дүртенче абыстайдан колак какты, күзе бик тә кызган иде. Ә чынында менә ничек булган: Зөләйханың әнисе бу турыда ишетү белән: «Баланы авылда калдырасыбыз юк. Әнә, Тукай Гафури янына килгән, ала диген, ярәштек диген, ал да кайт атасы! — дип, эшне бик каты һәм кыска тоткан»[1].

Мәкаләдә Г. Тукайның тагын бер «мәхәббәте» бәян ителә: «Ул... Әминәнең онытып калдырган перчаткаларын үбә, редакциядә күңелләре йомшап, җылап җибәрердәй була. Ә үзе аның белән очаршудан качып йөри... Әминә авыл укытучысы булып Казаннан китә. Габдулла Тукай нык кайгыра, уйлана, ни эшләргә белми... үз-үзенә кул салмакчы була»[2].

Журналист Замир Низаметдинов (1948–2017) «Шәһри Казан» газетасының 2006 елгы 14 апрель санында дөнья күргән «Тукай — мәңгелек һәм үлемсез» исемле мәкаләсендә вакыйга Югары Бишенде авылына күчерелә. Автор бу мәгълүматны Югары Бишенде авылы кешесе Әнвәр Низаметдиновтан ишетүен белдерә[3].

2012 елда «Кайда да йөрәктә: Татарстаннан читтә яшәүче татар әдипләренең иҗаты» дигән җыентык басылып чыкты. Язучы Мирсәй Гарифның андагы «Башкортстанда Тукай эзләре» дигән язмада сүз шагыйрьнең хәзерге Башкортстан Республикасының Чакмагыш районындагы Аблай авылына, Бәләбәй якларына сәфәрләре турында бара. Хосусан, анда шундый мәгълүмат белән танышабыз: «Габдулла Казанга кайткач, иптәшләреннән сорашып, Зәйтүнәнең инде ярты елдан артык Бишенде мәдрәсәсендә мөгаллимә булып эшләвен белә. Их дөнья, аның сөйгәне шагыйрьдән һаман ераклаша. Ул инде эш эзләп Бәләбәй өязенә дә барып җиткән. Тукай, географик карта алып, Бәләбәй шәһәренең Аксаково станциясеннән унөч кенә чакрымда урнашканлыгын белә. Ә өяздән Бишендегә тагын туксан чакрым барасы юл икән әле»[4]. Без тарихчы мәкаләсендә «Зәйтүнә Бишенде авылы мәдрәсәсенә мөгаллимә итеп билгеләнә» дип укыган идек бит, ә биредә ул Бәләбәй өязе буйлап үзе эш эзләп йөргәнлеге (!?) ачыклана. Автор тагын озак еллар мәктәп директоры, аннары авыл советы рәисе булып эшләгән Сылу Якупова-Булатованың әнисеннән ишеткәннәрне дә китерә: «Сылу апаның сөйләвенчә, аның әнисен Зәйтүнә мөгаллимә укыткан. Кызлар җыеп, ул дин дәресләре генә бирмәгән, ә гомуми яшәеш фәлсәфәсен дә сеңдерергә тырышкан. Табигать кочагын алып чыгып, күп кенә мәгълүматлар биргән, файдалы үләннәр эзләгәннәр, чишмәләрне төзекләндергәннәр. Әлбәттә, кыз балалар апаларыннан кул эшләренә дә өйрәнгәннәр, мөгаллимәнең матур итеп үзе теккән күлмәкләренә хәйран калып, сокланып йөргәннәр»[5].

---

[1] Низаметдинов Ә. Күрс. хезм. — Б. 148.

[2] Низаметдинов Ә. Күрс. хезм. — Б. 149.

[3] Низаметдинов З. Тукай — мәңгелек һәм үлемсез / З. Низаметдинов // Шәһри Казан. — 2006. — 14 апр.

[4] Гариф М. Башкортстанда Тукай эзләре / М. Гариф // Кайда да йөрәктә: Татарстаннан читтә яшәүче татар әдипләренең иҗаты / төз.: И. М. Ибраһимов, Р. Г. Ханнанов; кереш сүз авт. Р. З. Закиров. — Казан, 2012. — Б. 30–31.

[5] Гариф М. Күрс. хзем. — Б. 36.

Моны ул «Мәңгелек мәхәббәт (Тукай белән Зәйтүнә хикәяте)» дигән китабында да кабатлый. Ләкин анда кайбер «кәттәрәк» өстәмәләр дә күзәтелә. Мәсәлән, мәдрәсә хуҗасы, мул тормышта яшәүче Мөхәммәтша мулла «Мал-туар күп тота. Атлар, сыерлар, дуңгызлар — берничә абзар кош-корт та бар»[1].

Чыганаклардан күренгәнчә, З. Мәүлүдова ул якларда бөтенләй булмаган.

М. Гариф Аблай авылында Нәфига Габдуллинадан Г. Тукайның шушы авылга килүе турында сөйләгәнен ишеткән һәм «документаль рәвештә хат белән җибәрүен»[2] үтенгән. Хаттагы «Безнең Аблай авылынада 1913 елда Габдулла Тукай булган»[3] дигән җөмләне укыгач та, бу хакта алга таба сүз алып баруның кирәге юклыгы аңлашыла.

Матбугатта басылган мәкаләләрдән күренгәнчә, Г. Тукай Аблай авылында бер тапкыр гына булганга охшамаган. Флюра Әхмәдуллина исемле автор шулай яза: «Башкортстандагы Аблай авылына кымыз белән дәвалану ниятеннән Габдулла Тукай килә, урта хәлле крестьян Әгъләм абзыйлар гаиләсендә яши. Кымыз бияләре исә авылыбыздан биш чакрым ераклыктагы «Якты күл»дә була. Авыл старостасы безнең әтигә Габдулла Тукайны иртә-кич көн саен ат белән шунда алып барырга куша. Шулай итеп, алар ике атна чамасы аралаша, тарантаста җилдерәләр... Тукай авылыбыздан киткәндә, әтигә рәхмәт йөзеннән, китапларын да бүләк иткән»[4]. Бу мәкаләдә, кызганыч ки, «вакыйга булган ел» күрсәтелмәгән.

Моңа кадәр миңа билгесез булган бу мәгълүматны дикъкать белән укып чыккач, шундый сораулар барлыкка килде: ә бу хакта берәр язма истәлектә хәбәр бармы, Г. Тукайның ул вакыттагы физик халәте аңа Уфадан ерак араларга ат арбасында яки чанасында шул дәвернең юлларында йөрергә мөмкинлек биргәнме һәм башкалар, һәм башкалар...

Г. Тукайның Уфага сәфәре турында тулы һәм иң ышанычлы язма истәлекләрнең берсе «Сабах» көтепханәсе бүлеге мөдире Х. Зәбиринеке. Әмма анда шагыйрьнең шәһәрдән авылларга чыгып йөрүе хакында бернинди дә мәгълүмат китерелми. Андый хәл булса, мотлакан теркәп калдырыр иде. Чөнки ул, язмасыннан аңлашылганча, Г. Тукай өчен үзендә зур җаваплылык тойгысы кичергән. Бу турыда ул болай яза: «Мәҗит Гафури һәр көнне килә. Ике шагыйрь рәхәтләнеп көн үткәрәләр. Бу турыда Мәҗитнең истәлекләре булганлыктан, артык язуны кирәксенмим, тик шуны гына әйтеп узам: мин аларның тыныч кына, тәмләп кенә шунда утыруларын тели идем. Шәһәргә чыгып уралып йөрсәләр кирле-кирәкмәгән кешеләргә очрап, Тукайның кәефен җибәрә торган берәр вакыйга булмас дип куркына идем»[5].

Г. Тукайны поездга утыртып Петербургка озатканда да ул җитди хәстәрлек күрә: «...Мин вокзалга озатышып Мәскәүгә тугры бара торган поездга билет алып бир-

[1] Гариф М. Мәңгелек мәхәббәт (Тукай белән Зәйтүнә хикәяте) / М. Гариф. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — Б.71.

[2] Гариф М. Күрс. хезм. — Б. 38.

[3] Гариф М. Күрс. хезм. — Б. 38.

[4] Әхмәдуллина Ф. Кунак Тукай / Ф. Әхмәдуллина // Ватаным Татарстан. — 2022. — 9 апр.

[5] Зәбири Х. Шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр... Б. 370.

дем. Эстәрлетамак сәүдәгәрләреннән бер кеше Мәскәүгә кадәрле карап барырга һәм анда Николайски вокзалда озатып йибәрергә дә өстенә алды»[1].

Уфада Кәримев-Хөсәневләрнең «Шәрекъ» китапханәсендә эшләгән Г. Вәлиев (?–?) исемле кеше Петербургта йөреп кайткан Г. Тукайның халәтен болай тасвирлый: «Мин аны «Сабах» китапханәсенең шул арткы бүлмәсендә күрәм һәм күрешү белән эсселе-суыклы булып киттем. Чөнки Тукай мин күргән, 1907–[1]908 нче елларда Казанда күргән, сөйләшкән, көлешкән ачык йөзле, шат күңелле Тукай түгел. Ул бөтенләй үзгәргән, бик ябык, хәлсез, рухсыз, өмидсезлеге йөзенә чыккан. Бик еш йөткерә, күзләрен бер йиргә терәп озак карап тора, бик әз сөйли. Шуның өчен күрешеп, хәл-әхвәл сорашу белән сүз бетте. Аның Троискигә китеп барышы икәнлеге миңа билгеле иде.

Тукайны бу хәлдә күрү миңа бик авыр тоелды, аның соңгы вакытларда «Теләү бетте», «Исемдә» вә «Васыятем» шикелле өмидсезлек җырлары җырлый башлавының нәрсәдән икәнлеге аңлашына иде»[2]. Х. Зәбири дә үзенең истәлегендә шулайрак яза: «Ниһаять, Габдулла әфәнде Петербургтан 2–3 һәфтә[3] соңра әйләнеп тә кайтты. ...Гаять дәрәҗәдә ватылып... сәламәтлеген тагын югалта төшеп кайтты»[4].

Чөнки Петербург университеты табибы А. Р. Поль ачыклаганча, Г. Тукайда туберкулезның инде соңгы дәвере булып, үпкәсенең бер ягы череп бетеп, икенче ягының да яртысы гына кала. Тын ала торган әгъзаларының дүрттән бере белән генә тын алып тора.

Г. Тукай Петербургтан Уфага кайткач, канын анализга тапшыру да проблемага әверелгән була. Моны без аның К. Бәкергә юллаган хатындагы менә шул юллардан укып беләбез: «...Уфа докторына кан тәхлилле тугрысында бардым. Ул әүвәл тазарырга, сәламәтләнергә кирәклеген вә бер кадәр беткән тәнне тәхлилгә вә анда микроб булган тәкъдирдә дә аңар агулы дару җибәрү мөмкин түгеллеген сөйләде. Җүтәлдән бер-ике төрле дару бирде. Кымыз эчәргә куштылар»[5].

Г. Тукайның сәламәтлеге 1912 елда ул әле Казанда вакытында ук начарланган була. Журналист Гариф Латыйф (1886–1962) шагыйрьне кайгыртып табибка алып баруы турында болай яза: «Бер вакыт мин аны врач Зарницын квартирасына алып бардым. Ул туберкулез авыруларын дәвалый торган оста врач иде. Бер вакыт врач Зарницын «Шәрекъ клубы»нда туберкулез авыруы һәм аңа каршы көрәш турында лекция укыган иде.

Зарницын Г. Тукайның күкрәген тыңлап карады, кайбер дарулар алырга рецепт язып бирде. Май, сөт һәм башка туклыклы азыклар ашарга, күбрәк яхшы, саф һавада йөрергә киңәш бирде»[6].

---

[1] Зәбири Х. Шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр... Б. 371.

[2] Вәлиев Г. Габдулла Тукай хакында хәтердә калганнар... — Б. 529–530.

[3] *Һәфтә* — атна (җиде көн).

[4] Зәбири Х. Шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр... Б. 371.

[5] Бәкер К. Күрс. хезм. — Б. 55–56.

[6] Латыйф Г. Татар халык шагыйре Габдулла Тукай турында истәлек / Г. Латыйф // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 451.

Г. Тукай белән Уфада турыдан-туры аралашкан икенче шәхес М. Гафури да үзара очрашулары турында шактый тәфсилле истәлек калдырган. Ул да шагыйрьнең пайтәхеттән бик йончып кайтуын һәм аның шәһәрдән башка беркая да бармавы турында болай яза: «Тукайның Уфада үткәргән ун-унбиш көн гомере «Сабах» көтепханәсенең артындагы бүлмәдә үтте»[1].

Шагыйрьнең сәфәрләре турында язма чыганаклардан тагын берсе — үзенең «Мәкаләи махсуса» дигән язмасы. Анда да аның Аблай авылы, Бәләбәй тарафларында йөргәнлеге хакында бернинди дә мәгълүмат китерелми.

Моннан байтак элек миңа Г. Тукайның хәзерге Башкортстан Республикасының Борай авылында кунакта булганлыгы турында да ишетергә туры килгән иде. Бу хосуста шунысын да онытмыйк: Уфа белән ике ара ике йөз чакырым тирәсе. Имеш, ул анда мунча кергәндә чабынган вакытында (!) миллек (себерке) түшәмдәге ярыкка кысылып калган. Шагыйрь кайда да, хәтта, ләүкәдә дә шагыйрь инде. Тиз генә «Җен тотты» дигән шигырьне иҗат итеп тә куйган. Дөрес, андый шигырьнең булу-булмавы әлегә татар әдәбияты гыйлемендә мәгълүм түгел.

Матбугатта Г. Тукайның хәзерге Татарстан Республикасы Яшел Үзән районындагы Мулла Иле авылында 1910 елда Гыйззәтулла Галиәкбәров (1885–1911) исемле муллада кунакта булганлыгы турында мәкалә басылды[2].

Шагыйрьнең хәзерге Арча районындагы Күпербаш авылына еш кына кайтып йөргәнлеген, Әминәгә (!) мәхәббәтен «раслаучы» язмалар да дөнья күрде[3].

Рәйсә Биккулова-Яркәева исемле автор әтисе Миргасыймның Г. Тукайны җирләүдә катнашуы турында язып чыкты[4]. Әмма мәкаләдәге шундый юллар уйланырга га мәҗбүр итә: «Җирләү һәм дини йолалары тәмамлангач та, бер кеше дә урыннан кузгалмады. Алар елый-сыктый моңланып, җыр башладылар». Хәтта, җырның бер куплеты да китерелә. Башка халыкларда ничектер, әмма мөселаман каберстанында җырлау кебек гореф-гадәтнең юклыгы тәгаен мәгълүм.

Билгеле ки, Г. Тукайның сәламәтлеге Уральскидан Казанга кайтканда ук инде яхшыдан булмый. 1907 елның сентябрь ае ахырында аны беренче булып каршылаган кеше, «Йолдыз» газетасында редакция-кантур мөдире, хисапчы, Галим (Галимҗан) Әмирхан (?–?) бу хакта болай яза: «Мәрхүм Тукай Казанга килгән көннәрдә төсенә карап, туп-тугры Тукай арыган, Тукайга яхшы тәрбия кирәк, яхшы ашау кирәк, яхшы һава кирәклеге күренеп тора иде. Чөнки Тукайның кечкенәдә ятим булып үсүе, мәдрәсә, типография, ачлы-туклы тормышлар Тукайны шул хәлгә китерергә тиешле булгандыр. Бәлкем әллә ул Казанга килгәндә үк үзен яшьлек дәверен-

[1] Гафури М. Күрс. хезм.

[2] Сәйфетдинов Р. Тукай — Мулла Илендә / Р. Сәйфетдинов // Ватаным Татарстан. — 2015. — 15 авг.

[3] Мир-Хайдаров Р. Последняя любовь поэта: неизвестные факты из жизни Габдуллы Тукая 1911–1912 годов / Р. Мир-Хайдаров // Респ. Татарстан. — 2018. — 20 сент.; Мир-Хәйдәров Р. Шагыйрьнең соңгы мәхәббәте (1911–1912 елларда Габдулла Тукай тормышына кагылышлы укучыларга мәгълүм булмаган вакыйгалар) / Р. Мир-Хәйдәров // Казан утлары. — 2019. — № 4. — Б. 169–173; // Тулпар. — 2019. — № 2. — Б. 44–55.

[4] Биккулова-Яркәева Р. Әткәм Тукайны җирләүдә катнашкан / Р. Биккулова-Яркәева // Кызыл таң. — 2000. — 1 март.

дәге авыр-начар тормышлары аңа яшерен хәлдә туберкулез оялап өлгергән булгандыр.

Шул хәлдә бер ялгыз, гаилә тормышы рәхәтен күрмәгән, ата-ана тәрбиясен бөтенләй белмәгән, вакытында җылы-кайнар ашы, чәе, тәмле чәй ашлары күрмичә фәкать кагылган, шунда фәкать хәрчәүник-ысталавай ашлары белә тукланып тору, аны да вакытында ашамау, эчмәү аның бар сәламәтлегенә зарар итте»[1].

Биредә китап һәм мәкалә авторларына хосусан нинди дә булса кискен дәгъва белдерү максат итеп куелмады. Алар шагыйрьнең тәрҗемәи хәле һәм иҗат эшчәнлеге белән кызыксына, эзләнә. Бу юнәлештә алып барган изге гамәлләре бары тик һәрьяклап ихтирамга һәм игътибарга лаек. Минем бурыч исә бары тик язма чыганакларга (истәлекләргә) нигезләнеп, куелган мәсьәләгә берникадәр ачыклык кертергә омтылыш ясау иде. Ә тиешле нәтиҗә чыгару һәркемнең үз эше.

Моны язучы һәм сәясәт эшлеклесе Г. Исхакый тагы да элгәрерәк алдан күреп, болай язган: «Тукайның зурлыгы алдында бөтен кечкенәләр, бөтен ваклар мыж киләчәкләр. Бөтен хәшәрәтләр аның төрле тарафында, төрле төстә җыелып: «Без Тукай берлән икәү...» дигән хиссиятне калдырыр өчен әллә никадәр маташачаклар. Берсе: «Шәкертем Тукайга әйттем», — дип йөриячәк. Берсе: «Без Тукай дуст берлән кочаклашып, табигатьне карап ләззәтләнә идек; Берсе: «Мин Тукай килгәч: «Син бит, Габдулла, миннән азрак сабак укымадың, менә минем фәлән мәкаләмне укы әле, фәлән китабымны моталәга[2] ит әле», − дип әйттем», − дип мактаначактыр. Бу табигый бер эштер. Авыл Сабан туенда батыр калган егетнең кодасы, кодачасы күбәйгән кебек, тормыш тартышында да шундый ихтирамны алган кешенең дусты, хәлфәсе, туганы, җан дусты күбәячәге дә билгеледер. Тукай да шулай булачактыр.

Аның хакында дөрест, ялган әллә никадәр сүз сөйләнеләчәк. Әллә никадәр юллар язылачактыр. Ләкин шул сүзләр, шул язулар арасында көнче кешеләргә азык булырлык бик күп материал табылса да, шуларның начар тәэсире мәктәбемезгә керергә тиеш түгелдер вә сыйныф балаларымызның күңелендәге матур, пакь шагыйрь Тукай дигән идеалыны пычратмаска, керләтмәскә тиештер»[3].

Г. Тукайның замандашы Камал Фәхретдиновның (?–?) шагыйрьгә багышланган мәкаләсендәге кайбер киңәшләренә игътибарны юнәлтү артык булмас дип уйлыйм: «Минем әйтергә теләгән сүзем дә әнә шул кешеләрдән ишетеп язучылар хакында. Чөнки соңгы вакытта матбугат сәхифәләрендә «язып алдым», «кешеләрдән ишеттем» кебек сүзләр еш кына күренә башлады. Хәтта: «Бу Тукай җырлаган җырлар» кебек риваятьләргә бик саклык белән карарга кирәктер... Әнә шул «язып алучыларга» һәм «фәлән кешедән ишеттем»нәргә бик саклык белән һәм җитди күзлектән карап эш итәргә кирәк»[4].

---

[1] Әмирхан Г. (Галим). Татар халкының сөекле. Бөек шагыйре Габдулла Тукайның Казанга килгән көннәре / Г. (Галим) Әмирхан // Тукай — ядкярләрдә: 2 томда / Фәнни мөх. Ж. Миңнуллин; төз.: Р. Исламов, Ж. Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2015. — 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. — Б. 419.

[2] *Моталәга* — берәр мәсьәләне төрле яктан тикшереп хөкем чыгару.

[3] Гаяз. Мәрхүм Тукай / Гаяз // Ил. — 1915. — 24 март.

[4] Фәхретдинов К. Энҗене чүпкә буямаска кирәк / К. Фәхретдинов // Кызыл таң. — 1966. — 26 окт.

Рәсем сәнгатендә дә Г. Тукайны тасвирлауда төгәлсезлекләр юк түгел. Мәсәлән, театр рәссамы, Татарстан Республикасының халык рәссамы Госман Абдулов (1922–2010) «Нәни Тукай Печән базарында» (1997) картинасын кыш көне итеп сурәтләгән. Чыганакларда язылганча, вакыйга җәй айларында була. Бу хакта Фәрхәт Зыятов шулай яза: «Бу картинаны ясарга алынганчы, Тукай турында язылган әсәрләрне, истәлекләрне укып кына чыгасы ит югыйсә. Шулай булса, җәй көне чана җикмәүләрен, тун кимәүләрен генә белер иде!»[1]. Шунысын да искәртеп үтү урынлы булыр: булачак шагыйрь ул вакытта Тукай буларак түгел, ә Габдулла исеме белән билгеле. Бу мәсьәлә үзе бер зур тема, шуңа күрә биредә аңа киң һәм тирән итеп тукталу мәгъкуль күрелмәде.

Әдәби әсәрләрдә Г. Тукай турында урын алган аерым төгәлсезлекләргә яки җитешсезлекләргә бары тик драматург Туфан Миңнуллин (1935–2012) гына тәнкыйди карады булса кирәк. «Без китәбез, сез каласыз» исемле пьесасының беренче вариантына карата шулай язып чыкты: «Акчуриннар белән саубуллашканда аны кырысрак итеп сурәтләдем. Өстәвенә, үзенә шагыйрьне кунакка чакырган Хәсән Акчурин шәхесен сурәтләүдә дә хилафлык киткән. Ярый әле исән чагымда ялгышымны төзәтеп өлгердем. «Без китәбез, сез каласыз»ның финалын төзәтеп яздым. Үземнең китапханәмдә саклана торган унтомлыкта пьесаның үзгәртелгән варианты саклана»[2].

XIV

Г. Тукайның библиографиясен төзергә беренче омтылыш XX гасырның кырыгынчы елларында ясала. Аерым алганда, әдипнең тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында кечкенә белешмә 1941 елда дөнья күрә[3]. Аннан соң берникадәр күләмлерәк андый хезмәт Зәйнәп Хәбибуллина (?–?) тарафыннан башкарыла[4]. Шагыйрьнең беренче библиографиясен фәнни нигездә Мәсгудә Бурнашева (1907–1973) төзи. Г. Тукай әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның кыскача библиографиясе (1907–1956 еллар)» дип аталган әлеге хезмәт әдипнең Хәй Хисмәтуллин (1895–1977) һәм Я. Агишев тарафыннан әзерләнеп, 1955–1956 елларда нәшер ителгән дүрт томлы «Әсәрләр»енең дүртенче томына кушымта сыйфатында урнаштырыла[5]. Аның төзелеше шулай: «Г. Тукайның аерым китап булып басылган әсәрләре (Татар телендә)», «Г. Тукайның совет чорында басылган китаплары (Татар телендә)»; «Г. Тукай әсәрләре СССР халыклары телендә»: «Рус телендә аерым китап булып чыккан әсәрләре», «Г. Тукайның рус телендә вакытлы матбугатта чыккан әсәрләре», «Г. Тукай әсәрләре басылган русча җыентыклар», «Башкорт телендә», «Казах телендә», «Кыргыз телендә», «Үзбәк телендә», «Уйгур телендә», «Чуваш телендә»; «Г. Тукай

[1] Зыятов Ф. Тукай Өчиледә / Ф. Зыятов // Казан утлары. — 2011. — № 4. — Б. 121.

[2] Миңнуллин Т. Ялгыш төзәтелергә тиеш / Т. Миңнуллин // Казан утлары. — 2011. — № 4. — Б. 135.

[3] Габдулла Тукай (1886–1913) (Библиографик белешмә). — Казан, 1941. — 4 б.

[4] Татар халык шагыйре Габдулла Тукай (1886–1913): Әдәбият исемлеге / Төз. З. Ш. Хәбибуллина. — Казан, 1953. — 19 б.

[5] Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда / Төз.: Х. Хисмәтуллин, Я. Агишев; Г. Халит ред. / Г. Тукай. — Казан: Таткнигоиздат, 1956. — 4 т.: Мәкаләләр, очерклар һәм фельетоннар (1909–1913 еллар). — Б. 256–276.

турында тәнкыйть әдәбияты»: а) «Аерым китап булып чыккан әсәрләр (татар телендә)», б) «Вакытлы матбугатта чыккан тәнкыйть әдәбияты (татар телендә)»; «Тукай турында рус телендә чыккан тәнкыйть әдәбияты»: а) «Революциягә кадәр», б) «Революциядән соң»; «Тукай турында башка илләрдә чыккан әдәбият»; «Г. Тукай турында истәлекләр», «Габдулла Тукай матур әдәбиятта»: а) «Татар телендә», б) «Рус телендә».

Ләкин, шунысын да әйтергә кирәк, башка төрки телдәге чыганаклар, нишләптер, татарчага тәрҗемә итеп бирелгән.

Әмма бу библиография, төзүче үзе язганча, тулылыкка дәгъва белдерми. Аерым алганда, ул болай ди: «Бу библиографиягә без Тукай турында булган әдәбиятның барысын да кертүне бурыч итеп куймадык. Шагыйрьнең бай иҗаты белән тирәнрәк кызыксынучы укучыларга. Аның иҗаты өстендә эшләүчеләргә ярдәм итү теләге белән, бүген дә әһәмиятен югалтмаган чыганакларны гына керттек. Тукай әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның тулы библиографиясе якын киләчәктә чыгарылыр дип уйлыйбыз»[1].

1974 елда Казан дәүләт университеты нәшриятында «Габдулла Тукай. Библиографик күрсәткеч. 1956–1970» исемле китап дөнья күрә[2]. Ләлә Хәйдәрова, Наилә Әхмәтҗанова төзегән бу хезмәттә материаллар шундый бүлекләргә урнаштырылган: «Г. Тукай әсәрләре. Сайланма әсәрләр»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Җыентыклар һәм аерым басылып чыккан әсәрләр»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә, чит ил халыклары телендә; «Г. Тукайның җыентыкларда, альманахларда һәм журналларда басылган әсәрләре»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Г. Тукайның газеталарда басылган әсәрләре»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Г. Тукайның хатлары»: татар телендә, рус телендә; «Г. Тукайның тәрҗемәләре»; «Г. Тукай турында әдәбият. Гомуми бүлек»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә, чит ил телендә; «В. И. Ленин Г. Тукай турында»: татар телендә, рус телендә; «Биографик материаллар»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Истәлекләр»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Тукайның иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи карашлары»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Г. Тукай иҗаты турында әдәбият. Гомуми бүлек»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Тукайның осталыгы»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Г. Тукай һәм халык иҗаты»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Г. Тукай иҗатында сатира»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Г. Тукай һәм әдәби тел»: татар телендә, рус телендә; «Г. Тукай иҗатында тәрбия мәсьәләләре»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Тукай иҗатын мәктәптә өйрәнү»: татар телендә, рус телендә; «Г. Тукай һәм башка халыклар әдәбияты. Г. Тукай заман шагыйрьләренең остазы»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Тукай — тәрҗемәче»: татар

[1] Бурнашева М. Тукай әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның кыскача библиографиясе (1907–1956 еллар) / М. Бурнашева // Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда... — 4 т.: Мәкаләләр, очерклар һәм фельетоннар (1909–1913 еллар). — Б. 257.

[2] Габдулла Тукай. Библиографик күрсәткеч. 1956–1970 / Төз.: Л. Хәйдәрова, Н. Әхмәтҗанова. — Казан ун-ты нәшр., 1974. — 116 б.

телендә, рус телендә; «Г. Тукай әсәрләренең СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемәләре турында»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Г. Тукай матур әдәбиятта. Китаплар»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Җыентыклар, альманахлар һәм журналларда басылган әсәрләр»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Газеталарда басылган әсәрләр»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Тукай сәнгатьтә»: Музыкада: татар телендә, рус телендә; Балетта: татар телендә, рус телендә; Театрда: татар телендә, рус телендә; Кинода: татар телендә; Скульптурада: татар телендә; Сынлы сәнгатьтә: татар телендә; График хезмәтләрдә: татар телендә, рус телендә; «Г. Тукай фоторәсемнәрдә»: татар телендә; «Тукай исемен мәңгеләштерү. Г. Тукай исемендәге республика бүләкләре»: татар телендә, рус телендә; «Г. Тукайның туган көне уңае белән үткәрелгән чаралар»: татар телендә, рус телендә, СССР халыклары телендә; «Г. Тукайга һәйкәлләр»: татар телендә, рус телендә; «Музейлар»: татар телендә, рус телендә; «Шагыйрь туган якларда»: татар телендә, рус телендә; «Тукайга багышланган библиографик күрсәткечләр»: татар телендә, рус телендә.

Әтрафлы һәм җентекле төзелгән бу библиографик күрсәткечтә, кызганыч ки, «СССР халыклары телендә» дигән бүлекчәдә материаллар барысы да рус теленә тәрҗемә итеп бирелгән.

Бу хезмәттә, Г. Тукай турындагы әдәбиятны мөмкин кадәр тулырак тупларга тырышылса да, төзүчеләр белдергәнчә, район газеталарындагы материаллар кертелмәгән, СССР һәм чит ил халыклары телләрендәге текстларның барысы да булмаганлыктан de visu тулысынча каралмаган.

Аннан соң Г. Тукайның әсәрләре тагын күп мәртәбә дөнья күрә, фәнни-мәдәни чаралар үткәрелде, шагыйрь иҗаты турында диссертацияләр яклана, хезмәтләр нәшер ителә, мәкаләләр басыла. Шуларны истә тотып, безнең тарафтан әдипнең яңа библиографик күрсәткече төзелеп, 2016 елда нәшер ителде[1]. Ул Г. Тукайның «Әсәрләре» һәм «Тормышы һәм иҗаты турында» дигән ике кисәктән гыйбарәт булып, икенчесе «Китаплар, монографияләр, гыйльми җыентыклар», «Диссертацияләр» һәм «Мәкаләләр» дигән өч бүлекчәгә бүленде һәм нинди телләрдә басылуларына карап аерымланды.

Шагыйрьнең әсәрләренә, аның тормышы һәм иҗатына багышланган фәнни хезмәтләргә яки җыентыкларга карата басылган бәяләмәләр һәр чыганак астында күрсәтелде. Бер үк чыганакның берничә мәртәбә басылу очраклары да истә тотылды. Бу укучыга аларны табып файдалануны җиңеләйтергә мөмкин.

Шагыйрьнең китап булып нәшер ителгән әсәрләре анда хронологик нигездә бирелде. Ә калган чыганаклар, нинди телләрдә басылуы буенча аерымланып, гамәлдәге татар алфавиты бирелеше тәртибендә урнаштырылды. Көндәлек матбугатта басылган шигырьләре алынмады.

Ләкин ул, кызганычка күрә, киң даирә укучыга җитәрлек күләмдә нәшер ителә алмады. Аннан соң тагын 2020 берәмлектән артык чыганак өстәлде. Шуларны һәм шагыйрьнең чираттагы юбилеен истә тотып, аның бу биобиблиографик күрсәткече

[1] Габдулла Тукай. Библиографик күрсәткеч / Төз. Р. Ф. Исламов. — Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016. — 480 б.

әзерләнде. Дөрес, ул да шулай ук камил тулылыкка дәгъва итми[1]. Бу төзүчегә бәйле булмаган объектив сәбәпләр белән аңлатыла. Әлеге юнәлештә эш киләчәктә дә дәвам иттерелүенә ышанасы килә.

Библиографик күрсәткечтә татар, әзәрбәйҗан, башкорт, балкар, венгр, гагауз, гарәп, инглиз, казакъ, каракалпак, кыргыз, кырымтатар, кытай, латыш, литва, мари, молдаван, немец, норвег, поляк, рус, тажик, төрек, төрекмән, удмурт, уйгыр, украин, үзбәк, фарсы, француз, чиркәс, чуаш, эстон телләрендәге чыганаклар тупланды.

Сүзләр чыганакларда ничек язылган булса, алар анда да шулай калдырылды. Мәсәлән, «Qzьl Tatarstan — Qьzьl Tatarstan», «Тукай — Тукаев», «Нафигов — Нафиков — Нәфигов — Нәфиков — Нәфыйков», «Расулева — Расүлева — Рәсүлева», «Баһаветдинова — Баһаутдинова», «Гыйлаҗев — Гыйләҗев», «Әгъзамов — Әгъзәмов», «Сәгыйт — Сәгыйть» һәм башкалар. Г. Тукайның кайбер китаплары «Шүрәле» тәхәллүсе белән нәшер ителгән. Күрсәткечтә ул үзгәртелмәде.

Академик Ә. Кәримуллин Г. Тукайның библиографиясен төзү зарурлыгы хакында язган мәкаләсендә шулай дигән иде: «Тукайның фәнни библиографиясен булдыру — фәнни оешмаларның планы нигезендә башкарыла торган эш»[2]. Кызганыч ки, ул һаман «аерым кешеләрнең үз ихтыярлары белән генә, Г. Тукайга булган мәхәббәт нигезендә генә, бер тиен түләүсез»[3] башкарылып киленә.

***

Эш барышында аерым мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәме өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директорының фән эшләре буенча урынбасары Ирек Һадиевка олуг рәхмәтләремне белдерәм.

Рәмил Исламов,
филология фәннәре докторы,
Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе

[1] Мәсәлән, Бәйрутта чыккан «Әл-голүм» журналынның 1969 елгы октябрь санында Г. Тукай хакында мәкалә басылуын «Казан утлары» журналындагы (1971, 2 нче сан) хәбәр буенча гына беләбез.

[2] Кәримуллин Ә. Җәүһәрләр югалмасын / Ә. Кәримуллин // Соц. Татарстан. — 1986. — 7 июнь.

[3] Кәримуллин Ә. Күрс. хезм.

ӘСӘРЛӘРЕ

Татар телендә

Г. Тукаев шигырьләре. 3 нче дәфтәр. Беренче кыйсем. Казанда Шәрәф матбагасы, 1907. — 48 б.

Рец.: Дамелла. «Габдулла Тукаев шигырьләре» / Дамелла // Әл-Ислах. — 1907. — 3 дек.

Габдулла Тукаев шигырьләре. 4 нче дәфтәр. Икенче кыйсем. Казанда Шәрәф матбагасы, 1907. — 56 б.

Рец.: Дамелла. «Габдулла Тукаев шигырьләре» / Дамелла // Әл-Ислах. — 1908. — 2 февр.

Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш. 7 нче дәфтәр. Габдулла Тукаев асәре. — Лито-типогр. И. Н. Харитонова Казань, собст. дом, 1908. — 22 б.

Рец.: Дамелла. «Яңа китаплар» («Печән базары яхут яңа Кисекбаш» / Дамелла // Әл-Ислах. — 1908. — 24 нояб.

Җуаныч. Асәр: Г. Тукаев. Беренче китап. Нашире: Сабах көтепханәсе. — Харитонов матбагасы Казанда, 1908. — 19 б.

Рец.: Габди. Яңа әсәрләр / Габди // Йолдыз. — 1911. — 5 апр.

Алтын әтәч. Асәр: Г. Тукаев. Икенче китап. Пушкин хикәясеннән алынды. Нашире: Сабах көтепханәсе, 1908. — 15 б.

Габдулла Тукаев диваны. 8 нче дәфтәр. 3 нче кыйсем. «Гасыр» көтепханәсе. — Казан: Электро-тип. «Урнэк», 1908. — 48 б.

Рец.: Габди. Яңа әсәрләр / Габди // Йолдыз. — 1911. — 5 апр.

Алтын әтәч. Икенче китап. Асәр: Г. Тукаев. Пушкин хикәясеннән алынды. Нашире: Сабах көтепханәсе. — Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1909. — 18 б.

Габдулла Тукаев шигырьләре. 3 нче дәфтәр. 1 кыйсем. Икенче табгысы / Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1909. — 48 б.

Габдулла Тукаев шигырьләре. 4 нче дәфтәр. 2 кыйсем. Икенче табгысы / Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1909. — 48 б.

Тукаев Г. Энҗе бөртекләре. Нашире: Мәгариф көтепханәсе / Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1909. — 72 б.

Тукаев Г. Яңа кыйраәт. Нашире: «Мәгариф» матбагасы / Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1909. — 72 б.

Рец.: Бәкер К. «Яңа кыйраәт» / К.Бәкер // Йолдыз. — 1909. — 17 сент.

Әдәбият. 10 нчы дәфтәр. Шагыйрь Габдулла Тукаевның. Габдулла әфәнде Тукаевның рәсеме илә. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1909. — 30 б.

Тукаев Г. Исемдә калганнар. Габдулла әфәнде Тукаев рисаләсе илә / Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1909. — 38 б.

Рец.: Бәкер К. Яңа әсәрләр / К. Бәкер // Йолдыз. — 1909. — 6 дек.

Тукаев Г. Балалар күңеле. Беренче җөзэ. Ибтидаи мәктәпләр өчен шигырьләр мәҗмугасе. Нашире: «Сабах» көтепханәсе Казанда / Г. Тукаев. — Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1910. — 32 б.

Күңелле сәхифәләр. 4 нче китап. Габдулла Тукаев әсәре. Нашире: «Сабах» көтепханәсе. Казан. — Казань: Тип. «Миллят», 1910. — 16 б.

Халык моңнары. Җыючысы Шүрәле. Нашире: «Сабах» көтепханәсе Казанда. — Казань: Типогр. «Миллят», 1910. — 24 б.

Тукаев Г. Халык әдәбияты. Нашире: «Сабах» көтепханәсе / Г. Тукаев. — Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1910. — 43 б.

Әдәбият. 10 нчы дәфтәр. Шагыйрь Габдулла Тукаевның. Икенче табгы. — Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе, 1910. — 30 б.

Рец.: Габди. Яңа әсәрләр / Габди // Йолдыз. — 1911. — 5 апр.

Тукаев Г. Яңа кыйраәт (икенче табгы) / Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы. — Казань: Электро-тип. «Урнэк», 1910. — 56 б.

Тукаев Г. Балалар күңеле. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда / Г. Тукаев. — Казань: Электро-тип. «Урнэк», 1911. — 44 б.

Тукаев Г. Күңел җимешләре. Нашире: Сабах көтепханәсе / Г. Тукаев. — Типогр. И. Н. Харитонова соб. дом, 1911. — 46 б.

Рец.: Габди. Яңа әсәрләр («Күңел җимешләре») / Габди // Йолдыз. — 1911. 5 апр.

Тукаев Г. Мияубикә. 1 нче китап. Нашире: Сабах көтепханәсе / Г. Тукаев. — Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1911. — 24 б.

Рец.: Габди. «Мияубикә» / Габди // Йолдыз. — 1911. — 21 июнь; С. Ваккас. «Мияубикә» / С. Ваккас // Шура. — 1011. — № 18. — Б. 572.

Шүрәле. Яшен ташлары. Беренче җөзэ. Нашире: Су анасы. — Казань: Электро-тип. «Умид», 1911. — 24 б.

Тукаев Г. Балалар күңеле. Беренче җөзэ. Икенче мәртәбә басылуы. Нашире: «Сабах» көтепханәсе, 1911. — 32 б.

Шүрәле. Яшен ташлары. Икенче җөзэ. Нашире: Су анасы / Шүрәле. — Казань: Электро-тип. «Умид», 1911. — 24 б.

Тукаев Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Нашире: Мәгариф көтепханәсе / Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1911. — 144 б.,

Тукаев Г. Балалар күңеле. Икенче кыйсем / Г. Тукаев. — Казань: Электро-тип. «Умид», 1912. — 32 б.

Шүрәле. Яшен ташлары. Икенче җөзэ. Нашире: Су анасы / Шүрәле. — Казань: Электро-тип. «Умид», 1912. — 23 б.

Тукаев Г. Сабитның укырга өйрәнүе / Г. Тукаев. — Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1912. — 8 б.

Халык моңнары. Икенче табгы. Җыючысы Шүрәле. Нашире: «Сабах» көтепханәсе Казанда, 1912. — 24 б.

Тукаев Г. Халык әдәбияты. Икенче табгы. Нашире: «Сабах» көтепханәсе / Г. Тукаев. — Казань: Электро-тип. «Умид», 1912. — 38 б.

Тукаев Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Нашире: «Сабах» көтепханәсе / Г. Тукаев. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1911. — 144 б.

Рец.: Габди. «Мәктәпләрдә милли әдәбият дәресләре» / Габди // Йолдыз. — 1911. — 4 гыйнв.

Тукаев Г. Җан азыклары (соңгы шигырь мәҗмугасе). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда / Г. Тукаев. — Казанда Л.П. Антонов матбагасы, 1912. — 48 б.

Г. Тукаев диваны. 6 нчы дәфтәр. «Мәгариф» көтепханәсе Казанда, 1913. — 48 б.

Г. Тукаев диваны. 7 нче дәфтәр. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. — Казань: Электро-тип. Л. П. Антонова, 1913. — 48 б.

Габдулла Тукаев диваны. 8 нче дәфтәр. 3 нче кыйсем. — Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1913. — 48 б.

Габдулла Тукаев шигырьләре. 1 кыйсем. Өченче табгысы. Казанда «Мәгариф» көтепханәсе, 1913. — 48 б.

Г. Тукаев шигырьләре. 4 дәфтәр. 2 кыйсем. Өченче табгысы. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. — Казань: Электро-тип. Л. П. Антонова, 1913. — 48 б.

Тукаев Г. Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш. 7 нче дәфтәр. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. — Казань: Электрич. тип. Л. П. Антонова, 1913. — 22 б.

Тукаев Г. Яңа кыйраәт (өченче табгы). «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. / Г. Тукаев. — Нашире: Антонов матбагасы, 1913. — 54 б.

Әдәбият. 10 нчы дәфтәр. Шагыйрь Габдулла Тукаевның (Икенче табгы). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. — Казанда Л. П. Антонов матбагасы, 1913. — 30 б.

Тукаев Г. Балалар күңеле. Өченче табгы / Г. Тукаев. — Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда, 1914. — 31 б.

Тукаев Г. Күңел җимешләре. Өченче табгы. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе / Г. Тукаев. — 1914. — 36 б.

Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Җәмаледдин Вәлиди тарафындан язылган Тукайның тәрҗемәи хале һәм әшгаре хакында бер мөляхәзә. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе Казанда. — «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1914. — 442 б.

Рец.: Емельянов А. Краткий обзор татарско-мухаммеданской неповременной печати за 1914-й г. / А. Емельянов // Инородческое обозрение, приложение к журналу «Православный собеседник» за сентябрь 1915 года. — Казань: Центр. тип., 1915. — Кн. 12-я. — С. 1008–1015; Юлдаш К. Матбугат вә әдәбият. Тукай мәҗмугасы / К. Юлдаш // Тормыш. — 1915. — 14 гыйнв.

Тукаев Г. Печән базары. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. Электро-тип. «Маариф», 1914. — 26 б.

Тукаев Г. Яңа кыйраәт (дүртенче табгы). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. Электро-тип. «Маариф», 1914 — 55 б.

Шүрәле. Яшен ташлары. Беренче җөзэ. Икенче басмасы. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1914. — 22 б.

Шүрәле. Яшен ташлары. Икенче җөзэ. Икенче басмасы. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1914. — 24 б.

Тукай Г. Җан азыклары (соңгы шигырь мәҗмугасе). Икенче басмасы. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1914. — 48 б.

Тукай Г. Шүрәле. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. — Казань: Электро-тип. «Маариф», 1914. — 11 б.

Тукай Г. Балалар күңеле. Беренче җөзэ. Дүртенче мәртәбә басылуы Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда / Г. Тукай. — «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1915. — 32 б.

Тукаев Г. Яңа кыйраәт (дүртенче табгы). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. Электро-тип. «Мааріф», 1915 — 55 б.

Габдулла Тукаев шигырьләре. 4 нче дәфтәр. 2 нче кыйсем. Дүртенче табгысы. Казанда «Мәгариф» матбагасы, 1915. — 48 б.

Габдулла Тукаев диваны. 8 нче дәфтәр (3 басылуы). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1915. — 48 б.

Тукаев Г. Балалар күңеле. 5 табгы. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1917. — 19 б.

Тукаев Г. Яңа кыйраәт (алтынчы табгы) / Г. Тукаев. — Казанда «Антонов» матбагасы. — Казань: Электро-тип. «Мааріф», 1917. — 55 б.

Тукаев Г. Халык әдәбияты (өченче мәртәбә басылуы). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда / Г. Тукаев. — 1917. — 31 б.

Тукай Г. Исемдә калганнар (өченче басылуы). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда / Г. Тукай. — Казанда «Мәгариф» матбагасы, 1917. — 34 б.

Тукаев Г. Җан азыклары (соңгы шигырь мәҗмугасе). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1917. — 48 б.

Тукаев Г. Яңа кыйраәт (йиденче табгы) / Г. Тукаев. — Казанда «Мәгариф» матбагасы, 1918. — 55 б.

Габдулла Тукаев шигырьләре. 3 нче дәфтәр. 2 нче кыйсем. Өченче табгысы. Казанда «Мәгариф» матбагасы, 1918. — 16 б.

Габдулла Тукаев шигырьләре. 3 нче дәфтәр. 1 нче кыйсем. Дүртенче табгысы. Казанда «Мәгариф» матбагасы, 1918. — 37 б.

Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Җәмаледдин Вәлиди тарафындан язылган Тукайның тәрҗемәи хале һәм әшгаре хакында бер мөляхәзә. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе Казанда. — «Мәгариф» матбагасы Казанда, 1918. — 239 б.

Тукай Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда / Г. Тукай. — Казанда «Мәгариф» матбагасы, 1919. — 112 б.

Тукай Г. Халык әдәбияты (Дүртенче басмасы). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда / Г. Тукай. — Казань: 6-я гос. тип., 1919. — 23 б.

Г. Тукай диваны (4 нче басылуы). Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе Казанда. — Казань: Изд-ие Т-ва «Мааріф», 1919. — 44 б.

Тукаев Г. Күңел җимешләре. Нашире: «Мәгариф» көтепханәсе / Г. Тукаев. — 1919. — 31 б.

Тукай Г. Алтын әтәч. Су анасы / Г. Тукай. — Казан: «Мәгариф» матбагасы, 1919. — 16 б.

Тукай Г. Шүрәле. Кәҗә белән сарык әкияте. Нашире: «Мәгариф» ширкәте / Г. Тукай. — Казан, 1919. — 14 б.

Тукай Г. Мияубикә / Г. Тукай. — Казан, 1919. — 15 б.

Шүрәле. Яшен ташлары. Беренче җөзә. Нашире: «Мәгариф» ширкәте, 1920. — 22 б.

Тукай Г. Мияубикә / Г. Тукай. — Казан, 1921. — 193 б.

Тукай Г. Шүрәле / Г. Тукай. — Казан: Матбугат һәм нәшр. эшләре комб. «Шәрекъ» матбагасы, 1923. — 10 б.

Тукай әсәрләре. — Казан: Татар. матбугат-нәшр. комб. басмасы, 1925. — 43 б.

Г. Тукай шигырьләре / Төз. Ф. Бурнаш. — Казан: «Гажур» нәшере, 1926. — 228 б.

Рец.: Галиев Г. Г. Тукай шигырьләре / Г. Галиев // Кызыл Татарстан. — 1926. — 29 авг.

Tuqaj A. Kisekbaş / A. Tuqaj. — Qazan, 1927. — 33 b.

Tuqaj A. Mijav bikə / A. Tuqaj. — Qazan, 1927. — 40 b.

Tuqaj A. Şyrəle / A. Tuqaj. — Qazan, 1927. — 20 b.

Tuqaj A. Su anasь həm başqa şiǫerlər / A. Tuqaj. — Qazan, 1928. — 29 b.

Ƣ. Tuqaj əsərləre / Təz. F. Səjfi-Qazannь. — Qazan: Jaŋlif, 1929. — I t. — 164 b.

Рец.: Ƣəli Ƣ. Akademik nəşrlərdə ąilmi nigzlər (Ƣ. Tuqaj əsərlərenең «Akademik» nəşere turьnda) / Ƣ. Ƣəli // Bezneң jul. — 1929. — № 6–7. — B. 10–18.

Ƣ. Tuqaj əsərləre / Təz. F. Səjfi-Qazannь. — Qazan: Jaŋlif, 1930. — 2 t. — 191 b.

Рец.: Ƣəli Ƣ. Ƣ. Tuqaj əsərləre. 2 nce tom. Jaŋlif nəşritь basmasь, 190 bit. Bəjəse 1 s. 50 t. / Ƣ. Ƣəli // Bzneң jul. — 1930. — № 2. — B. 41; // Jaŋalif. — 1930. — № 2. — B. 5–10.

Tuqaj A. Şurəle / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1930. — 29 b.

Тукай Г. Җуаныч / Г. Тукай. — Басып таратучы: Токиода матбагаи исламия, 1930. — 14 б.

Ƣ. Tuqaj əsərləre / Təz. F. Səjfi-Qazannь. — Qazan: Jaŋlif, 1931. — III t. — 208 b.

Тукай. Мәҗмугаи асәре. Беренче бүлем: җитди шигырьләр. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 209 б.

Тукай. Мәҗмугаи асәре. Мәрхүм милли шагыйремезнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәтилә хатирә уларак басылды. Икенче бүлем: балалар кыйсеме. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 314 б.

Тукай. Мәҗмугаи асәре. Мәрхүм милли шагыйремезнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәтилә хатирә уларак басылды. Өченче бүлем: көлке вә һөҗү кыйсеме. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 89 б.

Тукай. Мәҗмугаи асәре. Мәрхүм милли шагыйремезнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәтилә хатирә уларак басылды. Дүртенче бүлем: нәсер кыйсеме. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 105 б.

Тукай. Мәҗмугаи асәре. Мәрхүм милли шагыйремезнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәтилә хатирә уларак басылды. Бишенче бүлем: тәрҗемәи хәле. Нашире: Токиода матбагаи исламия, 1933. — 105 б.

Tuqaj A. Jaŋa Kisekbaş / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1934. — 24 b.

Tuqaj A. Mijav bikə / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1935. — 42 b.

Tuqaj A. Nəniləргə şiǫerlər / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1936. — 12 b.

Tuqaj A. Şyrəle / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1936. — 14 b.

Tuqaj A. Balalar өcen şiǫerlər / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1936. — 12 b.

Tuqaj A. Şyrəle / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1937. — 16 b.

Tuqaj A. Kəcə belən sarьq əkiəte / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1937. — 12 b.

Tuqaj A. Jьlnьŋ dyrt vaqьtь / A. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1937. — 11 b.

Tuqaj Ƣ. Sajlanma əsərlər / Çəv. red. M. Çəlil / Ƣ. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1938. — 622 b.

Рец.: Ƣəbdraxmanof F. Ƣ. Tuqaj sajlanma əsərləreneŋ syz başь turьnda / F. Ƣəbdraxmanof // Sovet ədəbiatь. — 1938. — № 4. — B. 77–80.

Tuqaj Ƣ. Şioɣerlr / Ƣ. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1938. — 76 b.

Tuqaj Ƣ. Sajlanma şioɣerlr / Ƣ. Tuqaj. — Qazan: Tatgosizdat, 1938. — 88 b.

Тукай Г. Әкиятләр. Шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1941. — 47 б.

Тукай Г. Академик басма / Төз.: Х. Хисмәтуллин; җав. ред. Ш. Рамазанов / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1943. — I т.: Шигырьләр. 1905–1913. — LI+471 б.

Рец.: Габдулла Тукай әсәрләренең тулы җыелмасы // Кызыл Татарстан. — 1943. — 14 апр.; Заляй Л. Академическое издание произведений Тукая / Л. Заляй // Кр. Татария. — 1944. — 19 янв.; Исәнбәт Н. Тукайның соңгы басмасы турында / Н. Исәнбәт // Совет әдәбияты. — 1945. — № 5. — Б. 59–73; Сөнкишева И. Тукайның үзгәртелмәгән китабы / И.Сөнкишева // Шәһри Казан. — 2006. — 10 июль.

Тукай Г. Кәҗә белән Сарык әкияте / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1944. — 8 б.

Тукай Г. Мияубикә / Г. Тукай. — Казан: Татагосиздат, 1944. — 11 б.

Тукай Г. Су анасы / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1944. — 8 б.

Тукай Г. Шүрәле / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1944. — 12 б.

Тукай Г. Балалар өчен шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1944. — 78 б.

Тукай Г. Күңелле сәхифәләр / Төз.: Г. Халит, Х. Хисмәтуллин / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1946. — 118 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр / Җыелманы Г. Халит, Х. Хисмәтуллин төз.; җав. ред. М. Гайнуллин / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат., 1946. — 323 б.

Рец.: Новые издания произведений народного поэта // Кр. Татария. — 1946. — 26 апр.

Тукай Г. Халык әдәбияты / Җав. ред. Х. Ярми / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1946. — 100 б.

Тукай Г. Балалар өчен шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1946. — 79 б.

Тукай Г. Күңелле сәхифәләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1946. — 118 б.

Тукай Г. Шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1946. — 12 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр / Төз.: Г. Халит, Х. Хисмәтуллин; Г. Халит кереш мәкаләсе белән / Г. Тукай. — Казан: Татагосиздат, 1946. — XXXII+322 б.

Тукай Г. Шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1946. — 11 б.

Габдулла Тукаев шигырьләре. Шагыйребез Габдулла Тукаевның дөньяга килүенә 61 ел тулу мөнәсәбәте белән бастырылды / Тех. ред. Х. Төхфи; ред. И. Юнич; нашире: Голҗа татарларының мәдәни җәмгыяте. — Голҗа: Инкыйлаби Шәркый Төркестан халык матбагасында басылды, 1947. — 17 б.

Тукай Г. Шигырьләр, мәсәлләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1947. — 62 б.

Тукай Г. Академик басма / Төз. Х. Х. Хисмәтуллин; җав. ред. Ш. Рамазанов / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1948. — II т.: Прозаик әсәрләр. 1905–1913. — 567 б.

Рец.: Исәнбәт Н. Тукай прозасы / Н. Исәнбәт // Совет әдәбияты. — 1949. — № 7. — Б. 102–107.

Тукай Г. Исемдә калганнар / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1949. — 32 б.

Тукай Г. Туган илемә (Шигырьләр һәм мәсәлләр) / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1949. — 68 б.

Тукай Г. Алтын әтәч / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1950. — 16 б.

Тукай Г. Япон хикәясе. Бурениннан алынган / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1950. — 12 б.

Тукай Г. Мияубикә / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1951. — 20 б.

Тукай Г. Мәсәлләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1952. — 56 б.

Тукай Г. Шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1952. — 55 б.

Тукай Г. Күңелле сәхифәләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1953. — 104 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томлык / Төз., кереш сүз авт. Я. Агишев / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1953. — 1т.: Шигырьләр. Поэмалар һәм әкиятләр. — XXV+322 б.

Тукай Г. Шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1953. — 56 б.

Тукай Г. Шүрәле / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1953. — 11 б.

Тукай Г. Әкиятләр / Г. Тукай. — Казан: Татгосиздат, 1953. — 32 б.

Тукай Г. Исемдә калганнар: Автобиографик очерклар, истәлекләр / Г. Тукай. — Казан: Таткнигоиздат, 1954. — 71 б.

Тукай Г. Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш / Г. Тукай. — Казан: Таткнигоиздат, 1954. — 19 б.

Тукай Г. Сатирик һәм юмористик шигырьләр / Төз. Ә. Исхак / Г. Тукай. — Казан: Таткнигоиздат, 1954. — 187 б.

Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда / Төз.: Х. Хисмәтуллин, Я. Агишев; Г. Халит ред. / Г. Тукай. — Казан: Таткнигоиздат, 1955. — 1 т.: Шигырьләр, поэмалар (1905–1908). — 282 б.

Рец.: Габдулла Тукай әсәрләренең яңа басмасы // Яшь сталинчы. — 1955. — 30 дек.

Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда / Төз. Х. Хисмәтуллин, Я. Агишев; Г. Халит ред. / Г. Тукай. — Казан: Таткнигоиздат, 1955. — 2 т.: 1909–1913 еллар. — 376 б.

Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда / Төз.: Х. Хисмәтуллин, Я. Агишев; Г. Халит ред. / Г. Тукай. — Казан: Таткнигоиздат, 1956. — 3 т.: Мәкаләләр, фельетоннар һәм хикәяләр (1906–1908). — 359 б.

Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда / Төз.: Х. Хисмәтуллин, Я. Агишев; Г. Халит ред. / Г. Тукай. — Казан: Таткнигоиздат, 1956. — 4 т.: Мәкаләләр, очерклар һәм фельетоннар (1909–1913 еллар). — 288 б.

Тукай Г. Мияубикә / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. — 16 б.

Тукай Г. Мәсәлләр / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. — 36 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр / Төз.: Х. Хисмәтуллин, Я. Агишев / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. — 507 б.

Тукай Г. Эш беткәч уйнарга ярый / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 23 б.

Тукай Г. Кызыклы шәкерт / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. — 11 б.

Тукай Г. Шүрәле / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. — 28 б.

Тукай Г. Шигырьләр. Әкиятләр. Поэмалар / Төз. Р. Башкуров / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. — 511 б.

Тукай Г. Су анасы (Бер авыл малае авызыннан) / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. — 20 б.

Тукай Г. Эш беткәч уйнарга ярый: Шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. –23 б.

Тукай Г. Кәҗә белән Сарык / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. — 12 б.

Abdulla Tukay. Şigırları / Ciyştıruçı H. Sadik. — Helsinki, 1969. — 102 b.

Тукай Г. Бу кайчак була? / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. — 14 б.

Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда / Төз., текст һәм иск. хәзерл. Р. Гайнанов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. — 1 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1904–1908). — 431 б.

Рец.: Хәким С. Тукайны укыйм... / С. Хәким // Соц. Татарстан. 1975. — 28 дек.

Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда / Төз., текст һәм иск. хәзерл. Р. Гайнанов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — 2 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). — 400 б.

Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда / Төз., текст һәм иск. хәзерл. Р. Гайнанов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — 3 т.: Мәкаләләр. Хикәяләр. Мәсәлләр. — 447 б.

Рец.: Нуруллин И. Яңа табышлар, кайбер югалтулар / И. Нуруллин // Соц. Татарстан. — 1977. — 23 окт.

Тукай Г. Карлыгач / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — 15 б.

Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда / Төз., текст һәм иск. хәзерл. Р. Гайнанов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. — 4 т.: Мәкаләләр. Очерклар. Фельетоннар. Хатлар (1902–1913). — 431 б.

Рец.: Нуруллин И. Тагын табышлар һәм аерым югалтулар турында / И. Нуруллин // Соц. Татарстан. — 1978. — 18 июль; Урманчеев Ф. Тукай томнарын укыганда / Ф. Урманчеев // Казан утлары. — 1978. — № 5. — Б. 163–167.

Тукай Г. Шүрәле: Әкият-поэма / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр, 1981. — 14 б.

Тукай Г. Мәсәлләр / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. — 28 б.

Тукай Г. Сабыйга: Шигырьләр, поэмалар, мәкаллә р / Төз. З. Миңнуллина / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. — 128 б.

Тукай Г. Кызыклы шәкерт. Шигырьләр / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. — 15 б.

Тукай Г. Су анасы / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — 13 б.

Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда / Текст һәм иск. хәзерл. Р. Гайнанов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — 1 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1901–1908). — 406 б.

Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда / Текст һәм иск. хәзерл. Р. Гайнанов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — 2 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). — 400 б.

Рец.: Галимуллин Ф. Һаман да якыная / Ф. Галимуллин // Соц. Татарстан. — 1985. — 12 окт.

Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда / Томны, иск. һәм аңл. хәзерл. Р. Гайнанов; текст. хәзерл. Л. Гайнанова булышты / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — 3 т.: Проза. Публицистика (1904–1906). — 391 б.

Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда / Томны, иск. һәм аңл. хәзерл. Р. Гайнанов; текст. хәзерл.: Р. Гайнанов, Л. Гайнанова / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — 4 т.: Проза. Публицистика (1907–1913). — 351 б.

Рец.: Галимуллин Ф. Тулыландыручы мирас / Ф. Галимуллин // Соц. Татарстан. — 1986. — 17 окт.

Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Томны төз., иск. һәм аңл. язды Р. Гайнанов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 5 т.: Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). — 368 б.

Рец.: Галимуллин Ф. Тулыландыручы мирас / Ф. Галимуллин // Соц. Татарстан. — 1986. — 17 окт.; Урманчеев Ф. Кадерлерәк була бара / Ф. Урманчеев // Казан утлары. — 1987. — № 4. — Б. 161–165; Рәкыйпов Ш. Кайдан табарга? / Ш. Рәкыйпов // Әлмәт таңнары. — 1993. — 5 гыйнв.

Тукай Г. Эш беткәч уйнарга ярый / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 22 б.

Abdulla Tukay 100 yıl. Tukay kiçesi. 25. 10. 1986. — Helsinki, 1986. — 13 b.

Тукай Г. Шүрәле: Әкият-поэма / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр, 1989. — 14 б.

Тукай Г. Исемдә калганнар: Шагыйрьнең ятим балачагы турында хикәя / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. — 32 б.

Тукай Г. Шигырьләр, әкиятләр, поэмалар / Төз. Р. Даутов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. — 254 б.

Тукай Г. Кәҗә белән сарык әкияте / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 15 б.

Тукай Г. Энҗе бөртекләре: Мәсәлләр / Г. Тукай. — Казан: Мәгариф, 1995. — 15 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: Шигырьләр, мәсәлләр, поэмалар / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. — 191 б.

Тукай Г. Бала белән күбәләк: Шигырьләр, әкиятләр / Төз.-мөх. Ф. Зыятдинова / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. — 79 б.

Рец.: Алтатар. Бала белән күбәләк / Алтатар // Мәдәни җомга. — 1996. — 26 апр.

Тукай Г. Тулган Иман берлән Коръән садремә / Басма өчен җав. В. Ягъкуб / Г. Тукай. — Казан: Иман, 1996. — 49 б.

Тукай Г. Шүрәле / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр, 1997. — 14 б.

Тукай Г. Шүрәле: Әкият-поэма / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр, 1997. — 37 б.

Тукай Г. Шүрәле: Әкият-поэма / Г. Тукай. — Казан: Мы и наше дело, 1997. — 39 б.

Тукай Г. Кәҗә белән Сарык әкияте / Г. Тукай. — Казан: Раннур, 1999. — 17 б.

Тукай Г. Бәхетле бала / Г. Тукай. — Казан: Раннур, 2000. — 22 б.

Тукай Г. Бәхетле балачак / Г. Тукай. — Казан: Раннур, 2000. — 23 б.

Тукаев Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре / Г. Тукаев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. — 160 б.

Тукай Г. Безнең гаилә / Төз. Н. Газизова / Г. Тукай. — Казан: Раннур, 2001. — 175 б.

Тукай Г. Кәҗә белән Сарык-Кәсә belən Sarıq / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 20 б.

Тукай Г. Мәсәлләр = Məsəllər / Г. Тукай. — Казан: Мәгариф, 2002. — 47 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр / Төз. Ф. Галимуллин / Г. Тукай. — Казан: Хәтер (ТаРИХ), 2002. — 510 б.

Тукай Г. Эш беткәч уйнарга ярый: Шигырьләр = Eş betkəç uynarğa yarıy: Şiğerlər / Төз.-ред. Н. Нотфуллина / Г. Тукай. — Казан: Мәгариф, 2002. — 40 б.

Тукай Г. Шүрәле = Şürəle / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 25 б

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: Шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр / Төз. Ф. Бәшир / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 479 б.

Рец.: Ислам З. Шагыйрь рухына багышлап… (Г. Тукайның вафатына 90 ел) / З. Ислам // Шәһри Казан. — 2003. — 14 нояб.; Аныкы ук. Күңелнең көткәне / З. Ислам // Ватаным Татарстан. — 2003. — 22 окт.

Тукай Г. Энҗе бөртекләре / Г. Тукай. — Казан: Мәгариф, 2004. — 15 б.

Тукай Г. Әкиятләр / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр, 2006. — 60 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда / Төз.: Н. Хисамов, З. Мөхәммәтшин; иск., аңл. әзерл. М. Әхмәтҗанов; җав. мөх. Н. Хисамов / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 1 т.: Шигырьләр, поэмалар. — 271 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда / Төз.: Э. Галимҗанова, З. Шәйхелисламов, З. Рәмиев; иск., аңл. әзерл., җав. мөх. З. Рәмиев / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 2 т.: Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар. — 383 б.

Тукай Г. Әкиятләр / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 63 б.

Тукай Г. Шүрәле: Әкият-поэма / Төз.: Ф. Әхмәтова-Урманче, Р. Корбан / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 97 б.

Тукай Г. Шүрәле: Әкият-поэма. 2 басма / Төз.: Ф. Әхмәтова-Урманче, Р. Корбан / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 97 б.

Тукай Г. Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш: поэма / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр, 2007. — 30 б.

Tuqay Ğ. Şürəle / Ğ. Tuqay. — Qazan: Tatar. kit. nəşr., 2008. — 25 b.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр. 2-нче басма / Төз., кереш сүз авт. Ф. Бәшир / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. — 479 б.

Тукай Г. Тулган Иман белән Коръән садремә. 2-нче басма / Г. Тукай. — Казан: Иман, 1432/2011. — 64 б.

Тукай Г. Әсәрләр: Академик басма. 6 томда / Төз., текст., иск., аңл. әзерл.: Р. М. Кадыйров, З. Г. Мөхәммәтшин; фәнни мөх. З. Рәмиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. — 1 т.: Шигъри әсәрләр (1904–1908). — 407 б.

Тукай Г. Әсәрләр: Академик басма. 6 томда / Төз., текст., иск., аңл. әзерл.: З. Р. Шәйхелисламов, Г. А. Хөснетдинова, Э. М. Галимҗанова, З. З. Рәмиев; фәнни

мөх. З. Рәмиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. — 2 т.: Шигъри әсәрләр (1909–1913). — 384 б.

Рец.: Мансуров З. Дәүләткә торырлык өтер: Тукайның күптомлыкларын чыгаруда кайчан камиллеккә ирешербез? / З. Мансуров // Мәдәни җомга. — 2011. — 18, 25 нояб.

Тукай Г. Аллаһ гыйшкы хакына: шигырьләр / [Төз.] Ф. Хуҗахмәт / Г. Тукай. — Казан: Милләт, 2012. — 175 б.

Тукай Г. Актык тамчы яшь: Шигырьләр / Төз. Л. Шәех / Г. Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. — 495 б.

Тукай Г. И матур тел! / Г. Тукай. — Казан: Тип. «Татграф», 2013. — 35 б.

Тукай Г. Әсәрләр: Академик басма. 6 томда / Төз., текст., иск., аңл. әзерл. З. Шәйхелисламов; фәнни мөх. З. Рәмиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. — 3 т.: Мәкаләләр, фельетоннар, хикәяләр (1904–1906). — 415 б.

Тукай Г. Әсәрләр: Академик басма. 6 томда / Төз., текст., иск., аңл. әзерл. З. Мөхәммәтшин; фәнни мөх. З. Рәмиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. — 4 т.: Проза, публицистика (1907–1913). — 431 б.

Тукай Г. Әсәрләр: Академик басма. 6 томда / Төз., текст., иск., аңл. әзерл.: Э. Галимҗанова, Ф. Фәйзуллина; фәнни мөх. З. Рәмиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. — 5 т.: Г. Тукай төзегән җыентыклар, архив материаллары, документлар (1907–1913). — 471 б.

Тукай Г. Әсәрләр: Академик басма. 6 томда / Төз., текст., иск. аңл. әзерл.: Г. Хөснетдинова, Г. Ханнанова; фәнни мөх. З. Рәмиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. — 6 т.: Мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913). — 415 б.

